ИННОВАЦИОН МӘКТӘП

ФДМС

А.И. Кравченко

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ



5 сыйныф

«РУССКОЕ СЛОВО»

А.И. Кравченко ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ 5

ФДМС

Инновацион мәктәп

А.И. Кравченко

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

Гомуми белем бирү учреждениеләренең 5 сыйныфы өчен дәреслек

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Дәреслеккә РФА (*беркетмә №10106-5215/421 14.10.2011*)
һәм РМА (*беркетмә №01-05/7д-610 24.10.2011*)
тарафыннан федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләренә туры килүгә экспертиза узган

Дәреслек Федераль дәүләт мәгариф стандартына туры килә

Москва
«Русское слово»
2012

Казан
«ХӘТЕР»
2012

УДК 373.167.1:3*05(075.3)
ББК 60я72
К 78

Методик аппарат авторы — *тарих фәннәре кандидаты* И.В. Козленко
Бизәлеш, макет — Н.В. Канурина

Дәреслекнең бизәлешендә Россия балалар фонды (162 б.)
һәм *И.Д. Онохина* (164, 165 б.) фотосурәтләре файдаланылды

Кравченко А.И.

К 78 Обществознание: учебник для 5 класса общеобразовательных учреждений / А.И. Кравченко. — М.: ООО «Русское слово — учебник», 2012. — 200 с. : ил. — (ФГОС. Инновационная школа).

ISBN 978-5-91218-272-3

Кравченко А.И.

К 78 Җәмгыять белеме: гомуми белем бирү учреждениеләренең 5 сыйныфы өчен дәреслек / А.И. Кравченко. — русчадан А.М. Камалов тәрҗ. — Казан: Татарстан Руспубликасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2012. — 200 б.: рәс. б-н

ISBN 978-5-94113-403-8

Китап «Русское слово» нәшриятында җәмгыять белеме дәреслекләренең яңа юнәлештән ача. 5 сыйныф дәреслегенең эчтәлеге кешегә һәм аның янәшәсендәге иҗтимагый мохитка (гаилә, дуслар, укучылар коллективы) багышлана. Шәхесләр арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрнең әхлакый нигезләренә аерым игътибар бирелә. Дәреслек гади, аңлаешлы язылган, анда бишенче сыйныф балаларына көндәлек тормышта юнәлеш бирүче төрле мисаллар китерелгән, бизәлеше уңышлы.

Эчтәлеге 2010 елгы төп гомуми белем бирү Федераль дәүләт мәгариф стандартына һәм Төп гомуми белем бирүнең якынча программасына тулысынча туры килә.

Дәреслек гомуми белем бирү учреждениеләре: мәктәпләр, гимназияләр һәм лицейлар өчен әзерләнгән.

УДК 373.167.1:3*05(075.3)
ББК 60я72

Учебное издание

ФГОС. Инновационная школа

Кравченко Альберт Иванович

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

Учебник для 5 класса общеобразовательных учреждений
(Перевод с русского на татарский язык)

Редакторы *Р.С. Вафина*
Корректоры *Н.Г. Габдрахманова*
Компьютерда битгә салучы *Ю.М. Эстис*

Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты

420111, Казан, Тельман ур., 5
Хатлар өчен: 420014, Казан, Кремль, а/я 14
Тел./факс: (843) 264-67-96

Оригинал макеттан басарга кул куелды 24.07.12. Форматы 60х90 1/16.
Офсет кәгазе. «Mysl», «Bukvar» гарнитурасы. Офсет басмасы.
Басма табагы 12,5. Тиражы 3830 д. Заказ М-748.

«Татмедиа» ААҖ филиалы –
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2

ISBN 978-5-91218-272-3
ISBN 978-5-94113-403-8

© А.И. Кравченко, 2012
© ООО «Русское слово — учебник», 2012
© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, татарчага тәрҗемә, 2012

Эчтәлек

Кереш 5

1 бүлек. Кеше җәмгыятьтә

§ 1. Кеше дигән сер 9
§ 2. Кешенең ихтыяҗлары 14
§ 3. Кеше мәнфәгатьләре 19
§ 4. Кеше үз-үзен һәм башкаларны ничек бәяли 27
§ 5. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм аерым ихтыяҗлары булган кешеләр 33
§ 6. Эшчәнлек 39
§ 7. Кеше дөньяны һәм үз-үзен ничек танып белә 47
§ 8. Белем алу һәм үзлегеңнән белем алу 52
§ 9. Социальләшү 58
§ 10. Кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны 66
§ 11. Кешенең гомер чорлары 74
§ 12. Яшүсмерлек чоры үзенчәлекләре 81
§ 13. Гендер нәрсә ул? 88
§ 14. Малайларның һәм кызларның үз-үзләрен тотышында аерымлыклар 94
§ 15. Кешенең милләте 100
§ 16. Россиянең яшь гражданнары 107
§ 17. Сәламәт яшәү рәвеше 113
§ 18. Тормыш иминлеге 119
1 бүлеккә йомгаклау сораулары һәм биремнәре 126

2 бүлек. Яшүсмернең иң якын даирәсе

§ 19. Иң якын кешеләр 129
§ 20. Гаилә мөнәсәбәтләре 136
§ 21. Гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре 143

§ 22. Гаиләдә кайгыртучанлык һәм тәрбия............................149
§ 23. Гаиләгә дәүләт ярдәме...156
§ 24. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау..........................161
§ 25. Кеше кече төркемдә..168
§ 26. Аралашу..173
§ 27. Шәхесара конфликтлар..179
2 бүлеккә йомгаклау сораулары һәм биремнәре.................185
Йомгаклау тесты...187
Йомгаклау..192
Сүзлек...194
Җәмгыять белеме буенча Интернет ресурслары.........200

Кереш

Кадерле 5 нче сыйныф укучылары!

Сезнең дәресләр исемлегендә җәмгыять белеме дигән яңа фән пәйда булды. Сез аны мәктәпне тәмамлаганчы өйрәнәчәксез. Бу курста без яшәгән **җәмгыять** — кешеләр дөньясы өйрәнелә.

Җәмгыять ул, табигать кебек үк, бик катлаулы һәм кызыклы күренеш, һәм шуңа күрә дөньяда булган барлык фәннәр зур төркемнәргә бүленә. Беренчесен төгәл һәм табигать фәннәре — физика, химия, биология һ.б. тәшкил итә. Алар терек һәм терек булмаган табигатьне: йолдызларны, диңгезләрне, җир тетрәвен, үсемлекләрне һәм хайваннарны өйрәнәләр.

Икенче төркемгә иҗтимагый фәннәр керә. Алар җәмгыятьне өйрәнә. Җәмгыять — кешеләрнең күмәк эшчәнлек җимеше ул. Әмма күмәкләп кешеләр генә эшчәнлек кылмый. Кырмыска оясы — шулай ук катлаулы бергәлек, ул кешеләр бергәлеген хәтерләтә. Бал кортлары да, кешеләр кебек үк, күмәк тормыш алып бара. Әмма кырмыскалар да, бал кортлары да кырмыска оясы яисә умарта эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килми. Алар — табигатьнең бер өлеше.

Миллион еллар элек кеше дә фәкать табигать продукты гына булган. Безнең ерак бабаларыбыз да хайваннарга охшаган, алар сөйләшә дә, уттан файдалана да белмәгән, гаилә һәм дуслык турында мәгълүматлары булмаган. Әмма кеше акрынлап үсеш-үзгәреш кичергән, эшләгән, сөйләшергә һәм фикерләргә өйрәнгән, соңрак йолалар һәм гореф-гадәтләр барлыкка килгән. Кеше үзе дә үзгәреш кичергән, әйләнә-тирә мохитен үзгәрткән. Хайваннар мондый сәләткә ия түгел! Боларның барысына да кешеләр күмәкләп, җәмәгать белән гамәл кылулары нәтиҗәсендә ирешкәннәр. «Җәмгыять» сүзе нәкъ менә шушыннан ки-

леп чыккан. Бергәләп эшләгәндә, уртак карашлар, инанулар, гореф-гадәтләр барлыкка килгән. Туганнан соң кеше, күмәк йолаларны, нормаларны, кыйммәтләрне үзләштерә-үзләштерә, озын юл уза. Ул, табигать кочагыннан аерылып, иҗтимагый затка әверелә.

Тарих дәресләрендә сез кешелек җәмгыятьләренең ничек һәм нигә барлыкка килгәнен, аларның ничек үзгәрүен һәм үз тирәләрендә дөньяны ничек үзгәртүләрен белерсез, ә җәмгыять белеме сезгә хәзерге җәмгыятьнең ни-нәрсә булуын төшенергә ярдәм итәр.

Җәмгыять белемен берничә фән тәшкил итә. Болар — **философия, социология, икътисад, хокук белеме, политология, психология** һәм **мәдәният белеме.** Аларның һәрберсе нәрсә өйрәнгәнен дәреслекнең ахырындагы сүзлектән укып белә аласыз. Бу сүзлек уку елы дәвамында сез өйрәнгән төп төшенчәләр һәм терминнар җыелмасыннан гыйбарәт.

Дәреслек бүлекләрдән һәм параграфлардан тора. Һәр параграф бүлекчәләргә бүленә. Алар өйрәнелә торган теманың төп мәсьәләләрен формалаштыра.

Параграф текстында аның эчтәлеген үзләштерү өчен мөһим рубрикалар урнаштырылган. Шул рәвешчә, «Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!» рубрикасы «Җәмгыять белеме» курсының төп төшенчәләре белән эшләү өчен файдалы булачак.

Моннан тыш параграфларның төп текстын тарихи һәм заманча фактларына, фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләренә таянып аңлата һәм киңәйтә торган «Кызыклы фактлар», «Өстәмә уку» рубрикалары белән танышачаксыз. «Законга мөрәҗәгать итик» рубрикасында законнардан өзекләр китерелә, «Акыллы фикер» үткәннең мәшһүр затлары әйткән сүзләр белән таныштыра. «Йомгак ясыйбыз» рубрикасы тема буенча чыгарылган нәтиҗәләрдән гыйбарәт.

Төрле сорауларга җавап эзләү һәм биремнәрне үтәү сезгә теманы яхшырак үзләштерергә ярдәм итәчәк.

Һәр параграф алдыннан дәрес темасына төшенергә, иң әһәмиятле нәрсәләрне аерып алырга өйрәнергә, алдарак өйрәнелгәннәрне искә төшерергә булышачак сораулар китерелә. Параграф текстында бу сорауларга җавап

эзләүне дәрес вакытында башкарырга мөмкин, ул сезгә өй эшен эшләүне җиңеләйтәчәк.

Өй эше сораулары һәм биремнәре арасында параграфта каралган мәсьәләләргә төшенүне таләп итә торган, укучылар үз белемнәрен үзләре тикшереп карасын өчен махсус сораулар («Белемегезне сынап карагыз») һәм практик биремнәр («Практикум») бар. «Практикум» биремнәре укучыларның булган белемнәрен эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә һәм төрле тормыш шартларында файдалануга юнәлдерелгән (шартларны анализлау, актуаль проблемаларны ачуга багышланган инша — фикер йөртү, кече проектлар һәм презентацияләр әзерләү һ.б.). Катлаулырак сораулар һәм биремнәр йолдызчык (*) белән билгеләнгән. Кайбер биремнәрне үтәгәндә, тарих, әдәбият дәреслекләреннән, шулай ук сүзлекләрдән, энциклопедияләрдән, Интернет материалларыннан файдаланырга киңәш ителә.

Дәреслек бүлекләре гомумиләштерү характерындагы йомгаклау мәсьәләләре һәм биремнәре белән тәмамлана.

Дәреслек белән эшләү уңайлырак булсын өчен һәр рубриканың махсус билгесе бар:

Кызыклы фактлар

Өстәмә уку

Законга мөрәҗәгать итик

Акыллы фикер

Практикум

Белемнәрегезне сынап карагыз

Автор дәреслек үзегезне һәм без яши торган җәмгыятьне өйрәнү юнәлешендәге мөстәкыйль адымнарыгызга этәргеч бирер дип ышана.

1 бүлек

Кеше җәмгыятьтә

§ 1. Кеше дигән сер

Кеше ни ул?

Кешенең Җир йөзендә пәйда булуы

Җир йөзендә пәйда булган мизгелләреннән алып XXI гасыр башына кадәр кеше зур үсеш юлы кичерә. Әгәр фикеребезне эшкә җигеп, кешегә күз салсак, аның тормыш рәвешендә, тышкы кыяфәтендә һәм әйләнә-тирә мохитендә нинди зур үзгәрешләр килеп чыкканлыгын күрербез. Галимнәр Җир шарында яшәгән бер генә тереклек иясенең дә бу вакыт эчендә шундый зур үзгәреш кичермәгәнлеген ышанып әйтәләр. Үзе дә танымаслык булып үзгәрүгә һәм тирә-як мохитне үзгәртүгә фәкать кеше генә ирешкән.

Кеше Җирдә ничек барлыкка килгән? Бу турыда төрле фикерләр бар. Галимнәрнең бер өлеше кешенең борынгы бабалары маймыллардан килеп чыккан дип саный. Алар акрынлап, 2,5 млн елдан артык вакыт эчендә үсеш һәм үзгәреш кичергән, нәтиҗәдә Җирдә **кеше** пәйда булган. Бу турыда Борынгы заман тарихы дәресләрендә тирәнрәк белә алырсыз.

Кеше ни соң ул?

Кешенең табигате

Асылда, кешедә ике башлангыч: **биологик** (табигый, хайвани) һәм **социаль** (иҗтимагый) башлангычлар берләшә.

Грек теленнән тәрҗемә иткәндә, **биология** «тереклек турында фән» дигәнне аңлата. **Иҗтимагый** (социаль) сүзе socialis — «иҗтимагый» дигән латин сүзеннән (латин телендә кайчандыр борынгы римлылар сөйләшкән) килеп чыккан.

Кешелек барлыкка килүне ике чорга — биологик һәм иҗтимагый этапларга бүләргә мөмкин. Беренче этап озынрак, икенчесе – кыскарак.

Биологик этап
2,5 млн ел

Социаль этап
40 мең ел

Кешенең формалашу этаплары

Биологик этапта әле хәзер дә кешене башка тереклек ияләреннән аерып тора торган төп билгеләр барлыкка килгән. Болар: ике аякта йөрү, нык үскән баш мие, фикерләү сәләте, анык сөйләм, аң, хезмәт коралларыннан һәм уттан файдалану.

Кызыклы фактлар

Кешенең баш мие 80 процент судан тора.
Кеше елмайганда аның 17 мускулы «эшкә җигелә».
Үпкәнең өслеге 100 кв.метрны тәшкил итә.
Кешенең уңъяк үпкәсе, сулына караганда, күбрәк һава сыйдыра.
Кеше йөрәгенең үлчәме аның йодрыгы белән бер чамада.
Бер минут эчендә кеше йөрәге 23 литр кан куа.

Әмма кеше үз үсешендә тукталып калмый! 40 мең ел элек хәзерге кешеләрне хәтерләтә торган адәм заты — **«аңлы кеше»** барлыкка килә. Кешедәге соңгы 40 мең ел буена барган үзгәрешләр биология белән түгел, җәмгыять белән, ягъни аның башка кешеләр арасында көн күрүе белән бәйләнгән. Сөйләм барлыкка килү кешегә әйләнә-тирә мохит турында белем тупларга һәм аны буыннан буынга тап-

шыра килергә, башка кешеләр белән аралашырга мөмкинлек бирә, аларның үзара аңлашуына һәм уртак хезмәттәшлегенә ярдәм итә. Болар барысы да кеше барлыкка килүнең **социаль этабында** бара. Күмәк хезмәт эшчәнлеге вакытында кеше социаль, иҗтимагый зат буларак үсеш кичерә.

Кызыклы фактлар

Җәнлек-җанварларның (бүреләр, аюлар, маймыллар һәм хәтта ана юлбарысның) адәм балаларын тәрбияләү, бу балаларның аннары кешеләр арасына кире кайту очраклары тарихта утыздан артык. Алар барысы да бик авырлык белән нибарысы берничә сүз әйтергә өйрәнә, ике аякка басып йөрергә күнегә алмый һәм, кагыйдә буларак, тиздән һәлак була.

Бу балаларның язмышы ни өчен шулай була соң? Чөнки алар бик озак кешеләрдән, җәмгыятьтән аерылып яши. Вакытында аларны кеше булырга өйрәтүчеләр табылмый.

Шулай итеп, кеше — биологик һәм иҗтимагый зат. Кешенең сере нәкъ менә шуннан гыйбарәт. Кешенең биологик башлангычы аның кайчандыр хайван булганлыгы белән бәйләнгән. Иҗтимагый башлангыч уку-өйрәтү һәм тәрбия аша җәмгыятьтән алынган, ул кешедә өстенрәк урын тота.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Биологик (грек теленнән bios — тормыш, logos — тәгълимат) — табигый; терек табигать белән бәйле.

Иҗтимагый (латин телендәге «socialis» сүзеннән) — җәмгыятьнеке; җәмгыятькә бәйле.

Нинди үзенчәлекләре кешене биологик зат буларак характерлый? Кешенең баш мие, скелеты, мускуллары, нервлары, кан әйләнеше һәм башка системалары бар. Биологик организм буларак без, мәсәлән, ризыкка, нәселебезне дәвам итүгә, иминлеккә ихтыяҗ тоябыз.

Иҗтимагый зат буларак, кешегә **иҗтимагый тирәлек** кирәк. Бу кешенең үзе кебек кешеләр арасында, җәмгыятьтә яшәвен, һәм анда билгеле бер кануннар, оеш-

малар, гореф-гадәтләр, йолалар, иҗтимагый нормалар гамәлдә булуын аңлата. Әйтик, җәмгыять яшьләрдән өлкәннәргә ихтирамлы булуны таләп итә. Хайваннарда мондый традиция юк. Ягъни җәмгыять ул — нормалар һәм традицияләр нигезендә идарә ителгән иҗтимагый тирәлек. Боларның барысы турында да җәмгыять белеме курсында сүз булачак әле.

Безнең бер-беребездән нык аерылуыбыз, ике бердәй затның булмавы — кешенең тагын бер сере шул. Һәр кешенең үз мәнфәгатьләре һәм ихтыяҗлары, хәтере һәм ихтыяры, гадәтләре була, ул үзенчә тоя, үзенчәлекле талантка һәм сәләткә ия була. Киләсе дәресләрдә без сезнең белән

Кеше — биологик зат

Кеше — иҗтимагый зат

❓ Фотосурәтләрдә кешенең биологик һәм иҗтимагый үзенчә-лекләре чагылышы ничек күрсәтелүен аңлатыгыз.

Йомгак ясыйбыз

Кешенең сере биологик һәм иҗтимагый башлангычларны берләштерүеннән гыйбарәт.

Кешеләр бик күп төрле, һәрбер кешенең билгеле бер холкы, мәнфәгатьләре һәм ихтыяҗлары, сәләтләре һәм талантлары бар.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Биологик, иҗтимагый

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Сез «кеше — биологик һәм иҗтимагый зат» дигән гыйбарәне ничек аңлыйсыз? Җавап биргәндә, схемадан файдаланыгыз.



2. Түбәндәге төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатыгыз: «иҗтимагый», «биологик».

3. Кеше хайваннардан, нигездә, ни белән аерыла?

4*. Сезнең карашка, бер кеше икенчесеннән ни белән аерыла?

Практикум

1. Кешенең биологик зат булуын раслаучы мисаллар китерегез. Кешенең иҗтимагый зат булуын исбатлаучы мисаллар китерегез.

2*. Кешенең килеп чыгышы турында сез бу параграфта укып белгән фәнни карашлардан тыш башка карашлар да бар. Кешенең килеп чыгышына кагылышлы төрле фикерләр ни өчен яши дип уйлыйсыз? Шуларның берәрсе турында кыска чыгыш әзерләгез. Тарих дәреслекләре материалларыннан, энциклопедияләрдән, Интернеттан файдаланыгыз.

3*. Сез, мөгаен, инглиз язучысы Редьярд Киплингның «Джунгли китабы» дигән әсәре герое Маугли белән таныштыр. Аның тормышынданиләр чынбарлыкка туры килә, ә ниләр уйдырма?

§ 2. Кешенең ихтыяҗлары

Кешенең ихтыяҗлары нәрсә ул? Аларның ниндиләре була? Акыллы һәм акылга сыймаслык ихтыяҗлар нәрсә ул? Ихтыяҗлар кирәгеннән артык булырга мөмкинме?

Кеше ихтыяҗларының төрлелеге

5 нче сыйныф укучылары буларак, сез күп беләсез һәм кулыгыздан да күп нәрсә килә. Мөгаен, арагыздан кемнәр музыка, спорт яисә бию белән шөгыльләнәдер, атаклы кешеләр тормышы белән кызыксына, театрларга, музейларга, концертларга йөри, ата-аналарыгыз белән төрле шәһәрләргә сәяхәт кыладыр. Һәм, әлбәттә, сездә китап уку, хуҗалык эшләрендә өлкәннәргә булышу, кыерсытылганнарны яклау теләге туа. Болар барысы да — сезнең шәхесегез, эчке дөньягыз чагылышы.

Ихтыяҗ кичерү тормышыбызда зур роль уйный. Алар булмаса, әйләнә-тирәбездә бушлык хасил булыр — йортлар да, күперләр, биналар, очкычлар да, компьютерлар да булмас иде. (Чөнки ул очракта кешеләргә боларның кирәге юк.)

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Ихтыяҗлар — кешеләргә кирәкле төрле файдалы нәрсәләр ул. Әйтик, азык-төлек һәм өс-баш, мәхәббәт һәм кайгырту, дуслык һәм ярдәмчеллек, музыка һәм спорт, белем алу һәм аралашу, сәяхәт итү һәм башкалар.

Кешенең ихтыяҗлары бик күп төрле. Ашау, эчү, баш өстендә түбә булдыру кебек гади хаҗәтләр белән беррәттән, иминлеккә, мәхәббәткә һәм дуслыкка, үз-үзеңне хөрмәт итүгә һәм башкаларның сиңа ихтирамына, матурлыкка, көйлелеккә һәм гаделлеккә ихтыяҗ кебек катлаулыраклары да бар...

Ихтыяҗларның **акылга сыйганнары** (чыннары) һәм **акылга сыймаганнары** (ялганнары) бар. Аларны канәгатьләндерү кешегә файда китерә торган ихтыяҗлар — акыллы, ә зыян

сала торганнары акылга сыймаган ихтыяҗлар дип санала. Исерткеч эчемлекләр эчүгә яисә тәмәке тартуга ихтыяҗ — акылсыз, ә спорт белән шөгыльләнү яисә эти-әниеңә фатир җыештырырга булышу теләге — күркәм ихтыяҗ.

Кызыклы фактлар

Тәмәке тартудан минутына алты кеше үлә. 35 яшьтән алып 69 яшькәчә булган россиялеләрнең гомере тәмәке тарту аркасында уртача алганда 20 елга кыскарды. Тәмәкечеләрнең колаклары 1,7 тапкырга ешрак начар ишетә башлый. 13 яшьтән 15 яшькәчә тәмәке тартучы үсмерләрнең саны бөтен дөньяда 14 процентка җитә, әмма аларның өчтән ике өлеше бу начар гадәттән котылырга тели.

Бүген күп кенә илләрдә бөтен җәмәгать урыннарында диярлек тәмәке тарту тыелган. Бу начар гадәткә каршы Россиядә дә көрәш алып барыла.

Акылга муафыйкъ булмаган ихтыяҗлар кешенең камилләшүенә һәм үсешенә киртә була, җәмгыятькә зыян китерә.

Плакатларда кешенең акылга сыймаслык нинди ихтыяҗлары фаш ителә? Ни өчен аларга каршы көрәшергә кирәк?

Әйтик, наркоманлык бөтен кешелек казасына әверелде. Көче һәм сәламәтлеге ташып торган меңләгән яшь кеше дәваланмаслык чир тозагына эләгә, күбесе үлә.

Ихтыяҗлар тагын **матди** (әйберләргә ихтыяҗ), **иҗтимагый** (кешенең җәмгыятьтә яшәвенә бәйле), **рухи** (дөньяны һәм үз-үзеңне танып белүгә бәйле) була. Беренче төркемгә — ризыкка, торакка, кием-салымга, төрле техникага һ.б. ихтыяҗ; икенчесенә — аралашуга һәм күмәклеккә, дуслык, мәхәббәт, көчсезләрне яклауга, үзара ярдәмләшүгә, кайгыртучанлыкка, башкаларның ихтирамына һ.б ихтыяҗ; өченчесенә яшәешеңнең мәгънәсенә төшенүгә, яңа белем һәм тәэсирләргә, сәфәр-сәяхәтләргә, иҗатка, рәсем ясау, музыка, спорт, бию белән шөгыльләнүгә, камилләшүгә ихтыяҗ керә.



Әлеге ихтыяҗ нинди төргә карый? Ул матдиме, әллә рухимы? Үз җавабыгызны нигезләгез.

Ихтыяҗларның барлыкка килүе

Барыннан да элек матди ихтыяҗлар туган. Чөнки мәрхәмәтлелек яисә әйләнә-тирә дөньяны танып белү ихтыяҗы туганга кадәр, кешеләргә исән калу өчен көрәшергә туры килгән.

Рухи һәм иҗтимагый ихтыяҗлар, күрәсең, бергә барлыкка килгәндер. Борынгы кешенең кыядагы сурәтләре, кеше

һәм хайван сыннары, төрле бизәнү әйберләре, аучыларның йола биюләре башкаруы борынгы каберлекләр, бүләк бирешү, балалар, олылар һәм гарипләр турында кайгырту белән бергә барлыкка килгән.

Ихтыяҗлар күп була аламы?

Үз ихтыяҗларын канәгатьләндергәндә, кеше хезмәт коралларын камилләштерә, гаилә мөнәсәбәтләре кора, торагын бизи, хәвефкә каршы тору сәләтен ныгыта, дәүләт мөнәсәбәтләрен үстерә һәм, җәмгыять яхшырсын өчен, башка бик күп нәрсә эшли. Димәк ки, ихтыяҗлар — кеше җәмгыяте үсешенә этәргеч бирүче көч ул.

Әмма һәрчак алай түгел. Кешенең ихтыяҗлары чамадан тыш артып китү очраклары да була. Тормышын җайлау өчен бер ихтыяҗларын канәгатьләндереп өлгерми, кешенең яңа, тагын да куәтлерәк кирәк-яраклары килеп чыга. Алтын балык турындагы әкиятне искә төшерегез. Әби башта яңа тагарак сорый, аны биргәч, балчык алачык урынына яңа йорт кирәк була, ә аннары ихтыяҗлары чамадан аша — үзен нәселле (столбовая) дворянка, алай гына да түгел, патшабикә ясауны таләп итә. Ахыр килеп, карчыкның диңгез хуҗабикәсе буласы килә башлый. Әкият шуның белән бетә дә. Карт кайтып керсә, карчык ватык тагарак янында утыра. Димәк ки, ул үзенә кирәкмәгән нәрсәгә өметен сузган булып чыга!

Ихтыяҗларның артуы һәм өстенлеккә омтылуы

Матди ихтыяҗлар — түбән, ә иҗтимагый һәм рухилары өстен ихтыяҗлар була. Тормышта өстен ихтыяҗларны канәгатьләндерергә тырышып яшәргә кирәк. Бу **өстен ихтыяҗларга күчү** дип атала.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Өстен ихтыяҗларга омтылу — кешенең түбән (матди) ихтыяҗларын үтәүдән өстен (рухи, иҗтимагый) ихтыяҗларын үтәүгә күчүе.

Мәсәлән, башта тамак туйдырырга (матди ихтыяҗ), аннары китап укырга (рухи ихтыяҗ) кирәк.

Ихтыяҗлар, күтәрелү белән беррәттән, **арталар** да әле. Ихтыяҗ даирәләре үзгәреш кичерми торган хайваннардан аермалы буларак, кеше ихтыяҗлары даими арта бара. Һәрбер чираттагы тарихи чор саен кеше ихтыяҗлары төрлеләнгәннән төрләнә. Борынгы кеше учакта кыздырылган кош ите белән туенып, шуңа канәгать булган. Хәзерге заманның тәмле ашарга яратучылары шул ук кош итен, төрле тәмләткечләр һәм соуслар кулланып, грильдә әзерләп ашый.

Үзеңнең рухи ихтыяҗларыңны арттырырга омтылырга: китаплар укырга, музыка тыңларга, спорт белән шөгыльләнергә, театрларга һәм музейларга йөрергә кирәк.

Йомгак ясыйбыз

Ихтыяҗлар — кешеләр ирешергә омтылган төрле уңайлыклар. Кешенең ихтыяҗлары күптөрле, алар шәхеснең эчке дөньясын характерлый. Кешегә өстен ихтыяҗларга омтылу һәм аларның артуы хас.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Ихтыяҗлар, өстен ихтыяҗларның барлыкка килүе

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Ихтыяҗлар нәрсә ул? «Ихтыяҗ» сүзенә синонимнар табыгыз.

2. Ихтыяҗлар нинди була? Ихтыяҗ төрләренә мисаллар китерегез.

3. «Ихтыяҗларның артуы һәм өстенлеккә омтылу» ни дигән сүз, шуны аңлатып бирегез. Яшегезгә карап сезнең ихтыяҗларыгыз ничек үзгәрде?

4*. Уйлап карагыз: альтруистлык — башкалар өчен үзүзеңне корбан итү ихтыяҗы нинди төргә керә?

5*. Ихтыяҗларың белән идарә итү мөмкинме? Булса, ничек идарә итәргә мөмкин?

Практикум

1. Борынгы җәмгыять тарихыннан матди ихтыяҗларның алданрак барлыкка килүен исбатлаучы мисаллар китерегез.

2. Үзегезнең төп ун ихтыяҗыгызны атагыз. Аларның кайсылары матди, кайсылары иҗтимагый һәм рухи?

3*. Ихтыяҗларыгызның артуын һәм өстен ихтыяҗларыгыз барлыкка килүе планын төзегез.

4*. Николай Носовның «Белмәмешнең Айга сәяхәте» китабы геройлары Җүләрләр утравына эләгә. Бу утрауда яшәүчеләр бары тик ашыйлар, йоклыйлар, аттракционнарда әйләнәләр һәм куркыныч фильмнар карыйлар, шулай итеп, акрынлап куйларга әверелә баралар. Җүләрләр утравы кешеләре нинди ихтыяҗларын канәгатьләндерә, ә нindиләрен — юк? Автор аларны куйларга әйләндерүе белән ни әйтергә теләгән?

§ 3. Кеше мәнфәгатьләре

Мәнфәгать нәрсә ул? Алар нинди була? Ничек итеп кызыклы белем алырга һәм яшәргә?

Без сезнең белән кешенең серен чишүне дәвам итәбез. Узган параграфта ихтыяҗлар турында фикер алыштык. Бүген без кешенең мәнфәгатьләре, кызыксынулары турында сөйләшербез. Безнең ихтыяҗларыбыз нәкъ менә мәнфәгатьләребездә чагылыш таба.

Кызыксыну

Сезгә кайчан да булса: «Син нәрсә белән кызыксынасың? Сиңа нәрсә кызыклы?» — дигән сорау биргәннәрдер, мөгаен.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Мәнфәгать — нәрсәгә дә булса яисә кемгә дә булса аңлы ихтыяҗ; нинди дә булса предмет белән танышу нияте, аны танып белүгә омтылыш. Әйтик, әдәбият, спорт, медицина, чәчәкләр үстерү, музыка белән шөгыльләнү, сәяхәт итү мәнфәгате.

Кызыксыну эш өлкәсенә караган, акчага хирыслыкка корылган булырга мөмкин, бу очракта алар файда алуга юнәлтелгән була. Мәсәлән, кеше эшкә аның кызыклы булуына карап түгел, бәлки югары хезмәт хакы түләнүгә карап урнаша.

Мәнфәгать күпчелек очракта хисләр яссылыгында туа, ихлас була. Бу очракта нәрсәгә дә булса игътибар бирү, кызыксынучанлык турында сүз алып баралар. Сез, әйтик, сатар өчен түгел, күңелегезгә рәхәтлек алу өчен чәчәк үстерәсез.

Акыллы фикер

«Кызыксыну — безнең бөтен уйларыбыз һәм гамәлләребез чыганагы ул».

Клод Гельвеций, XVIII гасыр француз философы

Кызыксынулар бик иртә формалаша. Балаларда аның башта гади формасы барлыкка килә: аларның игътибарын ачык төсләр һәм күзгә ташлана торган яңалыклар җәлеп итә. Аннары нилэр була соң? Үзегезне искә төшерегез: сез, үскән саен, «Бу нәрсә?», «Бу кем?», «Нигә шулай?» кебегрәк сорауларны һаман да ешрак бирә торган булгансыздыр. Нигә күк йолдызлы, кешеләр ни өчен баштүбән йөрми? Ни өчен «яңгыр коя» дибез, ә «кар коя» дип әйтмибез? Башка планета кешеләре кайда яши, һәм Ай каян килгән?



Мәктәпкә кергәнче нәрсәләр белән кызыксынуыгызны искә төшерегез.

Ниһаять, сез 1 нче сыйныфка укырга кердегез. Укытучы ачык һәм гыйбрәтле мисаллар китереп дәрес бирсә, уку материалының яхшырак үзләштерелүен, шулай ук җитди кызыксыну тудыруын сез сизми калмагансыздыр. Мондый дәресләрдән соң сыйныфташларыгызның барысы да кинәт кенә тарихчы, язучы яисә рәссам булырга хыяллана башлый.

«Кызыксыну» сүзенең тамырында «кызык» («игътибарны биләү» мәгънәсендә) сүзе ята. Әйтик, эшчеләрне — хезмәт хакын күтәрү, ә эшкуарларны табыш алу кызыксындыра. Мәктәп җитәкчелеген һәр сыйныфта бишлегә генә укучылар саны күбрәк булуы, ә ата-аналарны мәктәпнең балаларындагы төрле сәләтләрне мөмкин кадәр киңрәк ачуы кызыксындыра. Күрүебезчә, бар очракларда да билгеле бер нәтиҗәгә ирешү нияте турында сүз бара.

Кешенең мәнфәгатьләре гаять күп. Олыгая барган саен, алар арта гына. Берәүләр сәясәт белән, икенче берәүләр маҗаралы әдәбият уку, экстремаль спорт төрләре белән кызыксына һ.б.

Мәнфәгатьләр иерархиясе

Һәр кешенең мәнфәгатьләре төрле-төрле була. Аларның кайберләренә ул күбрәк, ә кайберләренә азрак игътибар

бирә. Димәк, һәр кеше үз кызыксынулары «исемлеген» төзәргә һәм аларны мөһим булмаганнардан мөһимнәренә яисә түбәннәреннән алып югарыларына таба тәртип белән урнаштыра ала.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Иерархия — нәрсәнең дә булса өлешләренең (элементларын) түбәннәреннән югарыларына таба, мөһим булмаганнарыннан (икенчелләреннән) мөһимнәренә таба эзлекле урнашуы.

Банкирның төп кызыксынуы, әйтик, фермер яисә язучы өчен һич кенә дә мөһим булмаска мөмкин. Ирләрнең кызыксынулары хатын-кызларныкыннан аерыла, ә балалар һәм картларның бер үк әйберләр белән кызыксыну очраклары бик сирәк. Мәсәлән, яшьләр музыканың көчле яңгыравын тели, ә әби-бабайларга тынычлык кирәк. Әти кеше кичләр буена яраткан футболын карарга әзер, ә әни кешенең сериал карыйсы килә. Банкир зур табыш китерәчәк эш башкарып чыгарга тели, ә авыл хуҗалыгында эшләүче кеше корылык кайчан тәмамланыр икән дә, кайчан яңгыр явар икән дип борчыла.

Кеше тормышында аның мәнфәгатьләре даирәсенең киңлеге зур роль уйный. Ул кешенең рухи байлыгы ни дәрәҗәдә булуын, аның күпкырлылыгын күрсәтә.

Акыллы фикер

«Һәрнәрсә турында аз-маз һәм аз гына нәрсәләр турында тулы мәгълүматлы булырга кирәк».
Константин Тимирязев, рус галиме, табигать фәннәре белгече

Башкача әйткәндә, кеше һәрнәрсә белән кызыксынырга, әмма аның төп мәнфәгате кызыксынуы берәү генә булырга тиеш. Ул кешегә сайлаган һөнәрендә камиллеккә ирешергә мөмкинлек бирә.

Фотосурәтләрдә тасвирланган эшчәнлек төрләрендә нинди кызыксынулар чагылыш таба?

Өстәмә уку

Рус халкының XVIII гасырда яшәгән бөек гаскәр башлыгы Суворов гадәттән тыш кызыксынучанлык үрнәге булып тора. Аның киң даирә кызыксынуларының иң мөһиме сугыш эше тирәсендә тупланган була. Үсмер елларыннан ук ул үзенең тормыш-көнкүрешен тулаем сугыш эшенә әзерләнүгә буйсындыра: хәрби тарих һәм техника буенча үзе таба алган бар китапларны укып чыга, тактик мәсьәләләрне чишә, организмын сугыш вакытында гаскәриләр җилкәсенә төшә торган авырлыкларны күтәрергә акрынлап күнектерә. Гадәттән тыш зур кызыксынуы организмының физик яктан зәгыйфьлеген дә, әтисенең малайны хәрби хезмәткә әзерләүгә катгый каршы торуын да җиңә. Шуның белән беррәттән Суворов үз чорының иң укымышлы кешеләреннән берсе була. Ул гыйлем өлкәләренең барысы белән дә кызыксына, буш вакытын тулысынча укуга һәм белем туплауга багышлый, математика,

география, философия, тарих фәннәрен яхшы белә. Телләр өйрәнүгә күп вакыт бирә, немец, француз, итальян, поляк, фин, төрек, гарәп, фарсы телләрен белә.



А.В. Суворов
Рәссамы И. Крейцингер. 1799

Текстка нигезләнеп: «А.В.Суворов — бик күп мәнфәгатьләре булган кеше, һәм аларның барысы да бер төп кызыксынуы — сугыш эше тирәсендә тупланган була», — дигән сүзләрне раслагыз.

Мәнфәгатьләрне үстерү һәм «чыныктыру»

Әгәр концертларга йөрсәң, музыкага кагылышлы мәгълүмат бирә торган әдәбият укысаң, берәр уен коралында уйнарга өйрәнсәң, мәктәп ансамблендә катнашсаң, музыка белән зәгыйфь кенә кызыксынуның да тора-бара чын-чынлап зур хирыслыкка әверелүе мөмкин булуын сезнең һәрберегез таныйдыр. Бу мисалдан мәнфәгатьләрне, кайчак үзебезне мәҗбүр итеп булса да, тәрбияләргә һәм «чыныктырырга», үстерергә һәм тирәнәйтергә кирәклеген ачык аңлыйбыз. Әмма кызыксынулар, аларга мәгълүмати «ягулык» өстәп яисә белемнәр белән ашлап тормасаң (булдыклы бакчачы үз бакчасын яратып үстергәндәй), сүнәргә дә мөмкин. Ата-аналарыгыздан сорап карагыз: үсмер чакларындагы кызыксынуларыннан кайсылары хәзергә кадәр сакланды икән?

Сезнеңчә мәнфәгатьләрне ни өчен «чыныктырырга» һәм үстерергә кирәк?

Өлкәннәрнең еш кына уфтануларын ишетергә туры килә: ни өчен үз вакытында, мөмкинлек була торып, алар әдәбият, музыка, рәсем ясау белән шөгыльләнмәгәннәр, үз рухи дөньяларын ярлы хәлдә калдырып, шәхесләрен берьяклы гына үстергәннәр, янәсе. Вакытында башкарылмаган эшләрне олыгайгач башкару күпчелек очракта мөмкин булмавын исегездән чыгармагыз. Моның өчен кешенең, гадәттә, көче дә, вакыты да, мөмкинлекләре дә җитми.

Кызыксыну бездә хисләр, фикерләр, теләкләр уята. Максат кую һәм аңа ирешү юлларын билгеләгәнлектән, ул эшчәнлегебезне оештырырга ярдәм итә. Теге яисә бу нәрсә — фән, музыка, спорт белән кызыксынуыбыз шуларга тәңгәл килә торган эшчәнлек белән шөгыльләнүебезгә сәбәп була. Әйтик, кеше, кибеткә барып, үзенә кирәкле китапны сатып ала, музыка яисә спорт секциясенә языла.

Кызыксынулары булмаган кешенең тормышы күңелсез, эчпошыргыч һәм мәгънәсез була. Бер нәрсәдән ямь тапмаган, күңелсезлеккә бирелеп яшәгән кеше ялгыз кала. Бер үк нәрсәләр белән мавыккан кешеләр берләшсә, уртак мавыгулары булмаганнары ерагая. Кешеләр җәмгыяте шулай төзелгән. Мәнфәгатьләрегез бердәй булган фикердәшләр һәм дуслар табыгыз, тормышыгыз күпкә күңеллерәк булыр.

Йомгак ясыйбыз

Мәнфәгать — нәрсәгә дә яисә кемгә дә булса аңлы ихтыяҗ. Һәр кешенең төп һәм икенчел кызыксынулары була. Кешенең мәнфәгатьләре күплеге — рухи дөньясының байлыгы, күпкырлылыгы күрсәткече.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Кызыксыну, мәнфәгатьләр иерархиясе

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Мәктәптә өйрәнелә торган фәннәрнең кайсы сездә зур кызыксыну уята һәм ни өчен?

2. Мәнфәгатьләр кеше эшчәнлегендә ничек чагылыш таба?

3. Сезнең төп кызыксынуыгыз нәрсәдә күренә? Аны гамәлгә ашыру өчен сезгә нәрсәне дә булса корбан итәргә туры киләме?

4. Кызыксынуларның күплеге нәрсә ул?

5. Мәнфәгатьләр иерархиясе нәрсә ул?

6*. Ни өчен мәнфәгать кешенең әйләнә-тирә мохиткә актив мөнәсәбәтен чагылдыра?

Практикум

1. Бүгенге мәнфәгатьләрегез иерархиясен төзегез. Тагын ниләр белән кызыксынып идегез?

2*. Инглиз язучысы Льюис Кэрроллның «Алиса Могҗи-залар илендә» дигән әсәрендә Алисаның маҗаралары аның үз яныннан йөгереп узып баручы сәгатьле куян артыннан куа китүе белән башлана. Алиса аның артыннан ихтыяҗ тугангa йөгерәме, әллә кызыксынуданмы?

3*. Мәшһүр психолог Сергей Рубинштейн: «Нәрсә белән булса да кызыксынырга һәм нәрсәдә булса да мәнфәгатьле булырга мөмкин. Болар бер-берсе белән бәйләнгән, шулай да төрле нәрсәләр. Мәнфәгатебез

төшмәгән берәү безгә бик тә кызыклы булырга һәм безгә бөтенләй кызыксыз кешегә теге яисә бу шартларда мәнфәгатебез төшәргә мөмкин».

Бу сүзләрнең хаклыгын расларлык мисаллар китерегез.

§ 4. Кеше үз-үзен һәм башкаларны ничек бәяли

Кеше яшәешенең сере нәрсәдә? Без башка кешеләрне ничек бәялибез? Башка кешеләр безне ничек бәяли? Без үз-үзебезне ничек бәялибез?

Сезгә бер сер ачам: кеше үзеннән үзе генә түгел, ә башка кешеләр һәм үз бәяләмәләрендә яши. Мәсәлән, сыйныфташларыбыздан еш кына: «Нинди яхшы, гадел кеше», — яисә, киресенчә, «Саран, ялганчы», — дигән гыйбарәләр ишетәбез. Мәктәп балаларының яшьтәшләренә бирә торган бәяләмәләре нәкъ менә шушы сүзләр белән белдерелә. Башка бер хәлне алыйк. Сез өегездә утырасыз һәм узган көнгә йомгак ясап фикер йөртәсез: мин теге яки бу очракта ничегрәк эш йөрттем, гадел булдыммы яисә кемне дә булса алдамадыммы. Бу мисал кешенең үз эш-гамәлләренә бәя бирүен чагылдыра.

Без башка кешеләрне ничек бәялибез

Чынлыкта хайваннар да башка хайваннар бәяләмәсеннән бәйсез яши алмый. Буйвол бозавы көтү артыннан теркелде, ә куаклыкта посып утыручы арысланнар инде күптән булачак әбәтләрен күзәтеп һәм бәяләп утыралар: нинди тизлектә чаба, авыру түгелме, бозауны яклашырга дип килүләре мөмкин булган зур хайваннар еракмы. Корбан үзе дә, хәл-торышны тулысынча бәяләмичә торып, бер адым да атламый.

Кешеләрдә бәя бирү автомат рәвештә башкарыла һәм, хайваннардан аермалы буларак, күп гамәлне үз эченә ала. Хәтта сулы стаканны өстәлгә куяр өчен генә дә сез бик күп нәрсәләрне уегызда үлчәргә тиеш: суын түкмәс өчен стаканны ничегрәк тотарга; су кайнармы яисә салкынмы; өстәлгә

кадәр ара еракмы; мине олылар күзәтәме, мин үземне ничегрәк тотам һ.б.

Кеше озаграк яшәгән саен, аңа күбрәк нәрсәләрне бәяләргә туры килә. Кешенең шөгыле катлаулырак булган саен, аның бәяләү процессы да киңрәк һәм катлаулырак була.

Без һәрвакыт үз-үзебезгә һәм башка кешеләргә бәя бирәбез

Шул рәвешчә, җәмгыятьтәге тормышыбыз миллионлаган бәяләмәләр белән чуарланган — сез үзегезне һәм башка кешеләрне бәялисез, башкалар сезгә бәя бирә һәм шулар нигезендә сезнең белән мөнәсәбәтләрен кора. Мәсәлән, әгәр сезгә «сер тотмас, бытбылдык» дигән бәя бирелсә, сезнең белән берәүнең дә эч серен бүлешмәячәген белеп торыгыз.

Үз-үзеңә бәя бирү

Сезнең кайчан да булса сыйныфташларыгыз, бер йортта яшәгән яшьтәшләрегез яисә танышларыгыз алдында мактанганыгыз булдымы? Үзегезнең үзенчәлекле һәм бик сәләтле булуыгызны, башкаларның кулыннан килмәгән теге яисә бу эшләрне булдыра алуыгызны сөйләгәнегез бармы?

Бу — сезнең үзегезне бәяләвегез. Әмма ул — арттырылган бәя. Борчылмагыз — кешеләрнең күпчелеге өчен хас сыйфат бу. Гәрчә бик үзенчәлекле дип уйласагыз да, сез, баксаң, башкаларга охшаган икән.

Үз-үзеңне бәяләү төрле була. Кайберәүләр үзләрен бөек галим дип ышана, ә чынлыкта гыйлем дәрәҗәсендә бик сай йөзә. Бу — үз-үзеңә арттырып бәя кую. Кайберәүләр үзләрен чынбарлыктагыдан түбәнрәк бәялиләр. Бу исә — киметелгән бәяләмә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Үз-үзеңә бәя бирү — кешенең үзен-үзе, үз мөмкинлекләрен, сәләтләрен, сыйфатларын һәм башка кешеләр арасында тоткан урынын бәяләве; кешенең үз-үзеннән алган тәэсире яисә үзе турындагы фикере.

Сәләт — кешенең нәрсә булса да эшли белүендә, нинди дә булса шөгыльгә яисә һөнәргә хирыслыгында чагылыш тапкан шәхси үзенчәлеге.

Өстәмә уку

Кешеләр төрле-төрле, берсе икенчесенә тәңгәл килгән кеше юк. Һәр кешегә билгеле бер сәләт бирелә, әмма бар кеше дә талантка һәм даһилыкка ия була дип әйтә алмыйбыз.

Үзегезнең *сәләтлеме* икәнегезне ничек ачыкларга? Сәләтлелек сезнең, әйтик, математика, музыка яисә башка өлкәләрдәге конкрет биремнәрне ничек тиз һәм уңышлы үтәвегез белән үлчәнә. Сәләтлелек нәрсә белән булса да, скрипкада уйнауны, коллекция туплауны, бик көчле мавыгуда чагыла.

Яңалыгы, камиллеге һәм иҗтимагый әһәмияткә ия булуы белән аерылып торганниләр булса да иҗат итәргә мөмкинлек бирә торган сәләтләр җыелмасы *талант* дип атала. *Даһилык* — талант үсешенең иң югары баскычы. Бар кешелек өчен әһәмиятле берәр нәрсә иҗат иткән кешене даһи дип атыйлар.

Сез, мөгаен, бөтенләй сәләтсез кеше түгелсездер. Үзегезгә игътибар итегез: сезнең нинди сәләтләрегез бар? Дусларыгызның нинди сәләтләре бар?

Әгәр хөрмәткә лаек нәрсәләрегез булса (сәләтләрегез, уңышларыгыз һ.б.), сез үзегезне ихтирам итәсез. Һәм бу **үз-**

үзеңне хөрмәт итү дип атала. Әгәр мактарлыгы булмаса, кеше, киресенчә, үз-үзендә бик күп кимчелекләр таба һәм үз-үзен битәрли. Бу — **үз-үзеңне кимсетү, түбәнсетү.**

Спорттагы уңышлар үз-үзеңә бәя бирүгә ничек йогынты ясарга мөмкин?

Кызыклы фактлар

Бер тикшеренү вакытында яшьләренә карап өч төркемгә бүленгән 400 гә якын кыз һәм малай арасында сораштыру уздырыла. Төркемнәрдә уртача 13, 15 һәм 17 яшьлек балалар тупланган була. Өч төркемдә дә кызларның үз-үзләрен бәяләве яшьтәш малайларыныкына караганда югарырак булып чыга. Моны кызларның малайларга караганда физик һәм иҗтимагый яктан иртәрәк җитлегүе белән аңлатырга мөмкин.

Үз-үзеңне бәяләгәндә тәнкыйть күзлегеннән карарга кирәк. Бу үз-үзеңне һичшиксез тәнкыйтьләргә һәм һәрвакыт һәрнәрсәдә җитешсезлекләр эзләргә кирәк дигән сүз түгел. Башка кешеләр белән чагыштырып үз-үзеңә бәя биргәндә, объектив (дөрес) һәм тәнкыйди карарга кирәк. Үз-үзеңне бәяләү — башка кешеләр белән чагыштырганда үзеңә бәя бирү ул, дип юкка гына әйтмиләр.

Үзеңнең көчле якларыңны күрә һәм аларга хөрмәт белән карый белергә, үз тормышыңда аларны файдаланырга — булганнарын үстерергә, яңаларын булдырырга кирәк. Әгәр шәхесегезнең кайсы да булса яклары сезгә яшәргә комачауласа, үзеңне камилләштерергә тырышырга кирәк. Бу **үз-үзеңне тәрбияләү** дип атала. Ул әйләнә-тирәдәге кешеләр белән дөрес мөнәсәбәтләр корырга булышачак.

Үсмернең үз-үзен бәяләве формалашуында яшьтәшләренең, укытучыларының һәм ата-аналарының аңа мөнәсәбәте нинди булуы зур әһәмияткә ия.

Игелек һәм явызлык турындагы күзаллаулар кешенең үз-үзен һәм башкаларны бәяләвенә ничек йогынты ясый

Олыгайган саен, кеше үз гамәлләренә **әхлак** ягыннан чыгып бәя бирә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Әхлак — игелек һәм явызлык турындагы күзаллауларга нигезләнгән, җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар.

Әхлакый нормалар булмаса, без бары кешеләр фикеренә генә бәйле булыр идек. Ә алар — һәр кешенең үзенеке. Әмма игелек һәм явызлык, намус һәм абруй турындагы әхлакый нормалар һәркем өчен уртак. Шуларга таянырга кирәк.

Әйтик, дустыгыз сезгә аны кешеләр алдында «сатлыкҗан» дип атавыгыз өчен ачуланды ди. Сезнең болай эшләвегезнең үз сәбәпләре бар иде: сез дустыгызның гамәлләрен намус һәм гаделлек нормалары белән үлчәп карагач, аларның бозылганлыгын күрдегез. Әмма иптәшегез барысын да башкачарак бәяли: сезнең кешеләр алдында әйткән сүзләрегезне хыянәт дип санап, үз гамәлен вак шаяру дип кенә күрсәтә. Кемгә ышанырга һәм нәрсәләргә таянырга соң? Әлбәттә, әхлак нормаларына! Ә алар «урлашма», «алдашма», «җан кыйма», «үзеңә нинди мөнәсәбәттә булуларын теләсәң, кешеләргә дә шундый мөнәсәбәттә бул» дип өйрәтә һ.б.

Йомгак ясыйбыз

Кеше башка кешеләр бәяләмәләрендә һәм үз бәяләмәсендә яши. Үз-үзеңә бәя тәнкыйть күзлегеннән чыгып бирелергә тиеш.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Үз-үзеңне бәяләү, сәләтләр, әхлак

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Кеше башка кешеләр бәяләмәсендә яши» дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

2. «Үз-үзеңә бәя бирү» дигән төшенчәнең мәгънәсен аңлатып бирегез. Ул нинди була? Җавап биргәндә, түбәндәге схемадан файдаланыгыз:

3. Үсмернең үз-үзенә арттырылган һәм киметелгән бәя бирүе нидән тора?

4. Үзеңә башка кешеләр белән чагыштырып бәя биргәндә ни өчен үз-үзеңә тәнкыйди һәм объектив карашта булу бик мөһим?

5*. Әхлакый нормалар, игелек һәм явызлык турындагы күзаллаулар безнең башка кешеләрне бәяләвебезгә ничек йогынты ясый?

Практикум

1. Күп кенә галимнәр нинди дә булса эштә уңышка ирешү өчен үз-үзеңә арттырып бәя бирү киметеп бирүгә караганда яхшырак дип саный. Сез ничек уйлыйсыз? Үз карашыгызны дәлилләгез.

2*. Антоний Погорельскийның «Кара тавык, яисә Җир астында яшәүчеләр» дигән әкиятен яңадан укып чыгыгыз. Әкиятнең төп герое — Алёша — могҗизалы көчкә ия булганчы һәм аннан соң үз-үзен ничек бәяли? Аны башка кешеләр ничек бәяли? Ни өчен Алёшаның үз-үзен бәяләве һәм аңа башка кешеләр биргән бәяләмә үзгәрә?

§ 5. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм аерым ихтыяҗлары булган кешеләр

Кешеләр ни өчен инвалид була? Алар нинди ярдәмгә мохтаҗ? Мөмкинлекләре чикле кешеләр нәрсәләргә ирешә ала?

Инвалидлар

Мөмкинлекләре чикле кешеләр — **инвалидлар** булмаган җир юк. Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) Җир йөзендәге һәр ун кешенең берсе инвалид дип белдерә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Инвалид (мөмкинлекләре чикләнгән яисә аерым ихтыяҗлары булган кеше) — физик яисә акыл ягыннан, психик тайпылышлары аркасында мөмкинлекләре чикле кеше.

Инвалидлар — умыртка сөяге зарарланган, аяк-куллары киселгән, церебраль параличлы, склероз белән авыручы, күзләре күрми, колаклары ишетми торган, психик авырулы һ.б. кешеләр.

Шундый булып туууында яисә шулай булуында кешенең гаебе юк. Һәрвакыт эшли һәм үзен-үзе тәэмин итә алмавында ул гаепле түгел. Инвалидларның тормыш рәвеше — көн саен организмнарының тормыш эшчәнлеген туктатмаска мөмкинлек бирүче, әмма авырулардан дәвалый алмый торган дарулар эчүдән гыйбарәт.

Инвалидлык сәбәпләре

Инвалидлык — һәрвакытта да тумыштан, нәселдән булмый. Бик еш кына моңа очраклылык сәбәпче: яңа гына сугыш булып узган илләрдә кешеләр җирдә шартламыйча калган миналардан зыян күрә. Производствода куркынычсызлык техникасын үтәмәү травмалар алуга китерә. Кешеләрнең егылып аякларын сындыру очраклары да сирәк түгел.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Инвалидлык — нинди дә булса эшчәнлекне кеше өчен нормаль саналган дәрәҗәдә башкару сәләтенең чикле булуы яисә бөтенләй булмавы.

Кызыклы фактлар

Халыкара сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр көне һәр елны 3 декабрьдә билгеләп үтелә.

Гәрчә үзенчәлекләре булса да, инвалидлар башка кешеләр кебек үк. Ә үзенчәлекләр кемдә юк ди ул?! Мөмкинлекләре чикле кешеләр гади кешеләр белән бергә укырга һәм эшләргә тиеш. Алар аңлауга һәм башкалар белән бертигез хокукларга мохтаҗ.

Мөмкинлекләре чикле кешеләр көндәлек тормышта нинди кыенлыкларга очрый? Аларны җиңәргә нәрсә ярдәм итә?

Мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм

Без сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм итәргә тиеш.

Дәүләт, булдыра алганча, инвалидларга булышлык күрсәтә. Мәсәлән, кайбер шәһәрләрдә яшел-сары төстәге «билбаулы» махсус автобуслар 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларны йөртә. Дәүләт инвалидларга медицина ярдәме күрсәтә. Илнең барлык төбәкләрендә мәктәпкә йөреп укый алмый торган балаларны өйдә укытуны тәэмин итәргә тырышалар.

Россиядә инвалид балаларны укыту өчен махсус программалар эшләнә

Безнең илдә инвалидлар эшли торган, югары сыйфатлы продукция чыгаручы предприятиеләр аз түгел.

Өстәмә уку

Тумыштан сукырлар беркайчан да агачка килеп бәрелми, тротуардан егылып төшми. Ә кинәттән күрү сәләтен югалткан кешеләр еллар буена өйдә ябылып ята, урамга туганнары ярдәме белән генә чыга ала. Аларга икмәк сатып алу, юл аркылы чыгу авыр — тавышлы светофорлар сирәк күренеш әле.

Мәктәпләрдә һәм махсус курсларда алган белеме бер әзерлек сукыр инвалидларга шактый иркен һәм мөстәкыйль рәвештә кирәк урыннарына

бару, җәмәгать транспортында йөрү, кибетләрдә әйберләр сатып алу, көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү һәм, гомумән, калган кешеләрдән берни белән дә аерылып тормау мөмкинлеге бирә. Дөньяда әйләнә-тирәдәгеләрдән бәйсез булырга ярдәм итүче җайланмалар — кәгазь акчаларны тану, стаканда күпме су барлыгын билгеләү аппаратлары, бәрелмиегылмый йөрергә мөмкинлек бирә торган мини-компьютерлар бар. Моннан тыш, махсус әзерлек узганнан һәм күнекмәләр алганнан соң, кеше кул таягы яисә махсус өйрәтелгән эт ярдәмендә урамда йөри ала.

?

Көндәлек тормышта инвалидлар нинди кыенлыкларга юлыга? Аларны җиңәргә нинди җайланмалар ярдәм итә? Күзләре күрмәү сәбәпле инвалид кешеләргә сез ничек ярдәм итә аласыз?

Рәсми мәгълүматларга караганда, Россиядә 10 млн тирәсе мөмкинлекләре чикле кеше яши. Бер үк вакытта сукыр да, чукрак та булган балаларның саны Россиядә 12 меңгә якын. Сукырлар мәктәпләрендә белем алучы балаларның 80 проценты тумыштан инвалид, 1 процент тирәсе — бәхетсезлеккә очрап күрү сәләтен югалткан, ә калганнары — күзләре начар күрүче балалар.

Күренекле казанышлар

Инвалидларның гади кешеләр сәләтле булмаган гаять күренекле казанышларга ирешә алуына бик күп мисаллар китереп булыр иде.

Бөек композитор Людвиг ван Бетховен үзе генә дә ни тора! Иҗаты чәчәк аткан чорда ул ишетү сәләтен югалта, һәм, үтә зур кыенлыклар кичереп, зур көч һәм тырышлык куеп, бөек симфонияләр яза.

Сукырайган Николай Островский үзенең «Корыч ничек чыныкты?» дигән романында зур батырлык турында яза һәм кешеләрне кыенлыклар алдында тез чүкмәскә өнди.



А.П.Маресьев

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында очучы Алексей Маресьев каты яралана, шуның нәтиҗәсендә аның ике аягын тез тиңентен кисәләр. Инвалид булуына карамастан, ул үз полкына әйләнеп кайта һәм, ясалма аяклар (протезлар) куйдырып, яңадан оча башлый. Яраланганчы дүрт немец очкычын, ә кабат сафка баскач, тагын җидесен бәреп төшерә.

Россиянең паралимпия спорт төрләре буенча җыелма командасы төп олимпия командасына караганда һәрчак уңышлырак чыгыш ясый. (Паралимпиада — инвалидлар өчен спорт ярышлары — төп Олимпия уеннарыннан соң уздырыла.)

Мөмкинлекләре чикле кешеләрнең казанышлары сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?

Мөгаен, инвалидлар ирешкән гаять зур казанышларның сәбәбе — аларның гадәттән тыш зур көч, тырышлык куюларындадыр. Аларга бераз ярдәм итәргә генә кирәк.

Аздан башлагыз — аларга елмаегыз, исәнләшегез яисә юл аша чыгарга булышыгыз.

Кызыклы фактлар

Бөек Новгородта 30 ел диярлек «Жест» дигән уникаль театр эшли. Анда ишетмәү нәтиҗәсендә инвалидлар һәм коляскалы инвалидлар уйный. Гадәти булмаган труппа составына актерларны 7 яшьтән һәм шуннан өлкәнрәкләрен җыялар. Тиңе булмаган бу театр күп тапкырлар халыкара, бөтенроссия һәм төбәк фестивальләрендә җиңү яулый, берничә абруйлы премиягә лаек була.

Йомгак ясыйбыз

Инвалидлык һәрвакыт нәселдән яисә тумыштан килми. Кешенең көндәлек гамәлләре һәм хезмәт эшчәнлеге инвалидлыкка китерергә мөмкин. Көндәлек тормышыбызда мөмкинлекләре чикле кешеләр проблемаларына игътибарлы булу гаять мөһим.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Инвалид, инвалидлык

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Инвалид», «инвалидлык» сүзләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Инвалидлыкка китерә торган сәбәпләрне атагыз.

3. Әгәр инвалидлар мөмкинлекләре чикле кешеләр икән, алар ничек олимпия рекордлары куя?

4. Әгәр сез дәүләт җитәкчесе булсагыз, мөмкинлекләре чикле кешеләрнең тормышын яхшырту өчен нинди чаралар тәкъдим итәр идегез?

Практикум

1. 2009 елда «Большой город» («Зур шәһәр») журналы оештырган акция вакытында коляскалы инвалидлар һәм инвалид коляскасына утырган сәламәт кешеләр (шул исәптән берничә атаклы кеше) «Кутузов» метро станциясеннән «Киев» метро станциясенә чаклы юл уздылар. Алар гадәти эшләр башкарырга — кибеткә, даруханәгә керергә, кафеда утырырга тырыштылар. Бу акция Мәскәү шәһәренең әлеге районы инвалидларга яшәү өчен уңайлымы икәнен ачыклау өчен уздырылды. Бу эш ничек башкарылган һәм моннан ни килеп чыкканлыгын сезгә үзлегегездән ачыкларга һәм телдән кыска гына мәгълүмат әзерләргә кирәк булачак. Моның өчен Интернеттан файдаланыгыз.

2. Тирә-юнь йортларны һәм урамнарны әйләнеп чыгыгыз — аларда нәрсә инвалидлар өчен җайлаштырылган, ә нәрсәләр — юк. Җайлаштырылмаган урыннарны сез ничек үзгәртеп корыр идегез? Үз тәкъдимнәрегезне әйтегез.

3. Сезнең тирәгездә мөмкинлекләре чикле кешеләр бармы? Аларның тормышы турында сез ниләр сөйли аласыз? Шәхсән үзегез мөмкинлекләре чикле кешеләргә ниндирәк ярдәм күрсәтә алыр идегез?

4*. Тормышта зур уңышларга ирешү өчен инвалидлык комачауламаган замандашларыбыз турында мәгълүмат туплагыз. Компьютерда презентация әзерләгез.

5*. Безнең илдә инвалидларга нинди ярдәм күрсәтәләр? Ә чит илләрдә? Дәрескә әзерләнгәндә, газета һәм журналлар, Интернет материалларыннан файдаланыгыз.

§ 6. Эшчәнлек

Кешенең асылы барыннан да бигрәк нәрсәдә ачыла? Эшчәнлек нәрсәдән тора? Эшчәнлек нинди була?

Үз гомере дәвамында кеше һәрвакыт нинди дә булса эшчәнлек белән шөгыльләнә. Кешенең асылы нәкъ менә

эшчәнлек вакытында тулырак ачыла. Эшчәнлектә аның белем туплауга сәләтлелек дәрәҗәсе, таланты һәм сәләтләре, ихтыяҗлары, ихтыяр көче, темпераменты, максат куя һәм карар кабул итә белүе ачык чагыла.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Интеллект — белем туплауга һәм проблемалар чишүгә сәләтлелек.

Ихтыяр — сайлап алуга һәм гамәл кылуга сәләтлелек.

Интеллект кешенең яшенә, белеменә, индивидуаль үзенчәлекләренә бәйләнгән. Теләсә нинди проблемада төп якларны аерып алып, аны анализлау һәм хәл итү ысулларын таба алган кеше интеллектлы була. Ихтыяр көче югары булган кеше мөстәкыйль, катгый карарлар кабул итә, үз максатларына ирешүдә таләпчән була.

Күрәсезме, **эшчәнлек** дигән төшенчә күпме нәрсәне берләштерә икән.

Эшчәнлекнең этәргечләре һәм максатлары

Кеше болай гына бернәрсә дә эшләми. Аның үз-үзен тотышы һәм гамәлләре билгеле бер этәргечләргә нигезләнә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Этәргечләр — кешенең үз-үзен тотышы һәм аның гамәлләре сәбәпләре. Этәргечләр ихтыяҗлар һәм кызыксынулар йогынтысында барлыкка килә.

Белем алу һәм үзе сайлаган өлкәдә яхшы белгеч булып җитешү теләге кеше өчен институтка керүгә этәргеч булып тора. Моның өчен мәктәптә өйрәтелә торган фәннәрне яхшы белү, тиешле документлар булу шарт.

Эшчәнлек нәрсә соң ул? Әйтик, сез сыйныфыгыз белән экскурсиягә барасыз, дәресләрдә укытучы сорауларына җавап бирәсез, өй эшен эшләргә тотынасыз — болар барысы да **гамәл**, ә уку яисә өйрәнү — **эшчәнлек**.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Эшчәнлек — озак вакыт дәвамында башкарылган һәм конкрет максатны күздә тоткан гамәлләрнең (акыл яисә физик яктан) эзлеклелеге. Эшчәнлек үҗәтлек, максатчанлык, даими тырышлык таләп итә.

Кызыклы фактлар

Галимнәр эксперементлар кую юлы белән мәгънәсез гамәлләргә кайчак файдалы һәм кирәкле гамәлләргә сарыф ителгән кадәр көч һәм энергия китүен дәлилләделәр.

Эшчәнлекнең *максаты* була. Әйтик, кеше автомобиль сатып алырга дигән максат куя. Аңа ирешү өчен, акча җыярга, медицина тикшерүе узарга, төрле белешмәләр, машина йөртү хокукы бирә торган таныклык алырга, аннары бәяләре һәм машина маркалары яраклы кибет табарга кирәк. *Гамәл* — эшчәнлекнең кыска гына фрагменты — кибеткә кереп автомобиль алу. Эшчәнлек ул — уку, төрле кешеләр белән аралашу, күпьеллар дәвамында, әйтик, банкта, заводта, офиста эшләү, аның өчен хезмәт хакы түләнә.

Эшчәнлекнең төрләре

Кешеләр эшчәнлеге күптөрле, шулай да эшчәнлекнең төп төрләре булып **уку, уен** һәм **хезмәт, иҗат, аралашу** тора.

Уку — яңа белемнәр туплау, яңа күнекмәләр алу. Мәсәлән, уку процессында сез эшчәнлекнең нәрсә икәнен белдегез, ә хәзер аның нинди төрләре булуын билгеләү күнекмәсе аласыз. Тагын әле рәсем ясарга, йөзәргә, музыка уен коралында уйнарга өйрәнергә мөмкин.

Уен — чынбарлыктагы эшчәнлеккә охшатып гамәл кылу. Бала чакта, мөгаен, өлкәннәр тормышын өлге итеп алып, сез әни һәм кыз, хастаханә, кибет һ.б. шундый уеннар уйнагансыздыр. Моннан тыш спорт, компьютер уеннары шулай ук уен дип атала.

Хезмәт эшчәнлеге барышында кеше төрле файдалы нәрсәләр булдыра (йортлар төзи, автомобильләр җыя) яисә

төрле файдалы хезмәтләр (мәсәлән, туристлык, медицина, көнкүреш белән бәйле) күрсәтә.

Иҗат эшчәнлеге процессында һичшиксез берәр яңа нәрсә туа. Мәсәлән, тәгәрмәч, автомобиль уйлап табу, музыка иҗат итү, китап язу һ.б. *Аралашу* барышында мәгълүмат, идеяләр, хис-тойгылар алмашу бара.

Эшчәнлекнең мондый төрлелеге җәмгыятьнең мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бәйле. Ихтыяҗ тумаса, эшчәнлек тә барлыкка килми. Җылы киез итекләр һәм аларны басучы осталар, әйтик, Африкада кемгә хаҗәт? Анда ел әйләнәсе кояш кыздыра. Ә Россиядә исә бу товарга ихтыяҗ зур.



❓ Фотосурәтләрдә эшчәнлекнең кайсы төрләре күрсәтелгән? Алар нинди ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә юнәлтелгән?

Эшчәнлекнең нәтиҗәсе

Берәр файдалы нәрсә булдыру яисә хезмәт күрсәтү, әйтик, синең яраткан футбол командаң җиңү яуласа, шатлык хисләре кичерү, яисә, киресенчә, командаң җиңелсә, кайгыру — болар барысы да эшчәнлек *нәтиҗәсе*.

Нәтиҗәне һәрчак күз белән күреп булмаска да мөмкин. Мәсәлән, **акыл эшчәнлеге** вакытында ул башка теләсә нинди эшчәнлек алдыннан башкарыла. Акыл эшчәнлеге башка барлык эшчәнлек төрләре өчен нигез булып тора, чөнки кеше

башта уйлый, аннары эшли. Мәктәптә укыганда да, олы тормышка аяк баскач та бу кагыйдәгә таяну мөһим.

Эшчәнлек структурасын күз алдына китерсәк, ул максаттан, ихтыяҗлардан, этәргечләрдән, чаралардан, гамәлләр җыелмасыннан, нәтиҗәдән тора.

«Эшчәнлек структурасы» схемасы

Эшчәнлек һәм шәхес

Эшчәнлектә кеше үзе ачылып кына калмый, бәлки аның шәхесе чагылыш таба. **Шәхес** нәрсә дигән сүз ул?

> **Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!**
>
> **Шәхес** — үз гамәлләре өчен үзе җавап бирергә сәләтле, аңлы эшчәнлеккә әзер булган мөстәкыйль кеше.

«Шәхес» сүзе аңлы хезмәткә әзер кешегә карата кулланыла. Без «сабый шәхесе» дип сөйләмибез. Ике яшьлек баланың шәхесе турында да җитди сүз алып бармыйбыз. Шәхес булып тумыйлар. Шәхес булып җитешәләр. Бала үзе аңлы гамәлләр кыла башлагач кына шәхескә әйләнә. Баштарак олылар ярдәме кирәк булачак, әлбәттә.

Шәхес булу — кеше иҗтиһатының иң югары казанышы, аның үз өстендә эшләве нәтиҗәсе. Мөстәкыйльлек, актив-

лык, инициатива күрсәтү, үз гамәлләрең өчен җавап бирү, тәртибеңне контрольдә тоту сәләте. Болар сездә бармы?

Шәхес булу активлыкта һәм инициативалылыкта чагылыш таба

Игелек һәм явызлык турында катгый күзаллаулары булганда гына кеше шәхес булып җитешә ала. Якыннарыңны эчкерсез ярату кеше шәхесенең нигезен тәшкил итә, аның формалашуы җәмгыятьтә һәм гаиләдә башлана.

Шәхес көнкүрештә үз-үзен **тотышы** аша, конкрет **эшгамәлләрдә** ачыла.

Кешенең үз-үзен тотышы

Кешенең үз-үзен тотышы дигәндә без нәрсәне күздә тотабыз? Ул эшчәнлектән нәрсә белән аерыла? Мәктәп укучылары өчен бу аеруча мөһим. Укытучылар сезнең үзегезне генә түгел, тәртибегезне — үз-үзегезне тотышыгызны да бәялиләр.

> **Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!**
>
> **Кешенең үз-үзен тотышы** — аның билгеле бер максатка юнәлтелгән һәм әхлак (игелек һәм явызлык) күзлегеннән чыгып бәяләнә торган гамәлләре җыелмасы.

Кешенең үз-үзен тотышыннан аермалы буларак, эшчәнлек эчке (акыл эшчәнлеге) һәм тышкы булырга

мөмкин. Сез, эчтән генә мәсьәләне чишү юлларын уйлаганнан соң, өстәл артына утырасыз һәм чишелешне язып куясыз.

Кешенең үз-үзен тотышы гамәлләрдән тора.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гамәл — кешенең үзен шәхес буларак таныткан аңлы эше.

Гамәленең нинди булуы кешенең үз-үзен тотуын әхлакый яктан үлчәргә мөмкинлек бирә. Кешенең һәр эше гамәл була алмый. Яшь кеше бик арыган, һәм ул автобус урындыгында рәхәтләнеп утырып бара. Әлегә бу гади бер эш. Әмма автобуска өлкән яшьтәге ханым керде, һәм егет, арыган булуына карамастан, торып, аңа үз урынын бирә. Менә бу гамәл. Сезнең уегызча, ни өчен бу шулай?

Үзебездән көчсезрәк һәм яклаучысыз, аерым игътибарга һәм кайгыртуга мохтаҗ, мөмкинлекләре чикле кешеләргә карата кылган гамәлләребез аеруча әһәмияткә ия. Без аларның кыенлыкларына битарафмы яисә, ярдәм күрсәтеп, гамәл кылабызмы?

Йомгак ясыйбыз

Кеше үз эшчәнлегенә аша ачыла. Теләсә нинди эшчәнлекнең максатлары, этәргечләре — кешенең үз-үзен тотышы һәм эш-гамәл кылуы сәбәпләре, нәтиҗәсе була. Кеше эшчәнлеге гаять күптөрле.

Акыл эшчәнлеге эшчәнлекнең башка төрләре өчен нигез була.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Этәргечләр, эшчәнлек, интеллект, ихтыяр, шәхес, кешенең үз-үзен тотышы, гамәл

Белемегезне сынап карагыз

1. Эшчәнлек этәргечләре ни икәнен аңлатыгыз.
2. Эшчәнлекнең төп төрләрен атагыз. Аларны сурәтләүче конкрет мисаллар китерегез.

3. Мәктәптә укуыгыз нинди көндәлек эшләрдән тора?

4. Эш гамәлдән нәрсәсе белән аерыла? Мисаллар китерегез.

5. Шәхес дигәндә без нәрсәне күздә тотабыз? Эшчәнлектә кешенең шәхесе ничек чагыла?

6. Бүген сезнең өчен эшчәнлекнең нинди төре иң мөһиме? Аның максаты нинди? Бу максатка ирешү өчен сез нинди чаралардан файдаланасыз?

Практикум

1. Николай Некрасовның «Крестьян балалары» дигән шигыреннән өзек укыгыз. Аның персонажлары эшчәнлекнең нинди төрләре белән шөгыльләнә? Аларның этәргечләре нинди?

> ...Домой, ребятишки! обедать пора.
> Вернулись. У каждого полно лукошко.
> А сколько рассказов! Попался косой,
> Поймали ежа, заблудились немножко
> И видели волка... у, страшный какой!..
> — Довольно, Ванюша! гулял ты не мало,
> Пора за работу, родной! —
> Но даже и труд обернётся сначала
> К Ванюше нарядной своей стороной:
> Он видит, как поле отец удобряет,
> Как в рыхлую землю бросает зерно,
> Как поле потом зеленеть начинает,
> Как колос растёт, наливает зерно;
> Готовую жатву подрежут серпами,
> В снопы перевяжут, на ригу свезут,
> Просушат, колотят-колотят цепами,
> На мельнице смелют и хлеб испекут.
> Отведает свежего хлебца ребёнок
> И в поле охотней бежит за отцом...

2*. «Эшнең тискәре нәтиҗәсе — шулай ук нәтиҗә» дигән гыйбарә белән сез килешәсезме? Җавабыгызны нигезләгез.

Танып белү нәрсә ул? Без дөньяны нинди ысуллар белән танып беләбез? Үз-үзеңне танып белергә мөмкинме?

Кешенең эчке дөньясы аның кызыксынуларында һәм ихтыяҗларында, эшчәнлегендә, аның үз-үзен ничегрәк бәяләвендә ачылуын сез беләсез инде.

Кешенең ихтыяҗлары һәм кызыксынулары арасында **танып белү ихтыяҗы** мөһим урын алып тора.

Нәрсә ул танып белү

Кешегә танып белү ихтыяҗы табигатьтән бирелгән. Бу — **белергә омтылу**. Әйләнә-тирә мохитне танып-белү кешеләргә генә түгел, хайваннарга да хас, алар өчен бу гаять мөһим урын тота.

Хайван баласы тәүге адымнарыннан ук әйләнә-тирәне карый, иснәнә, тиеп ала, тыңлана. Биш тойгының бишесе дә (күрү, ишетү, сизү, ис, тәм тою) тормыш өчен мөһим мәгълүмат алу максатында әйләнә-тирә мохитне өйрәнүгә юнәлтелгән.

Тормыш танып белүдән һәм белергә омтылудан башлана.

Тормыш өчен кирәкле **мәгълүмат эзләү** — барлык тереклек ияләренең танып белү асылы шуннан тора. Әмма хайваннар дөньясы гади һәм бик акрын үзгәрә, ә кешеләр дөньясы катлаулы һәм даими үзгәреп тора. Әле йөз ел элек кенә илебездә авыл халкының 85 проценты электр уты, автомобильнең ни икәнен белми иде. Шуңа күрә кеше гоме-

ре буена оешкан танып белү системасына тартыла: балалар бакчасы, мәктәп, көллият яисә университет, күпсанлы белем күтәрү курслары, ниһаять, үзлегеңнән белем алу.

Кеше дөньяны нинди максатларда танып белә? Тормыш өчен кирәкле **белем** туплау өчен.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Танып белү — мәгълүмат алуга, саклауга, эшкәртүгә һәм системалаштыруга юнәлтелгән эшчәнлек.

Белемнәр — танып белү нәтиҗәсе, кеше үзләштергән мәгълүмат.

Әйтик, бер ел дәвамында мәктәптә билгеле бер фәнне өйрәнү — бу танып белү процессы, ә укытучы тикшерә торган үзләштерелгән материаллар җыелмасы — сезнең белемегез.

Белемнәр — танып белү нәтиҗәсе ул. Кеше үзләштергән мәгълүмат кына белем була.

Күренекле француз математигы һәм физигы Анри Пуанкаре фикеренчә, без күбрәк белгән саен, әле без белмәгән нәрсәләр күбәя генә бара. Галим торган саен аннан ерагая барган офыкка таба баручы кешегә охшаган.

Танып белү ысуллары

Кеше дөньяны ничек танып-белә? Ике төп ысулы бар: **тою ярдәмендә** һәм **рациональ.**

Тоеп танып белү биш тою органы ярдәмендә башкарыла (күрү, ишетү, орынып тою, ис һәм тәм тою). Алар ярдәмендә без нинди дә булса яңа нәрсәләр турында мәгълүмат алабыз. Әйтик, сез таныш түгел шәһәргә киләсез һәм беренче эш итеп аның белән танышасыз, фотога төшерәсез, яңа исләр тоясыз, таныш түгел тавышлар ишетәсез, шулай итеп, әлеге шәһәр турында таркау мәгълүматларыгыздан,бербөтен күзаллау оештырырга тырышасыз. Турист шулай эшли.

Рәссамнар, композиторлар, язучылар, артистлар эшчәнлегендә тойгылар аеруча зур урын тота. Болар белән рәттән тагын нинди һөнәр ияләре өчен ул мөһим?

Тоеп танып белү — танып белүнең беренче баскычы. Аның ярдәмендә без күренешләрнең бары тышкы ягын гына өйрәнәбез. Туристны искә төшерик. Аның беренче тәэсирләре шәһәрне тышкы яктан гына ача, чөнки алар — иң өстә ятучы тойгылар.

Икенче баскыч — **рациональ танып белү** — акыл, интеллект, фикерләү эшчәнлеге ярдәмендә әйләнә-тирә дөньяның закончалыклары ачыла.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Фикерләү — кеше танып белүенең иң югары баскычы. Ул чынбарлыкның турыдан-туры тою органнары ярдәмендә мәгълүмат алып булмый торган үзенчәлекләре һәм мөнәсәбәтләре турындагы белем тупларга мөмкинлек бирә.

Моны түбәндәге мисал нигезендә аңлатып бирик.

Турист, шәһәр тормышы белән якыннанрак танышкач, анда халык өчен күп кенә проблемалар булуын ачты. Мәсәлән, ул туристлык маршрутларыннан читтәрәк урнашкан җирләргә барып чыкты, зиннәтле сарайлар янында теләнчеләр утыруын күрде, газеталарда шәһәр проблемалары турында укыды, кешеләр белән сөйләште ди. Менә шул вакытта гына ул шәһәр һәм аның кешеләре турында төгәл күзаллау булдырды.



? Фотосурәтләрдә танып белүнең нинди баскычлары чагылыш таба? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

Танып белү процесслары — хисси һәм рациональ процесслар — бербөтен була, берсе икенчесенә күчә, бер-берсен тулыландыра. Шул рәвешчә сәяхәттән без фотосурәтләр һәм үзебезнең хисләребезне генә түгел, үзебез булган илләрдә яшәүче кешеләрнең язмышы турындагы уй-фикерләребезне дә алып кайтабыз. Экскурсияләр вакытында шәһәрнең тарихы, сәнгате, мәдәни казанышлары турында сөйләгән гидтан без күп мәгълүмат алабыз. Сиздермичә генә болар барысы да — тойгылар һәм рациональлек — күргәннәребез турында тулаем тәэссоратка әйләнә.

Әмма кеше әйләнә-тирә мохитне генә түгел, үз-үзен дә танып белә. Бу процесс кешенең **үз-үзен танып белүе** дип атала.

Үз-үзен танып белүе кешенең үз-үзен бәяләве белән бәйләнгән. Үзенә бәя биргәндә, үсмер үзе турында хак (үзенә тәнкыйть күзлегеннән карап, үз-үзен рациональ анализлап) яисә ялган (үзендә булмаган яхшы сыйфатларны өстәп, хискә бирелеп) белемнәр алырга мөмкин. Үзеңне үзең белән чагыштыру — кичә, бер ай, бер ел элек нинди булуыгыз белән бүгенге үзегезне янәшә куеп карау бик мөһим. Бу вакыт эчендә сез ниләр белдегез, нәрсәләргә өйрәндегез? Үзегезгә мондый сорауларны ешрак бирегез һәм аларга җавап эзләргә иренмәгез. Китаплар укыгыз, музейларга йөрегез, спорт секцияләренә яисә кызыксынуларыгыз юнәлешендә түгәрәкләргә язылыгыз. Болар сезгә үз-үзегезне танып-белү эшендә җитди уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Йомгак ясыйбыз

Танып белү ихтыяҗы кешенең табигатендә. Тойгы һәм рациональ танып белүләр берсе икенчесен тулыландыра. Танып белү нәтиҗәсендә белем туплана, ә кешенең үз-үзен танып белүе нәтиҗәсендә аның яхшыга үзгәрүенә ирешелә.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Танып белү, белем, фикерләү, кешенең үз-үзен танып белүе

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Танып белү җәмгыять тормышында нинди роль уйный? Бер генә минутка танып белү юкка чыкты дип күз алдына китерегез. Кешеләр тормышында ниләр үзгәрер иде?

2. Схемадан файдаланып, кешенең дөньяны һәм үзүзен ничек танып белүе турында сөйләгез.



3. «Белем», «танып белү», «фикерләү» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

4. Танып белү үз-үзеңне танып белүдән нәрсә белән аерыла?

5*. Яңа белемнәр ачу белән яңа мәгълүмат эзләү арасында нинди аерма бар?

6*. Француз физигы Анри Пуанкареның, без күбрәк белгән саен, әлегә без белмәгән күренешләрнең торган саен күбәя баруы турындагы сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?

Практикум

1. Инглиз язучысы Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо» романы яисә бу китап нигезендә төшерелгән фильмнар белән сез таныштыр, мөгаен. Сез ничек уйлыйсыз, төп герой тормышында танып белү һәм белемнәр нинди роль уйнаган?

2*. «Үз-үзен танып белүе кешене яхшырак итәме?» дигән темага фикер алышуга әзерләнегез.

8. Белем алу һәм үзлегеңнән белем алу

Белем алу нигә кирәк? Укытучыларсыз гына белем алып буламы?

Кешенең **белем алуы** һәм аның **үзлегеннән белем алуы** нигезендә тойгылар һәм рациональ танып белү ята.

Белем алу һәм үзлегеңнән белем алу

Галим бала вакытында мәктәптә системалы белем ала, ә аннары үзенең һөнәри эшчәнлегенә — танып белү һәм яңа белем туплауга керешә.

Үзенең төп эшен — укучыларга белем бирү эшен башкаручы укытучы белем туплауның бөтен баскычларын узган, һәм, профессиональ укытучы булып җитешкәч тә, танып белүен һаман дәвам итә. Ә укучылар үзләре? Сез укытучы җитәкчелегендә белем аласыз һәм шулай ук танып белү белән шөгыльләнәсез.

Мәктәпләрдә укытучы җитәкчелегендә белем алалар

Танып белү процессы берничә юл белән бара: укытучы, ата-аналар җитәкчелегендә, шулай ук укучыларның мөстәкыйль эше аша.

Өстәмә уку

Мәктәпләр Борынгы заманда ук барлыкка килгән. Кабиләләр чорында балаларга белем бирү телдән һәм күрсәтмә мисаллар ярдәмендә алып барылган. Чын мәктәпләр кешеләр язу уйлап тапкач пәйда була. Беренче мәктәпләр Борынгы Мисырда барлыкка килә. Бу кучереп язучылар мәктәпләре була.

Мисыр патшалыгыннан безнең көннәргә кадәр папируска төшерелгән язма — улын шундый мәктәпкә биргән атаның нәсыйхәте сакланган. Ул «Ахтой улы Дуауның улы Пиопига үгет-нәсыйхәте» дип атала. Язманың авторы үз улын мәктәпкә язарга өйрәнсен, түрә булсын һәм сарай аксөякләре улларыннан калышмасын өчен бирүен бәян итә. Мәктәпләрдә 5 яшьтән 16 яшькәчә малайлар укыган, бирелә бик кырыс дисциплина һәм тән җәзалары хөкем сөргән. Укырга, язарга һәм хисапка, тәртипле булырга өйрәткәннәр. Күчереп язучылар мәктәбе «Баланың колагы аркасында урнашкан, ишетсен өчен, аны кыйнарга кирәк!» дигән девиз буенча яшәгән.

Пиопины мәктәпкә бирүгә нәрсәләр сәбәп булган? Шуларны атагыз. Борынгы Мисыр мәктәбендәге уку-укыту белән хәзерге мәктәптә белем бирүне чагыштырыгыз. Әзерләнгәндә, тарих дәреслегеннән файдаланыгыз.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Белем алу — махсус учреждениедә укытучы җитәкчелегендә уку.

Үзлегеңнән белем алу — кеше тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, билгеле бер уку йортына йөрмичә генә белем алу.

Шулай итеп, белемнәрне мөстәкыйль туплау һәм эшкәртү — мәҗбүри программага кермәгән өстәмә әдәбият уку — мәктәп укучысының үзлегеннән белем алуы була.

Үзлегеңнән белем алуның нинди ысуллары бар? Сез үзлегегездән нинди белемнәр һәм күнекмәләр алдыгыз?

Белем алу белән үзлегеңнән белем алуны **танып белү эшчәнлеге** берләштерә. Ул биредә иң мөһиме. Өйдә яисә мәктәптә укуыгызга карамастан, сез нинди дә булса яңалык ачасыз. Шуннан соң сез моны өйрәнәсез, дәрестә җавап бирәсез, контроль эшләрдә үзләштерелгән материалны тикшерәсез. Димәк, белем алу — яңа белемнәрне үзләштерү һәм ныгыту, ә танып белү — аларны эзләү һәм табу.

Өстәмә уку

Кешеләр өчен космоска очу юлын ачкан күренекле галим Константин Эдуардович Циолковскийга (1857—1935) үсмер чагында кырыс тормыш сынавы узарга туры килә: каты авырудан соң ишетми башлавы нәтиҗәсендә аның белем алуы юлында зур киртә корыла. Ул яшьтәшләре белән нормаль аралаша, башкалар кебек мәктәптә укый алмый. Әлеге бөек кеше үзлегеннән белем ала, ягъни китаплардан яңа белемнәрне мөстәкыйль үзләштерә.

Энциклопедияләр һәм Интернет материалларыннан файдаланып, К.Э.Циолковскийның нинди төп казанышлары булуын ачыклагыз.

Өлкән сыйныф укучылары урта белемне көн саен мәктәпкә йөрмичә дә алырга мөмкин. Әмма имтихан бирү мәҗбүри. Мондый белем алу төре **экстернат** дип атала.

Кешенең үзлегеннән белем алуында уңай һәм тискәре яклар бар. Укытучы җитәкчелеге булмау кешенең барлык фәннәр буенча системалы белемнәре булмауга, кайбер әһәмиятле бүлекләр төшеп калуга, төп төшенчәләрнең үзләштерелмәвенә китерергә мөмкин. Тарих, тел, физика, математика һәм башка фәннәрне мөстәкыйль, укытучы ярдәменнән башка гына төпле итеп үзләштерү үтә кыен. Һичшиксез белем өзеклеге килеп чыгачак, һәм аны киләчәктә тутырып булмаячак.

Константин Эдуардович Циолковскийны мөстәкыйль белем алуга кырыс тормыш шартлары этәрә, әмма фән һәм техника тарихында үзлегеннән укыган һәм зур казанышларга ирешкән башка бөек шәхесләр дә мәгълүм. Болар: Михаил Васильевич Ломоносов, механик-уйлап табучы Иван Петрович Кулибин, электротехник Павел Николаевич Яблочков, авиаконструктор Игорь Иванович Сикорский, инглиз физигы Майкл Фарадей, америкалы уйлап табучы Томас Эдисон... Легендар Трояны (сез аның турында Борынгы заман тарихы дәресләрендә белерсез) ачкан немец археологы Генрих Шлиман да үзлегеннән укыган.

Заман мәктәбе

Хәзерге мәктәп, безгә күп кенә фәннәр буенча белем биреп кенә калмыйча, иҗади фикерләргә дә өйрәтә һәм шәхес тәрбияли.

Белем алуыгыз олыларның эшләве, хезмәт куюы белән тиңдәш. Хәзерге шәһәр мәктәпләре сәнәгать предприятиеләренә охшаган ич. Шәһәрнең төрле почмакларыннан меңнәрчә укучы белем фабрикаларына агыла. Кыңгырау, чылтырап, дәрескә чакыра, чылтырап, аның тәмамлануын белдерә. Борынгы заманда да, Урта гасырларда да мондый нәрсә күзәтелми.

Мәктәптә уңышлар, предприятиедәге кебек үк, нигездә, ахыр нәтиҗәгә карап бәяләнә. Укучы дәрестә ничек җавап бирде, контроль эш әйбәтме, имтихан сорауларын

Хәзерге мәктәптә белем бирү процессына ер-яңа технологияләр: компьютер, интерактив такта, Интернет ярдәмгә килә

яхшы беләме? Укытучы сезнең тырышлыгыгызны, яхшы мәгънәсендә үҗәтлегегезне, ихтыяр көчегезне бәяли.

Мәктәп сезне мөстәкыйль, бәйсез, кыю фикерләргә, үз инануларыгызны дәлилләргә һәм бәхәсләшергә өйрәтә. Иптәшлек, үз-үзеңә тәнкыйди караш, үзеңә һәм башкаларга таләпчәнлек, гаделлек, принципиальлек, затлылык һәм үз дәрәҗәңне белү, өлкәннәргә ихтирам, тәртиплелек һәм җаваплылык тәрбияли.

Күпчелек илләрдә хәзер бала мәктәпкә 6 яшьтән керә. Россия Федерациясендә 11 еллык гомуми белем гамәлдә. Ул **өч баскычтан** тора: башлангыч гомуми белем бирү (1—4 нче сыйныфлар), төп гомуми белем бирү (5—9 нчы сыйныфлар), урта гомуми белем бирү (10—11 нче сыйныфлар). Гомуми белем (11 нче сыйныф) мәҗбүри.

9 нчы сыйныфны тәмамлау турында таныклык алгач, 10—11 нче сыйныфларда белем алуны дәвам итәргә яисә һөнәр алыр өчен көллияткә керергә мөмкин.

Белем эчтәлеген дәүләт мәгариф стандартлары һәм программалары билгели. Алар һәрбер укучының теләсә кайсы белем алу баскычында билгеле бер белем дәрәҗәсенә ирешүен тәэмин итәләр. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, укучыларны төп мәктәпнең бөтен курсы буенча сынау — Дәүләт йомгаклау аттестациясе (ДИА), ә 11 нче сыйныфны тәмамлагач, Бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) көтә. Әгәр сез 10—11 нче сыйныфларда укырга теләмәсәгез, әмма югары уку йортына керергә уйласагыз, сезгә барыбер БДИ тапшырырга һәм моның өчен махсус әзерләнергә туры киләчәк.

Бердәм дәүләт имтиханы йомгаклары югары уку йортына кергәндә исәпкә алына.

Сыйфатлы белем алу аерым бер кеше өчен генә түгел, тулаем бөтен җәмгыять өчен файдалы. Шуның нәтиҗәсендә ил югары квалификацияле белгечләргә ия була. Ә бу исә җитештерү тармагы үсүен, яңа технологияләр кертелүен, илнең үз үсешендә алдынгы сафларга чыгуын аңлата.

Соңгы вакытларда безнең илдә һәм бөтен дөньяда **инклюзив белем** — гадәти балаларның мөмкинлекләре чикле балалар белән бергә укуы үсеш ала. Физик яктан проблемалары булган балалар белән бер сыйныфта укыган сәламәт балалар яхшырак, шәфкатьлерәк, аларга кызгану хисе хас була. Балалар яшьтәшләренең физик кимчелекләрен бик тиз күрми башлыйлар һәм инвалидларны үз уеннарына катнаштыралар.

Йомгак ясыйбыз

Танып белү кешенең белем алуы һәм үзлегеннән белем алуы нигезендә ята. Мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы җитәкчелегендә белем алырга мөмкин. Балаларга белем бирү сыйфатына җәмгыятьнең киләчәк үсеше бәйләнгән.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Белем алу, үзлегеңнән белем алу, инклюзив белем алу

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Кешенең белем алуы» һәм «үзлегеңнән белем алу» дигән төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатыгыз.
2. Яхшы белем кешегә һәм җәмгыятькә ничек файда китерә ала?
3. Өй эшен үтәүне үзлегеңнән белем алу дип санап буламы? Җавабыгызны дәлилләгез.
4. Россиядә белем бирүнең дүрт баскычын атагыз. Сез хәзер кайсы баскычта?
5. Инклюзив белем алу нәрсә ул?

6*. Мәктәптә «тырышыбрак түгел, акыл беләнрәк эшләү» нәрсә дигән сүз?



Практикум

1. Үзлегеннән укыган күренекле шәхесләр — М.В. Ломоносов, И.П. Кулибин, М. Фарадей, Т. Эдисон, П.Н. Яблочков, И.И. Сикорский нинди казанышларга ирешәләр? Энциклопедияләр, белешмәләр һәм Интернет материалларыннан файдаланыгыз.

2. «Яхшы уку, димәк...» дигән темага кыска гына инша языгыз.

§ 9. Социальләшү

Кеше кеше булырга ничек өйрәнә? Без җәмгыятьтә нинди рольләр уйныйбыз? Социальләшүгә сезне кем өйрәтә?

Беренче дәресләрдә үк без сезнең белән кешенең биологик (табигать) һәм социаль (иҗтимагый) зат булуын ачыкла-дык. Соңгысы кешенең башка кешеләр арасында, ягъни җәмгыятьтә яшәве белән бәйле. Анда кешенең үз-үзен тотышы билгеле мәдәни кагыйдәләргә (нормаларга) буйсындырыла. Бөтен гомере буена, сабый чагыннан алып картлыгына кадәр, кеше шуларны үзләштерә. Ягъни **социальләшә**, кешеләр арасында (социумда) яшәргә өйрәнә. Бу ничек бара соң? Иң беренче нәүбәттә **мәдәни нормаларны** үзләштерү аша.

Мәдәни нормалар

Гадәттә, тәрбияле һәм күп белгән кешене *мәдәниятле* диләр.

Мәдәният нәрсә ул? Кеше кулы белән булдырылган бар нәрсә — кием, машиналар, компьютерлар, сәнгать әсәрләре,

заводлар, биналар һ.б. — мәдәният була. Ә кеше тудырмаган нәрсәләр — диңгез-океаннар, агач-үләннәр, елга-күлләр, кошлар, җәнлекләр, таулар — табигатькә карый.

Моннан тыш мәдәният — билгеле бер халыкка хас булган нормалар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр һәм йолалар, кыйммәтләр җыелмасы ул. Итагатьлелек нормалары, ирек сөю һәм ватанпәрвәрлек хисе, өлкәннәргә хөрмәт традицияләре, Яңа ел бәйрәмен каршылау йоласы һәм башка күп кенә нәрсәләр теге яисә бу халыкның мәдәниятен тәшкил итә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Мәдәният — кеше тарафыннан тудырылган бар нәрсә; билгеле бер халыкка хас булган нормалар, кагыйдәләр, традицияләр һәм йолалар.

Мәдәни нормалар — кешенең җәмгыятьтә үзен-үзе тоту кагыйдәләре.

Мәдәният белән таныштыруның сезгә нинди ысуллары мәгълүм?

Мәдәни нормалар бала чакта ук формалаша башлый һәм бөтен гомер дәвамында камилләшә.

Мәсәлән, кешегә аркаң белән түгел, йөзең белән торып гаплəшү — мәдәни норма. Әңгәмәдәшләрне тиешсез сораулар биреп бүлдермәү (игътибарны үзләренә юнәлтү нияте белән балалар еш кына шулай эшли) — шундый ук норма.

Мәдәни нормаларны үзләштерү өчен, көндәлек күнекмәләр, тиешле әдәбият уку, мисаллар кирәк. Болар барысы да **тәрбия** процессында бара. Сезнең беренче тәрбиячеләрегез — әти-әниегез, әби-бабайларыгыз, абыйапаларыгыз.

Тәрбиянең түбән дәрәҗәдә булуын курыкмыйча **культурасызлык** дип атарга мөмкин. Ул төрлечә чагылыш таба: кешеләр сөйләшкәндә килеп тыкшыну, лифт яисә подъезд диварларына сурәтләр төшерү, ят йортта лампочкаларны борып алу, тупаслык, башка кешеләрнең абруен түбәнсетү, ашаганда тыйнаксызлык күрсәтү, мәктәп җиһазларын бозу.

Начар тәрбия алган бала кайчак үзен тәрбияле тота, әмма бу бары тик аны башкалар күзәтеп торганда яисә үзенә җәза бирелүдән курыкса гына шулай була. *Яхшы тәрбия алган* бала, башкалар күзәтеп тору-тормауга карамастан, үзе генә калган вакытта да тәртип кагыйдәләрен бозмый.

Сезнең өчен мәдәни нормалар әһәмиятлегә, ягъни **кыйммәтләргә** әверелгәч кенә, тәрбия сезнең өчен уңышлы булачак. Әйтик, башка кешеләрне алдамаска.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Кыйммәтләр — шәфкать, гаделлек, ватанпәрвәрлек, мәхәббәт, дуслык һ.б. турында күпчелек кешеләр тарафыннан хуплана һәм дөрес дип табыла торган күзаллаулар. Кыйммәтләр шик астына куелмый, алар барлык кешеләр өчен эталон, идеал булып тора.

Яшь буынга мәдәни кыйммәтләрне тапшыру һәрвакыт зур әһәмияткә ия булды

Кеше гомере иң зур кыйммәт булып тора. Аны сакларга кирәк.

Нормаларның кайберләре безгә бик ачык аңлашыла, без аларны һич уйлап тормыйча үтибез. Кайберләрен үтәү бездән билгеле бер көч сарыф итүне таләп итә. Өлкәннәргә урын бирү яисә таныш кешеләр белән очрашканда исәнләшү сезнең өчен мәҗбүри нәрсә булырга тиеш.

Без уйнаган социаль рольләр

Җәмгыятьтә яшәү — төрле мәдәни нормаларны гына түгел, төрле **социаль рольләр** дә үзләштерү дигән сүз ул.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Социаль роль — җәмгыятьтә тоткан урынына карап (ул, кыз, ата, ана, укытучы, укучы, сатып алучы, сатучы һ.б.), кешенең үз-үзен тоту өлгесе.

Гомере дәвамында кеше бик күп социаль рольләр үзләштерә. Аларны китаплардан гына өйрәнү мөмкин түгел, чөнки һәр роль билгеле бер кешенең үз-үзен тотышы өлгеләрен, бурычларын, мөнәсәбәтләрен үз эченә ала. Кеше чынбарлыктагы тормыш шартларында рольләр үзләштерә. Укытучы һәм укучы рольләре — иң мөһимнәрдән.

Социаль рольләр: укытучы һәм укучы

Чынлап та, кешенең яше барган һәм ул зуррак вазифалар били барган саен, аңа бик күп социаль рольләр үзләштерергә туры килә. Ул хезмәткәр, сатып алучы, ата яисә ана, бала, Ватан сакчысы һәм башка шундый күптөрле рольләр башкара.

Инглиз драматургы Уильям Шекспир: «Бөтен дөнья — театр, бар кеше анда — актер, һәм һәрбер кеше анда үз ролен уйный», — дигән. Әгәр дөньяны чынлап та сәхнә дип күзалласак, безгә ул сәхнәдә чынлап та бик күп роль уйнарга туры килә. Без барыбыз да — уллар һәм кызлар, ирләр һәм хатыннар, хезмәткәрләр һәм җитәкчеләр, нотык сөйләүчеләр һәм тыңлаучылар, пассажирлар, тамашачылар һ.б.

Әти-әниләрегез сездән кичке сәгать 10 тулганчы өйгә кайтуыгызны сорый, дәресләр әзерләвегезне тикшереп торалар яисә чүп чиләген чыгарып түгәргә кирәклеген исегезгә төшерәләр икән, аларның кәефе юк, яисә алар сезне яратмый дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Алар бары тик үзләренең социаль ролен генә үти. Сез моны төшенеп тә җитмисездер, мөгаен. Сезнең рольләрегез исемлеге бик кыска шул. Үсеп буйга җитегез әле, сез дә үзегезне нәкъ шулай тотачаксыз. Балалар һәрвакыт, зур үскәч, мәңге үземне шулай тотмаячакмын, дип кабатлый. Ә әти-әни үзалларына һәрчак, балачакта без яхшырак идек, ди.



Бу фотосурәттәге кешеләрнең мөмкин булган социаль рольләрен атагыз.

Социальләшү

Кеше бөтен гомере буена мәдәни нормалар һәм социаль рольләр үзләштерә. Ә бу исә бөтен гомер буена социальләшү процессы бара дигәнне аңлата. Без һәрвакыт җәмгыятьтә яшәргә өйрәнәбез.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Социальләшү — мәдәни нормалар һәм иҗтимагый рольләрне үзләштерү.

Социальләшү процессында өйрәнүче һәм яңа белемнәр, кыйммәтләр, йолалар, нормалар үзләштерүче як кына түгел, иҗтимагыйлашуга «өйрәтүче» як та катнаша.

Иң беренче нәүбәттә бу ата-ана, абый-апалар, әби-бабайлар, якын һәм ерак туганнар, бала караучылар, гаилә дуслары, тренерлар, табиблар, яшьләр төркемнәре лидерлары. Бу — мәдәни нормаларга өйрәтү һәм социаль рольләрнең үзләштерелүе өчен җаваплы конкрет кешеләр.



Ата-аналар, әби-бабайлар сезнең социальләшүегезгә ничек булышлык итә?

Әмма «гаилә» барыбер укытучыларның иң-иң кирәклесе. Балачакта гаиләдә өйрәнгәннәрегез сезне гомерегез буена озата киләчәк. Гаиләдә бала шәхесенең нигезләре салына. Исегездә калдырыгыз, кешенең мәдәни нормаларны һәм кыйммәтләрне, социаль рольләрне үзләштерү дәрәҗәсе аның җәмгыятьтә тоткан урынына йогынты ясый.

Йомгак ясыйбыз

Кеше бөтен гомере буена, сабый чагыннан алып картлыгына кадәр, җәмгыятьтә яшәргә өйрәнә — мәдәни нормаларны гадәтенә кертү һәм социаль нормаларны үзләштерү процессында катнаша. Социальләшүдә төп рольне гаилә уйный.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Мәдәният, мәдәни нормалар, социаль роль, социальләшү, кыйммәтләр

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Социальләшү» нәрсә ул? Җавап биргәндә түбәндәге схемадан файдаланыгыз:



2. Сез нинди социаль рольләр үзләштердегез инде?

3. Әти-әниегездән тыш сезнең социальләшүегезгә тагын кемнәр ярдәм итә?

4. «Мәдәният», «мәдәни нормалар», «социаль роль», «кыйммәтләр» төшенчәләрен аңлатыгыз.

5. «Җыештырып торган җирдә түгел, чүпләмәгән җирдә чиста» дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?

6*. Социальләшү процессында кеше социаль рольләрне үзләштерә, ә мәдәни нормаларны гадәткә кертә. Ни өчен?

Практикум

1. Кызганыч, әмма кешеләр арасында мәктәпкә яисә китапханәгә баш киемен салмыйча гына керә, чүпчарны урамда ташлап калдыра, сорауларга дорфа җавап бирә, этеп-төртсә дә, гафу үтенүне кирәк санамый торганнары очрый. Мондый кешеләрне ничек атыйбыз? Аларның үз-үзләрен тотышын ничек аңлатасыз?

2. Сез үзегезне һәрвакыт башкалар көткәнчә тотасызмы? Сезгә үзегезне яхшы тотуга комачаулык иткән һәм, киресенчә, ярдәм иткән нәрсәләр турында берничә җөмлә языгыз.

3. Әти-әниегездән яисә башка өлкәннәрдән кешенең яхшы тәрбиясе (үз-үзен тотышы) аңа авыр тормыш хәлендә ярдәм итүенә чынлыкта булган берәр хәлне искә төшерүләрен үтенегез. Бу мисалны язып алыгыз һәм дәрестә сыйныфташларыгыз һәм укытучы белән фикер алышыгыз.

§ 10. Кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны

Кешенең җәмгыятьтәге урыны нәрсәгә бәйле? Кешенең социаль статуслары күпме була? Нинди иҗтимагый статус иң мөһиме?

Кешенең социаль рольләре үзләреннән-үзләре генә булмый. Алар **кешенең җәмгыятьтә тоткан урынына** туры килә. Мәктәп баласы укучы, ул яки кыз, эне яисә сеңел, оныкавтобус пассажиры, азык-төлек кибетендә сатып алучы, халык бию ансамблендә катнашучы һ.б рольләр башкара. Әмма, әйтик, 5 нче сыйныф укучысы диплом эше якласа яисә салонда кыйммәтле машина сатып алса, сәер булыр иде. Бу гамәлләр укучының җәмгыятьтәге роленә, ягъни аның **социаль статусына** туры килмәс иде.

Шәхеснең социаль «үлчәмнәре»

Кешенең җәмгыятьтәге урыны аның тумыштан килгән һәм гомер барышында тупланган сыйфатларына бәйле. *Тумыштан килгән сыйфатлар* — кешенең буе, физик көче, күзенең төсе, гәүдә әгъзалары үлчәме, гәүдәсенең тулылыгы яисә арыклыгы, темпераменты, акыл сыйфатлары, җенесе һәм яше белән бәйле үзенчәлекләре һ.б. Әгәр агрессивлык кешенең тумыштан килә торган сыйфаты булса, кешеләр арасында котылгысыз низаглар килеп чыгачак.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Темперамент — кешенең индивидуаль сыйфатлары, беренче чиратта, хис-тойгыларының җитезлек һәм көчлелек дәрәҗәсе белән характерлана. Темперамент кеше хәрәкәтләренең үзенчәлекләрендә дә чагыла.

Өстәмә уку

Кешеләрне, аларның ничек эшләүләрен, укуларын, аралашуларын, сөенүләрен һәм көенүләрен күзәткәндә, без аларның үз-үзләрен тотуларында аерымлыклар күрәбез. Берәүләрнең хәрәкәтләре житез

һәм кискен, икенчеләрнең акырын, сабыр, тыныч һ.б. Мондый төрлелек сәбәбе кешенең аңа тумыштан ук хас темпераментына бәйле. Темпераментның дүрт төп төре бар.

Флегматик — ашыкмый, пошынмый, омтылышлары һәм холкы тотрыклы. Тыныч һәм тигез холкын җуймыйча, эштә үҗәтлек һәм таләпчәнлек күрсәтә.

Холерик — җитез, кискен, кәефе бик тиз үзгәрүчән, сабырсыз, низаглы.

Сангвиник — энергияле, тормыш сөючән, аралашучан кеше, кәефе, хис-тойгылары еш алышынып тора, барлык вакыйгаларга реакциясе бик җитез. Аңарда кызыксыну уянса, эшендә уңышлары бик зур була.

Меланхолик — нечкә күңелле, хисле, ул кешеләргә хәерхаһлы һәм аларга чын күңелдән теләктәшлек белдерә, хәлләренә керә.

Үзегезнең темпераментыгыз төрен билгеләргә тырышып карагыз. Мөгаен, сез үзегездә төрле темпераментларга хас сыйфатлар да табарсыз.

Үзләштерелгән сыйфатлар — мөстәкыйльлек, хезмәт сөючәнлек, җаваплылык, характер, ихтыяр көче, кешеләр белән аралаша белү, башлаган эшне ахырына җиткерү һ.б.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Характер — кешенең үз-үзен тотышында һәм эшчәнлегендә чагылыш тапкан индивидуаль үзенчәлекләр җыелмасы.

Өстәмә уку

Темпераменттан аермалы буларак, характер тумыштан килми. Ул, нигездә, кеше олыгая барган саен формалаша, тумыштан килгән сыйфатларга үзләштерелгән, нигездә, әхлакый сыйфатлар өстәлә.

Кешенең уңай яисә тискәре сыйфатлары чагылыш тапканда, аның характеры турында сүз алып баралар.

Уңай сыйфатлар: кешенең хезмәт сөючәнлеге, эшне намус белән башкаруы, җаваплылыгы, инициативалылыгы, аралашучанлыгы, сизгерлеге, ярдәмчеллеге,

абруй саклавы, үз-үзенә тәнкыйть белән каравы, тыйнаклыгы, җыйнаклыгы, сакчыллыгы, юмартлыгы һ.б. Тискәре сыйфатлар: ялкаулык, җавапсызлык, пассивлык, рәхимсезлек, тупаслык, кешеләргә өстән карау, үзен югары кую, тәккәбберлек, үпкә саклау, эгоистлык, җыйнаксызлык һ.б.

Үз характерыгызның уңай һәм тискәре сыйфатлары исемлеген төзегез. Үзегезнең фикерегезне дәлилләгез. Үз характерыгызда нәрсәләрне үзгәртер идегез?

Үзләштерелгән сыйфатларны **шәхеснең «социаль үлчәмнәре»** дип тә атыйлар. Алар җәмгыятьтә, башка кешеләр белән мөнәсәбәттә үзләштерелә һәм кешенең иҗтимагый статусына йогынты ясый.

Коткаручы, эшкуар, балерина өчен тумыштан килгән һәм үзләштерелгән нинди сыйфатлар мөһим. Үз фикерегезне дәлилләгез.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Социаль статус — кешенең җәмгыятьтәге иҗтимагый хәле.

Кешенең **социаль хәле** — аның җенесе, яше, белеме, һөнәре, икътисади (матди) хәле, сәяси мөмкинлекләре кебек позицияләр нигезендә характерлануы.

Кешенең белеме, һөнәре, матди хәле, җенесе һәм яше, дәүләт белән идарә итүдә катнашу мөмкинлегенә бәйле рәвештә, җәмгыятьтә билгеле бер социаль урын тота.

Мәктәп укучысының социаль хәле

Әйдәгез, **мәктәп укучысының социаль хәлен** төрле яклап тасвирлап карыйк.

Мәктәп укучысы социаль хәленең олылар белән чагыштырганда нинди үзенчәлекләре бар? Җавабыгызны дәлилләгез.

Сез әлегә белем аласыз гына, сезнең һөнәрегез юк, матди яктан әти-әниегезгә бәйле. Өлкәннәр сезнең турыда кайгырта, һәм сез аларның игътибар үзәгендә. Димәк, сез — *кайгыртудагы (опекадагы) кеше*. Бу — сезнең социаль хәлегез. Һәм бу сыйфатта сезгә күп кенә хокуклар бирелгән, алар дәүләт тарафыннан суд системасы аша яклана. Һәрбер бала үз әти-әнисе тарафыннан тәрбияләнергә, үзенең мәнфәгатьләре тәэмин ителүенә, төрле яклап үсеш кичерергә, кешелек абруен саклауга хокуклы.

Гаиләдә үз мәнфәгатьләренә кагыла торган теләсә нинди мәсьәлә хәл ителгәндә, бала үз фикерен белдерергә хокуклы. 10 яше тулган баланың фикере, аның мәнфәгатьләренә зыян китерә торган очраклардан гайре, һичшиксез исәпкә алынырга тиеш. Мәктәп укучысы уку йортын, түгәрәкләр һәм секцияләрне үзе сайларга хаклы.

Өстәмә уку

Берләшкән Милләтләр Оешмасының Балалар фонды (ЮНИСЕФ) — дөньяның 150 дән артык илендә балаларга ярдәм күрсәтә торган халыкара оешма. Россиядә ЮНИСЕФ 1997 елдан эшли. Безнең илдә фонд эшчәнлегенең төп максаты — бала хокукларын яклау, балаларның имин һәм сәламәт балачакка хокукларын тормышка ашыруга ярдәм итү, яшьләрнең үсеше-алгарышына һәм иҗтимагый тормышта актив катнашуына булышлык күрсәтү, һәрбер баланың үсешкә һәм үзенең тормышына турыдан-туры кагылышы булган карарлар кабул итү процессында катнашу хокукы булган җәмгыять формалаштыруга ярдәм күрсәтү.

Фондның Россиядәге адресы: 125003, Мәскәү шәһәре, Леонтьевский тыкрыгы, 9 йорт.
Тел.: (495) 933-88-18.
Сайт: *http: www.unicef.ru*
E-mail: *moscow@unicef.org*

Дәреслек текстын һәм unicef.ru сайты материалларыннан файдаланып, БМО Балалар фондының эшчәнлеге турында сөйләгез. Балалар ни өчен ярдәмгә аеруча мохтаҗ? Бу сезнең иҗтимагый хәлегез белән нинди бәйләнештә?

Хокуклар, бурычлар һәм җаваплылык

Кешенең социаль хәлен аның **хокуклары** гына түгел, **бурычлары** (ни дә булса эшләү зарурлыгы) да тәшкил итә.

Ата-ана үз балаларын тәрбияләргә, аларның мәнфәгатьләрен һәм хокукларын якларга, сәламәтлекләре турында кайгыртырга бурычлы. Укытучылар сезгә белем һәм

тәрбия бирә, мәктәп администрациясе уку-укыту процессын оештыра, ә сез яхшы укырга бурычлы.

Балигъ булганнан соң (18 яшь тулгач), сез сайлауларда катнашу хокукы аласыз, тулы хокуклы һәм сәяси актив гражданнарга әйләнәсез. Шушы вакыттан сез балалыктан чыгасыз, олылар категориясенә күчәсез.

Шул рәвешчә, һәр статус билгеле бер хокуклар һәм бурычлар белән характерлана.

Теге яисә бу бурычларны башкаруы аша кеше башкалар алдында билгеле бер **җаваплылык** үти. Итекче, әйтик, заказчыга үз вакытында һәм сыйфатлы продукция җитештереп тапшырырга тиеш. Әгәр бу шулай булмаса, ул ниндидер җәзасын алырга тиеш, ул кешеләр ышанычын югалтачак, яисә аны судка тартырга мөмкиннәр.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Җаваплылык — үз гамәлләрең яисә эшчәнлегең өчен җавап тоту бурычы.

Кызыклы фактлар

Борынгы Мисырда гадәт шулайрак булган: әгәр архитектор начар төзегән бина ишелеп, хуҗасын басып үтерсә, архитекторны үлем җәзасы көткән. Җаваплылык күрсәтү рәвешләренең берсе шундый.

Борынгы Римда, операция вакытында авыру үлсә, табибның кулларын кисканнәр.

Россия империясендә елга аша тимер юл күпере салу белән җитәкчелек иткән инженер, аның буйлап беренче поездны җибәргәндә, күпер астында көймәдә торган.

Кешенең хокуклары бурычлары белән тыгыз бәйләнгән. Статусы зуррак булган саен, кешегә шуның кадәр күбрәк хокук бирелә, һәм бурычлары да шуның кадәр күбрәк була. Мәсәлән, патша тәхете варисы яисә телевидениедә тапшырулар алып баручы мәшһүр журналист статусы әлеге кешеләрдән аларның үз-үзләрен ничек тотарга тиешлеге ту-

рында җәмгыятьтә яшәгән карашларга туры килердәй тормыш рәвеше алып баруын таләп итә.

Социаль статусларның күптөрлелеге

Кешенең социаль статуслары күп — ул, әйтик, рус (милли статус), россияле (гражданлык статусы), ир кеше (җенес), урта яшьләрдә (яшь), православие дине вәкиле (дини статус), программист (һөнәри), мәскәүле (территориаль), өйләнгән (никах статусы), ата (гаилә), «Спартак» җанатары (ял итү), аучы (ял итү), штангачы (спорт), лидер (төркем статусы) һ.б.

Һәрбер статуска бер яисә берничә социаль роль керә. Әйтик, ата үз балаларына карата аларны туендыручы, тәрбияләүче, уеннарында катнашучы иптәш була ала.

Әгәр **статус** җәмгыятьтә тоткан урын булса, **роль** — кешенең үз-үзен статусына яраклы рәвештә тотуы. Корольнең статусы аңа үзен гади гражданнардан аермалы буларак бөтенләй башкача тотуны йөкли. Әлеге статуска туры килә торган роль моделе аның дәүләтендә яшәүче кешеләр өметләренә һәм теләкләренә туры килергә тиеш. Үз нәүбәтендә әлеге кешеләр дә, үз статуслары һәм ранглары кушканча, җәмгыять нормалары һәм таләпләр нигезендә, шулардан һич тайпылмыйча гамәл кылырга тиешләр.



Укучылар укытучыдан үз-үзен билгеле бер тотышын көтәләр

Әмма һәркемнең бер **төп статусы** була. Бу — кешенең тормыш рәвешен, таныш-белешләре даирәсен, үз-үзен тотышын һ.б. билгеләүче статус. Хәзерге җәмгыятьтә, кагыйдә

буларак, бу — һөнәр, кешегә аның өчен акча түләнә торган шөгыль.

Кайбер кешеләр өчен төп статус инвалидлык була. Ул кешенең сәламәтлеге һәм инвалидка дәүләт бирә торган тиешле хокуклар белән билгеләнә.

Йомгак ясыйбыз

Кешенең җәмгыятьтәге урыны — социаль статусы — аның үзләштерелгән һәм тумыштан килгән сыйфатлары белән билгеләнә; белеменә, һөнәренә, матди хәленә, җенесе һәм яшенә, дәүләт белән идарә итүдә катнашу мөмкинлегенә бәйләнгән. Һәр кешенең социаль статуслары һәм социаль рольләре күп була. Аның статуслары һәм рольләре яше белән бергә үзгәрә.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Социаль статус, иҗтимагый хәл, җаваплылык, темперамент, характер

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Схемадан файдаланып, кешенең җәмгыятьтәге иҗтимагый хәле нәрсәләргә бәйле булуын аңлатыгыз.



2. Үз иҗтимагый хәлегезне төрле яктан, җенес, яшь, белем һәм башкалар белән бәйләп тасвирлагыз.

3. Сезнең төп социаль статусыгыз нинди? Ни өчен?

4. Шәхеснең социаль «үлчәмнәрен» сез ничек аңлыйсыз? Җавабыгызны дәлилләгез.

5. Түбәндәге төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатыгыз: «социаль статус», «иҗтимагый хәл», «җаваплылык».

6*. Үсмернең хокуклары аның иҗтимагый хәлен ничегрәк ача?

Практикум

Үзегез яраткан әдәби яисә кино геройлары арасыннан берсенең социаль хәлен тасвирлап бирегез.

§ 11. Кешенең гомер чорлары

Кешелек картая аламы? Кешенең гомер чорлары ничәү? Аларның кайсысы яхшырак?

Кеше гомере бик мавыктыргыч! Андагы күп кенә үзгәрешләр яшь белән бәйле, ә кеше үзенең яшен сизми.

Кеше дөньяда озаграк яшәгән саен, ул күбрәк эшләр башкарырга өлгерә — һөнәр ала, аның дуслары күбәя, ул дөнья буйлап күбрәк сәяхәт итә, балалар, оныклар үстерә. Андый эшләр бик күп.

Кешелек картая

Уртача алганда кеше җирдә 60 ел яши, Европада һәм Японияда — аннан озаграк, ә Африкада — кимрәк (кайбер илләрдә озын гомерле аерым кешеләрнең гомере 80 елдан артып китә). Галимнәр иң тәүге кешеләр җәмгыятендә уртача гомер озынлыгы — 15—22 ел, Борынгы заманда — 20—30 ел, XIX гасыр ахырында 50 ел булуын исәпләп чыгарганнар.

Әмма бу — уртача күрсәткечләр. Гомернең уртача озынлыгы түбәндәгеләрне исәпкә ала: яшьли үлемнәр, сугыштагы

югалтулар, озак яшәү рекордлары. Болар барысы да кушыла һәм аннары халык санына бүленә. Россия империясендә менә ни өчен йөз ел элек уртача гомер озынлыгы 30 ел, ә хәзерге Россиядә 69 ел тәшкил итә. Әмма ул вакытта да чал чәчле картлар һәм карчыклар очраган, алар хәзер дә бар.

Кызыклы фактлар

Ике миллион кешедән икесенең 116 яшькә җитү шансы бар.

Азәрбайҗан чабаны Ширали Мөслимовның паспортына ышансаң, ул 168 ел яшәгән. Сара Бернар 70 яшендә У.Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» пьесасы буенча куелган спектакльдә 13 яшьлек Джульеттаны уйный.

Чарли Чаплин театр сәхнәсенә беренче тапкыр 1894 елда биш яшендә чыга: ул мюзик-холл программасында үз әнисен алыштыра. Театрда һәм кинода ул 1957 елга кадәр уйный.

Гомумән, кешелек акрынлап картая. Башкача әйтсәк, тулаем халык исәбендә өлкән буын өлеше арта, ә яшь буынныкы кими. Бу күренешнең сәбәпләре — медицинаның алга китүе — безнең гомеребезне озайта һәм тормыш сыйфатын яхшырта, ә яшь чакта үзең өчен яшәү теләге бала табуны кичектерүгә яисә бөтенләй бала тапмауга этәрә.

Әле XIX гасырда гына Россиядә гаиләдә 7—10 бала булган, аларга күп эшләргә туры килә, алар еш авырый, күбесе сабый чакта ук вафат була. Бүген гадәти гаиләләрдә (Россиядә) 1—2 бала үсә. Балалар азайды, әмма алар турында кайгырту артты. Ата-аналар балаларына акыл үсешен тизләтә торган уенчыклар сатып ала, аларны сәнгать түгәрәкләренә, спорт секцияләренә йөртә.

Кеше гомеренең чорлары

Кеше гомеренең төп алты чоры бар: **балачак** (11—12 яшькә кадәр), **яшүсмер чак** (11—15 яшь), **яшьлек** (15—30 яшь), **өлгергәнлек чоры** (30—60 яшь), **өлкәнлек чоры** (60—80 яшь) һәм картлык (80 яшь һәм аннан олырак).

5 нче сыйныф укучысы яше ягыннан **кече үсмерлек чорына** керә.

Кешенең яшенә ихтирамлы мөнәсәбәт кешелек өчен борынгы чорлардан ук хас. Балалар киләчәкнең нигезе буларак кыйммәтле. Өлкәннәрне төп җитештерүче көч, аны саклаучылар һәм мәңгелек мәдәни кыйммәтләр тудыручылар буларак ихтирам иткәннәр. Ә картлар үзләренең акылы, сабырлыгы, зирәклеге белән хөрмәт казанган (өстәвенә кешелек узган юлның зуррак өлешендә картлык яшенә бик аз гына кеше килеп җиткән, хәзер генә бу башкача).

Фоторәсемдә сез кеше гомеренең нинди чорлары вәкилләрен күрәсез? Параграф материалларына нигезләнеп, аларга тасвирлама бирегез.

Гомернең беренче яртысы — яшәү көче һәм егәр туплау чоры, икенчесе — аларны сарыф итү чоры. Кеше скелетының 18—20 яшьтә формалашуы тәмамлануын, ә 30 яшькә кадәр көч туплавын без беләбез. Үз гомеренең калган елларында кеше үзенең табигый ресурсларын эшкә җигә. Кайбер кешеләр моны ерткычларча, кирәгеннән артык алкоголь эчеп һәм наркотиклар кулланып, үз-үзен эчке тетрәнүләргә һәм физик җәрәхәтләргә дучар итеп, начар тукланып яисә зыянлы ризык ашап уздыра.

Кешенең яше һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр

Кешелек җәмгыяте җитәрлек дәрәҗәдә зирәк төзелгән, һәм ул гомеренең һәр чорында кешегә билгеле бер мөмкинлекләр, бары аның яшендә генә башкарыла ала торган хезмәт, эшчәнлек төрләре, рольләр ача. Әйтик, мәктәпкә баланы 6 яше тулганчы алмыйлар. Билгеле бер яшькә җитми торып паспорт бирелми (Россиядә — 14 яшь), дәүләт вазифалары биләү, армиядә хезмәт итү һ.б. тыела. Пенсия яшенә җиткәч (55 яшь — хатын-кыз, 60 яшь — ир-ат), кеше лаеклы ялга китәргә мөмкин.

Бер яшьтәге, бер үк тарихи чорда яшәүче барлык кешеләр **буын** дип атала. Бер буын кешеләре бер үк төрле тарихи шартларда формалашалар. Сез һәм сезнең әти-әниләрегез, бабай-әбиләрегез — төрле буын кешеләре.

Төрле яшьтәге кешеләрнең физик һәм психологик мөмкинлекләре дә төрлечә, аларның үз бурычлары һәм социаль рольләре, ягъни **яшь статусы** бар.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Яшь статусы — теге яисә бу яшь өчен хас булган хокуклар һәм бурычлар җыелмасы.

Кешенең үз яшь статусына яраклы рәвештә үз-үзен тотышы **яшь роле** дип атала.

Төрле яшьтәге кешеләр рольләре һәм функцияләре белән бер-берсеннән аерыла: 30 яшьлек кеше, 14 яшьлек үсмер һәм 60 яшьлек кеше белән чагыштырганда, күбрәк эш башкара ала. Аңа күп социаль рольләр үзләштерергә, бер аралашу даирәсеннән икенчесенә күчәргә туры килә. 30 яшьлек ир-атның хокуклары һәм җаваплылыгы 12 яшьлек үсмернекенә караганда күпкә артыграк. Аны җинаять җәзасына тартырга мөмкиннәр, ул сайлауларда катнаша, теләсә нинди дәүләт вазифасы били һәм хәтта президент булып сайлана ала. Икенче яктан, аның бурычлары да күбрәк. Ул гаиләсен тәэмин итәргә, көнкүреш мәсьәләләрен чишәргә, һөнәри эшчәнлек алып барырга тиеш.

Бер үк кешегә бөтен рольләрне берьюлы башкарырга туры килгәне юк. Алар кеше гомеренең барлык чорларында

тигез бүленгән. Әйтик, балачакта сез бары тик ул яисә кыз, өлгергәнлек чорында — шуның өстенә ата яисә ана, ә картлыкта — әби яисә бабай.



Фоторәсемнәрдә сурәтләнгән төрле яшьтәге кешеләрнең нинди хокуклары һәм бурычлары бар? Аларның иҗтимагый рольләре нинди?

Гомернең һәр фасылы (чоры) үзенчә кабатланмас һәм алыштыргысыз. Аның һәркайсы калганнары (өлгергәнлек булуга да карамастан) башкара алмаган үз бурычларын хәл итә.

Сабыйлык чорыннан алып 15 яшькә кадәр, бу **балачак** һәм **яшүсмерлек чорына** туры килә, кешенең нинди дә булса төгәл генә максатлары юк. Бала бүгенге белән яши һәм киләчәкне бик томанлы күзаллый. Аның өчен өлкәннәр җаваплы була. Бу чорда, нигездә, физик һәм акыл мөмкинлекләре үсеш кичерә.

15 яшьтән 30 яшькәчә булган чор **яшьлеккә** туры килә. Бу вакытта кеше үзенең ихтыяҗларын, сәләтләрен һәм мәнфәгатьләрен аңлый башлый. Ул һөнәр, тормыш иптәше

сайлау, карьера ясау һәм үз тормышы мәгънәсен аңлау белән бәйле бөек планнар кора.

Киләсе чор 30 дан 60 яшькәчә дәвам итә һәм **өлгергәнлеккә** туры килә. Аның өчен төгәл максатлар кую хас. Бу вакытта кеше сайлаган һөнәрендә уңышларга ирешә, үз гаиләсен төзү һәм балалар үстерү белән бәйле карарлар кабул итә.

Киләсе чор 60 яшьтән 80 яшькәчә дәвам итә. Бу инде мөхтәрәм **өлкәнлек**. Кеше үз тормышына һәм ирешкәннәренә йомгак ясый. Моннан соң, киләчәккә күз салганда, һөнәри өлкәдә ирешкәннәрен, физик хәлен һәм гаилә тормышын исәпкә алып, кеше үз максатларын яңадан карап тикшерергә мәҗбүр була.

Гомернең йомгаклау чоры — **картлык**. Ул 80 яшьтән башлана. Калган көчләрен кешеләр якыннары һәм туганнары белән аралашуга, төрлечә ял итүгә сарыф итә, балалары, оныклары һәм оныкчалары белән тәҗрибә уртаклаша.

Йомгак ясыйбыз

Галимнәр кеше гомерен берничә чорга бүләләр: балачак, яшүсмер чак, яшьлек, өлгергәнлек, өлкәнлек һәм картлык.

Гомернең һәр чоры билгеле бер хокуклар, бурычлар, җаваплылык, статус, мөмкинлекләр һәм чикләүләр белән бәйле.

5 нче сыйныф укучысының яше кече үсмерлек чорына туры килә.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Яшь статусы, яшь роле, буын

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Кеше нинди гомер этаплары уза? Аларның үзенчәлеге нинди?

2. Сезнең яшегез нинди гомер чорына туры килә? Дәреслек материалын һәм үз тәҗрибәгезне исәпкә алып, аңа характеристика бирегез.

3. Түбәндәге гомер чорларының мөмкинлекләрен һәм чикләүләрен чагыштырыгыз: үсмерлек һәм өлгергәнлек; үсмерлек һәм картлык.

4*. Сез «гомернең һәрбер чоры үзенчә матур» дигән гыйбарә белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.



Практикум

1. Җөмләдә «йогынты ясый» яисә «йогынты ясамый» дигән сүзләрнең кайсысы төшереп калдырылган? Үз җавабыгызны дәлилләгез.
«Минем яшем минем иҗтимагый хәлемә ____________».

2. Фантастик повестьта 10 яшьлек малай могҗиза белән олы кешегә әверелә. Сез ничек уйлыйсыз, аңа нинди кыенлыклар кичерергә туры килә? Бу ни өчен шулай?

3. Төрле яшьтәге кеше төркемнәренең үз гадәтләре, үз зәвыгы. Алар билгеле бер нәрсәләргә өстенлек бирәләр. Аларның шул исәптән үз музыкаль зәвыклары да бар.
Төрле яшьтәге кешеләрнең нинди музыкага өстенлек бирүе турында уйлагыз. Үз сүзләрегез белән аларның музыкаль зәвыкларына, алар яраткан җырларның характерына һәм эчтәлегенә тасвирлама бирегез. Таблицаны тутырыгыз.

Яшь төркемнәре	Нинди музыка яратуы
Яшүсмерләр	
Өлгергәнлек яшендәге кешеләр	
Өлкән кешеләр	

4*. Балаларның тизрәк зур үсәсе килә, ә күп кенә картлар бала чакларына кире кайтырга каршы булмас иде. Сез ничек уйлыйсыз, бу нигә шулай?

5 нче сыйныф укучылары кемнәр алар? Яшүсмер булу җиңелме?

Кешенең яше – туган көне уңаеннан ел саен гаиләдә бәйрәм ителә торган еллар исәбе генә түгел, бәлки аның җәмгыятьтә билгеле бер урын биләве дә әле. Ул яңа хокуклар, бурычлар, җаваплылык белән дә бәйле.

Кемне яшүсмер дип санарга?

5 нче сыйныф укучылары — бала чактан өлкәннәр дөньясына күчүче кешеләр ул. Нәрсәләрдер бала чактан калган, нәрсәләрдер олылардан күчә. Мөстәкыйльлеккә омтылуны гына алыйк. Торган саен ешрак «Мин үзем беләм!» дигән сүзләр ишетелә. Бу сезнең үсмерлек чорына күчүегезне аңлата. Аның нинди үзенчәлекләре бар?

Яшүсмерлек чоры (аны кайчак күчеш чоры дип тә атыйлар, чөнки бу вакыт балалыктан өлкән кешеләр сафына күчү бара) 11 яшьтән 15 яшькәчә дәвам итә. 5 нче сыйныф укучылары яшь ягыннан кече үсмерлек чорына керәләр.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Яшүсмерлек чоры — балаларның 11—12 яшьтән 15 яшькәчә үсеше вакыты, бу 5—8 нче сыйныф укучылары яшенә туры килә.

«Үсмер» сүзе белән беррәттән чагыштырмача яңа «тинейджер» сүзе дә кулланыла. Ул *teens* һәм *age* дигән инглиз сүзләреннән ясалган. АКШ һәм Англиядә үсмерләрне «тин» дип кенә дә атап йөртәләр.

Әйләнә-тирәдәгеләр үсмерләрнең олы кешеләрчә гамәл кылуын көтәләр, аларга зур өметләр баглана, алар белән ешрак киңәш-табыш итәләр, аларга ышаныч зуррак. Әмма шул ук вакытта яшүсмерләргә таләпләр дә катгыйрак. Балачакта аның тәртибен ата-аналары тикшереп тора, ә олылар тормышы мөстәкыйль карарлар кабул итү таләбен куя. Дөньяга карашыңны яңача корырга, әзер кыйммәтләрне,

идеалларны кабул итәргә һәм үзлегеңнән яңаларын эшләргә туры килә.

Яшүсмер чак —
балалыктан олылар дөньясына күчеш чоры

Яшүсмерләр **балигъ булмаганнар** категориясенә керә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Балигъ булмаганнар — закон нигезендә олы кешеләр түгел дип танылган, 18 яшькә җитмәгән затлар.

Балигъ булмаганнар эшләп алган акчаларын яисә стипендияләрен мөстәкыйль тота алалар. 14 яшьтән (ата-анасы рөхсәте белән) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә мөмкин. Безнең илдә җинаять кылган өчен җаваплылык 16 яшьтән башлана. Әмма бу 16 яше тулмаган кешеләр җәзасыз кала дигәнне аңлатмый. 14 яшьтән РФ Җинаять кодексында күрсәтелгән җинаятьләр өчен (мәсәлән, үтерү, янап ни дә булса таләп итү, терролык акты турында ялган хәбәр бирү, авыр хәлләргә китерүче хулиганлык һ.б.) үсмер җавапка тартыла.

Үсеп җитү кыенлыклары

Сез башлангыч мәктәпне тәмамладыгыз. Урта сыйныфларда укуга күчү — сезнең тормышыгызда зур үзгәреш вакыты. Кече сыйныфларда сез укырга, язарга һәм санарга өйрәндегез, сезнең әйләнә-тирә мохит турында күзаллавыгыз барлыкка килде. Урта мәктәптә тарих,

җәмгыять белеме, чит телләр, география, биология, алгебра, физика, химия кебек яңа фәннәр керә башлады. Шул рәвешчә, сез системалы рәвештә фән нигезләрен өйрәнүгә керештегез. Сезгә белем бирү дә башкачарак оештырыла: башлангыч мәктәптәге бер укытучы урынына һәр фәнне хәзер аерым укытучы алып бара, бер сыйныф бүлмәсе урынына сез төрле кабинетларда белем аласыз. Монысы кабинет системасы дип атала. Бик күп нәрсәләр яңа: укытучылар, аларның белем бирү ысуллары, дәреслекләр.

5 нче сыйныфта тагын да күбрәк эшләргә туры киләчәк, яңа белемнәр һәрчак кызыклы

Үзегезгә игътибар белән карагыз. Әгәр башлангыч мәктәптә сез укытучының тәфсилләп дәрес бирүен бик теләп тыңласагыз, хәзер сез фикер йөртүне, теләсә нинди яңа мәгълүматны тәнкыйди бәяләп, үз фикерегезне әйтүне өстенрәк күрәсез. Шунысы да бар: үз фикерегез сезнең өчен аеруча зур кыйммәткә ия, чөнки ул зур авырлык белән бирелә.

Үсмерлек чоры — кайнап торган көч-егәр, активлык, зур уй-хыяллар һәм зур эшләр чоры ул. Сезнең яшегезнең характерлы билгеләре бар: кызыксынучанлык, зиһен үткенлеге, белергә һәм мәгълүмат тупларга омтылу. Сезнең бар нәрсәне эшләп карыйсыгыз, бар нәрсәдә катнашасыгыз килә. Бик теләп җырлыйсыз, биисез, рәсем ясыйсыз, төрле спорт уеннарында катнашасыз, үз куллары-

гыз беләнниләрдер ясыйсыз, натуралистлар һәм географлар, туристлар түгәрәкләренә йөрисез. Хәрәкәтле спорт төрләре сезне аеруча җәлеп итә. Роликларда, тимераякларда шуу дисеңме, скейтборд, чаңгы, сноуборд, велосипедта йөрүме — җаныгыз ни тели, барысына да юл ачык.



Походка бару — яшүсмер активлыгы чагылышы

Шул рәвешчә, сезнең әйләнә-тирә мохиткә яңача карашыгыз формалаша, үз карашларыгыз һәм фикерләрегез барлыкка килә. Әмма ул гына түгел: үзегез турында берникадәр югары фикер һәм шуның белән беррәттән, сәбәбен аңлатып булмый торган үпкәчәнлек тә пәйда була.

Кызыклы фактлар

Галимнәр күптән түгел генә 8 яшьтән 14 яшькәчә балалар арасында аеруча еш кулланыла торган сүзләрне ачыкладылар. Беренче урында — «мәхәббәт», икенче урында — «ирек», өченче урында — «дуслык».

Яшүсмерләрнең «көчсез», мөстәкыйль түгел, ягъни яшүсмернең «сабый түгеллеген» шик астына кую мөмкинлеге бирә торган сыйфатларга ия дигән дан алудан бик шүрләүләре ачыкланды.

Яшүсмер организмы бик көчле һәм тигезсез үсеш кичерә: скелет (аеруча аяк-куллар) буйга тиз үсә, ә күкрәк читлегенең үсеше акрынрак бара. Төрле еллар статистикасына караганда, хәзерге балалар ата-бабаларын буй ягын-

нан узып киткән. Барыннан да элек бу яхшы туклану, медицина ярдәме күрсәтү нәтиҗәсе булса кирәк.

Яшүсмерлек чорында малай-кызлар беренче мәхәббәт хисләре кичерәләр. Дөрес, алар тойгыларын дусларыннан, әти-әниләреннән, укытучыларыннан яшерергә тырышалар.

Өстәмә уку

Яшүсмерлек чорының психологик үзенчәлекләренә «үсмерлек комплексы» дигән атама бирелгән. Аларга түбәндәгеләр керә:

- төс-кыяфәтләренә читләр кешеләр куйган бәягә нык игътибар бирү;
- үз-үзенә чиксез ышану һәм әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтле артык катгый фикер йөртү;
- якыннарына илтифатлы булу һәм шул ук вакытта аларга гаять шәфкатьсез мөгамәлә күрсәтү;
- артык оялчанлык «тугарылганлык», ә башкалар тарафыннан танылу һәм бәяләнү теләге ясалма бәйсезлек белән үрелеп бара;
- танылган абруйлы шәхесләр, гомум кабул ителгән кагыйдәләр һәм киң таралган идеалларга илтифатсызлык күрсәтү белән бергә, очраклы кумирлар илаһилаштырыла.

Үзегезгә игътибар белән карагыз: сездә «яшүсмерлек комплексы» бармы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

Үсеп җитү хисе

Яшүсмерлек тәрбия бирүдә традицион рәвештә иң авыр чор дип танылa. Яшүсмерләрнең холкы, үз-үзен тотышы тотрыксыз, үзенә бәя бирүе үзгәреп тора, физик хәле һәм кәефе кинәттән алмашына, күңеле үтә сизгер.

Бу чорда яшүсмер өчен үзен **үсеп җиткән** дип хис итү психологик яктан иң мөһим ихтыяҗга әйләнә. Бу ихтыяҗ өлкәннәр тарафыннан аның тигез хокуклыгын, мөстәкыйльлеген тануда, ихтирамлы, җитди мөнәсәбәт, ышаныч күрсәтүдә чагылыш таба. Өлкәннәргә хас конкрет

эшләр башкаруга, иҗтимагый файдалы эшчәнлеккә омтылу шуннан килә.

Яшүсмернең теләкләре бик күп, әмма аңа күп нәрсәгә юл ябык. 5 нче сыйныф укучысы үзен күп нәрсәдән тыя, күп кенә нәрсәләргә ата-аналар рөхсәт бирми. Аларның сүзен тыңларга туры килә. Нәтиҗәдә яшүсмер әти-әнисе, укытучылары һәм үз-үзе белән каршылыкка керә. Моның сәбәбе аның үз-үзен «сабый түгел» дип хис итүе, ә олыларның аны «олы кеше» дип кабул итмәве белән бәйле. Аның үз-үзенә мөнәсәбәте үзгәрсә дә, аңа карата олыларның мөнәсәбәте үзгәрми.

Яшүсмерләр үзләренә өлкәннәр рольләрен «үлчи» башлый. Шул ук вакытта алар үзләрен өлкәннәр белән бертигез дип саныйлар, үзләренең тормыш программаларын булдыралар, киләчәкләрен кайгырталар һәм җәмгыятьне үзгәртү турында уйлыйлар. Алар тормышта иң мөһим нәрсәләр турында фикер йөртергә керешәләр, ничек үсеп җитәргә һәм кем булырга теләүләре турында уйланалар.

Яшьтәшләре белән мөнәсәбәт

Яшүсмерлек чорында **яшьтәшләр** белән мөнәсәбәтләр бик мөһим.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Яшьтәшләр — бер үк яшьтәге кешеләр.

Яшьтәшләрегез – сезнең белән бер яшьтәге кешеләр, һәм алар үзләрен сезнең эш-гамәлләрегезгә һәм үз-үзегезне тотышыгызга бәя бирергә хаклы дип саныйлар. Бу исә — яшүсмер әле яңа гына аяк баскан бөтенләй яңа вазгыять. Сез үзегезгә чит кеше күзе белән карарга өйрәнәсез. Алар сезгә, беренчедән, туган тиешле түгел, икенчедән, сезнең белән бер үк яшьтә. Тегесе дә, монысы да — «олылар җәмгыятенең» мәҗбүри билгеләре. Әлеге җәмгыятьтә дә кешеләр гамәлләрен яшь ягыннан бертигез һәм туган булмаган затлар бәяли. Яшьтәшләрегез арасында сез әйтерсең олы кешенең социаль «калыбын» үлчәп карыйсыз.

Үзегезгә игътибар белән карагыз. Әгәр сез яшьтәшләрегез фикеренә ата-аналарыгыз фикере белән бер үк дәрәҗәдә колак сала башласагыз, димәк, сез зурлар сафына беренче адымнарыгызны атлыйсыз дигән сүз. Бу 10—12 яшьләрдә башлана. Үсә барган саен, яшьтәшләрегез фикеренә һәм аларның сезгә биргән бәяләренә игътибарыгыз өстенлек алачак. Бөтен гомерегез буена шулай дәвам итәргә мөмкин. 40 исә 50 яшьлек ирләр һәм хатын-кызлар компаниясе — шулай ук яшьтәшләр төркеме, тик өлкәнрәкләр генә.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмерлек — зирәк акыл, белемгә омтылу, кайнап торган көч-егәр, активлык, инициативалылык, эшчәнлеккә сусау чоры. Бу — балалык дөньясыннан олылар дөньясына күчү вакыты.

Нәкъ менә яшүсмерлек чорында малайлар белән кызлар арасындагы аерымлыклар активрак чагыла, яшьтәшләр белән мөнәсәбәтләр зуррак роль уйный башлый.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Яшүсмерлек чоры, балигъ булмаганнар, яшьтәшләр

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Яшүсмерлек чорының чикләре нинди?
2. Яшүсмерлеккә «күчеш», «кискен борылыш» чоры буларак характеристика бирегез.
3. Үсеп җитү кыенлыклары нидә күренә?
4. Сезнең «үсеп җитү хисегез» ничек чагылыш таба?
5. Яшүсмерлек чорында яшьтәшләр белән мөнәсәбәтләр ни өчен бик мөһим?

6*. «Яшүсмерлек чоры — һәр кешегә бирелә торган сынау» дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

Практикум

1. Александр Волковның «Зөбәрҗәт шәһәр тылсымчысы» әкияти повестеннан Элли исемле кыз күп сынаулар уза һәм максатына ирешә — өенә кайта. 10—12 яшьлек балалар хәзерге тормышта нинди мөһим гамәлләр башкара ала? Аларга моның өчен ниләр кирәк?

2. Сез үзегезне өлкәннәрчә яисә, киресенчә, балаларча тоткан очракларны искә төшерегез. Сез моны нинди билгеләр буенча аңладыгыз?

13. Гендер нәрсә ул?

Иҗтимагый җенес нәрсә ул? Гендер рольләр нәрсә ул?

Борынгы грек философы Платон ир белән хатын кайчандыр бербөтен булган дип санаган. Әмма аллалар, гөнаһлары өчен җәза биреп, аларны икегә аерганнар. Шул вакыттан башлап болар дөнья гизәләр, бер-берсен эзлиләр, янәдән кушылу турында хыялланалар.

Гендер — социаль җенес

Биологик җенеснең — ир-ат һәм хатын-кыз җенесләренең нәрсә икәнен һәркем яхшы белә. Ул хайваннарда да, кешеләрдә дә бар. Әмма бары кешенең генә **социаль җенесе** була. Ул кешенең җәмгыятьтә яшәве белән бәйле.

Кешенең җенесе — ир-ат яисә хатын-кыз — гәүдәнең физик төзелешеннән генә тормый. Ир һәм хатын җәмгыятьтә — бу ике тормыш рәвеше һәм ике төрле үз-үзеңне тоту моделе.

Гадәттә ир кеше — гаилә башлыгы, ата кеше, аны тәэмин итүче һәм яклаучы. Хатын-кыз — ана, хуҗабикә, хезмәтче.

Кызыклы фактлар

Хатын-кызлар авыртуга сизгеррәк, әмма алар түземлерәк.

Ирләр ачлыкка һәм авыруларга түземсезрәк.

30 яшьтән башлап һәр 10 ел саен физик көч куллану сәләте ирләрдә — 10 процентка, хатын-кызларда исә нибары 2 процентка кими.

Хатын-кызлар ирләргә караганда күзләрен уртача ике тапкыр ешрак ачып йомалар.

Хатын-кызның ис тою сәләте 20 процентка яхшырак булуына карамастан, ислемай ясаучыларның 80 проценты — ирләр.

1960 елларда *социологлар* — җәмгыятьне өйрәнүче галимнәр — «гендер» термины кертәләр. Ул «социаль җенес»не аңлата.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гендер — ир-атның яисә хатын-кызның җәмгыятьтәге тормыш эшчәнлеге үзенчәлекләре белән бәйле социаль җенес (ир-ат яисә хатын-кыз җенесе).

Кешелек җәмгыятенең ике өлеше

Ир-атта көч, ихтыяр, гаярьлек, сугышчанлык башлангычлары өстенлек итә. Ул хәрәкәтчәнрәк, аның эшчәнлеге күбрәк ни дә булса булдыруга юнәлтелгән: ул — аучы, диңгезче, корыч коючы, космонавт. Тарих ирләрнең ерак юлларга, чит илләр басып алу сугышларына ешрак чыгып китүен, бөек күчешләрдә һәм зур төзелешләрдә ешрак катнашуын күрсәтә.

Хатын-кызда тынычлык башлангычы өстенрәк. Ул хисчәнрәк, тизрәк кабынып китә, әмма тизрәк суына да. Хатын-кыз — шәфкать туташы, тәрбияче, табиб һ.б. Хатын-кызның төп роле — балалар тудыру һәм тәрбияләү, аларны туктаусыз кайгырту.

Хатын-кызга һәм ир-атка нинди сыйфатлар хас?

Кешелек җәмгыятенең ике өлеше	
Ир-ат башлангычы инициативалылык, ихтыяр, гаярьлек, лидерлыкка омтылыш, катгый уй-фикер йөртү һәм гамәл кылу белән бәйле	Хатын-кызның үз-үзен тотышы йомшак күңеллелек, шәфкатьлелек, кайгыртучанлык, җаваплылык, рәхимлелек, кичерүчәнлек, хислелек, татулыкка омтылу белән бәйле

Гасырлар дәвамында берничә буын яшәгән гаиләдә аның башлыгы — өлкән ир-ат — туендыручы, бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүче казый, җитәкче ролен башкара. Ниһаять, сәясәт турында сөйләгәндә, ир-атның илдә сәяси элита тәшкил итүен әйтергә кирәк.

XX гасыр башында гомуми тигезлеккә омтылган хатын-кызлар сәясәт һәм көнкүреш өлкәсендә үзләрен ир-атларга охшатып тота башлый. Аерым алганда, чалбар кияләр. Хатын-кызларга сайлауларда катнашу, дәүләт вазифаларын биләү һәм күптән түгел генә ир-ат һөнәре дип саналган (төзүче, машина йөртүче, хәрби вазифалар һ.б.) профессияләр үзләштерү хокукы бирелә.



Ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр борынгы заманнардан ук сынлы сәнгатьтә урын ала килә: Тутанхамон фиргавен хатыны белән. Рәсемгә дикъкать белән карагыз: анда ир белән хатын арасындагы нинди мөнәсәбәтләр сурәтләнгән?

Кызыклы фактлар

Ир-атларның баш мие хатын-кызларныкына караганда 200 граммга авыррак.

Стандарт тестлар буенча дөньяда иң югары IQ (интеллект коэффициенты) күрсәткечләре — ике хатын-кызныкы.

Гиннесның Рекордлар китабы версиясе буенча, дөньядагы иң югары IQ га фамилиясе французча «акыл иясе» дигәнне аңлаткан хатын-кызга ия. 12 мәшһүр математикның берсе генә хатын-кыз.

Хатын-кызлар ир-атларга караганда телефоннан өч тапкыр ешрак сөйләшә.

Галимнәр тикшеренүләренә караганда, хатын-кызлар ирләр белән чагыштырганда белемлерәк. Алар, акылга нигезләнеп ясалган нәтиҗәләргә түгел, интуициягә һәм хисләргә күбрәк таяналар. Аның каравы ирләрдә — тикшеренү инстинкты, ә хатын-кызларда инде мәгълүм, куллану тәҗрибәсе булган гамәлләргә өстенлек бирү ныграк үскән.

Хәзерге Россиядә хатын-кызларның гомере ирләргә караганда якынча 12 елга озынрак. Гәрчә ирләр күбрәк туса да, алар сугышларда, производстводагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә ешрак һәлак була һәм ешрак авырый. Шулай итеп, безнең илдә картлар арасында хатын-кызлар күбрәк.

Көндәлек тормышта без «чын хатын-кыз» һәм «чын ир-ат» образларын үзебез формалаштырабыз һәм шул **рольләрне** өйрәнәбез.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гендер рольләре — ир-атка һәм хатын-кызга хас үз-үзләрен тоту модельләре, шулай ук әйләнә-тирәдәгеләрнең бу рольләрне башкаручыларга баглаган өметләре.

Гендер рольләре, әйтик, хатын-кызларга йорт хуҗалыгын алып бару, ә ирләргә гаилә башлыгы булу һәм акча табу тиешлеген билгели.

Аполлинарий Васнецовның «Мәскәү чоры борынгы рус йортының ак өендә» дигән картинасында хатын-кызның нинди гендер рольләре сурәтләнгән?

Йомгак ясыйбыз

Гендер — кешенең социаль җенесе (ир-ат яисә хатын-кыз).

Ул биологик билгеләр белән генә түгел, бәлки мәгълүм үз-үзен тотыш, киенү рәвеше, тормыш рәвеше, статус, психология һәм ир-ат белән хатын-кыз арасындагы башка аерымлыклар белән характерлана.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гендер, гендер рольләр

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Гендер», «гендер роль» дигән төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатып бирегез.

2. Кешеләр арасындагы гендерлык аерымлыклары ничек чагылыш таба? Ир-ат һәм хатын-кыз гендер рольләре чагылышына мисаллар китерегез.

3*. Ирләр турында еш кына «көчле җенес», ә хатын-кызлар турында «көчсез җенес» диюләрен ишетергә туры килә. Ни өчен шулай? Җавабыгызны дәлилләгез.

Практикум

1. Җөмләләрне күп ноктталар урынына сүзләр куеп тәмамлагыз.
«Ир-ат башлангычы ... лидерлыкка омтылу белән бәйле».
«Хатын-кыз башлангычы ... кайгырту белән бәйле».

2. Самуил Маршакның «Ниләрдән генә эшләнгән бу малайлар?» шигыреннән өзек укыгыз. Сез аның эчтәлеге белән килешәсезме? Үз карашыгызны дәлилләгез.

Из чего только сделаны мальчики?
Из чего только сделаны мальчики?
Из колючек, ракушек
И зелёных лягушек.
Вот из этого сделаны мальчики!

Из чего только сделаны девочки?
Из чего только сделаны девочки?
Из конфет и пирожных,
Из сластей всевозможных,
Вот из этого сделаны девочки...

3*. Тарих дәресләрендә алган белемнәрегезне, энциклопедия материалларыннан файдаланып, бирелгән темаларның берсенә кыска хикәя языгыз:
«Борынгы заманда — ирләр: тормышлары һәм киенү рәвешләре, җәмгыятьтә тоткан урыннары».
«Борынгы заманда — хатын-кызлар: тормышлары һәм киенү рәвешләре, җәмгыятьтә тоткан урыннары».

§ 14. Малайларның һәм кызларның үз-үзләрен тотышында аерымлыклар

Малайлар һәм кызларның үз-үзләрен тотышындагы аерымлыклар ни белән бәйле? Малайлар һәм кызлар тәрбиясе нәрсә белән аерыла?

Галимнәр күптән, кеше ир-ат яисә хатын-кыз булып туамы яисә яши-яши җитешәме, дип бәхәсләшәләр. Аларның кайберләре туганда малайлар белән кызлар психологик яктан бөтенләй аерылмыйлар дип саный. Социальләшү процессында гына берәүләре ир-атлык, икенчеләре, киресенчә, хатын-кызлык сыйфатлары җыелмасына ия була. Әгәр малайны бала чакта күлмәк киертеп һәм уенчык кибетендә машиналар түгел, курчаклар алсалар, ул ягымлы, нәфис һәм йомшак булып үсәр иде. Аның моның өчен барлык мөмкинлекләре бар, аларны бары үстерергә генә кирәк. Һәм, киресенчә, хатын-кыз булып туган кеше, тиешле тәрбия булганда, холкы һәм үз-үзен тотышы белән ир-атны хәтерләтергә мөмкин.

Башта галимнәр, киресенчә, ир җенесеннән булган сабыйны, күпме тырышсаң да, психологик яктан хатын-кызга әйләндереп булмый дип раслыйлар, чөнки ул ир-ат булып туган, аның баш мие ир-атныкы.

Без — төрле

Баксаң, безнең төрлелегебезгә кеше организмы эшләп чыгара торган гармоннар гаепле икән. Ир-ат һәм хатын-кыз гармоннары төрле. Алар безнең үз-үзебезне тотуыбыз, нәрсәләргә өстенлек бирүебез һәм безнең аерымлыкларыбыз өчен җаваплы. Бу нәрсә дигәнне аңлата? Әгәр балаларны кеше яшәми торган утрауда, аларның үз-үзен тотышына җитәкчелек итәчәк җәмгыятьтән һәм ата-аналардан аерым тәрбияләсәң, кызлар барыбер курчак белән уйнар, ә малайлар физик һәм интеллектуаль яктан бер-берсе белән ярышыр иде.

Кызыклы фактлар

Баш миендә акыл тупланган. Галимнәр ир-атлар һәм хатын-кызларның интеллектын сынап карау өчен тест тәкъдим итә. Хатын-кызларның чит телләрне яхшырак үзләштерүе, ә ир-атларның математикага сәләтлерәк булуы ачыклана.

Физик һәм психик яктан хатын-кызлар ир-атлардан чыдамрак. Бу карашны һәлакәткә очраган корабта күбрәк хатын-кызлар исән калуы раслый. Ир-атларга караганда хатын-кызлар ачлык, афәт, арыганлык, тетрәнүләр кебек организмның көчен суыра торган шартларны яхшырак кичерәләр.

Хатын-кызлар ир-атлардан яхшырак ишетәләр һәм югары ешлыктагы тавышларны яхшырак аералар. Хатын-кызлар мие бала кычкыруына программалаштырылган, ә ир-ат төнлә аны ишетмәскә, йокысыннан да уянмаска мөмкин. Аның каравы ирләргә батырлык, гаярьлек, мантыйклы фикер йөртү хас (абруйлы Нобель премиясе лауреатлары арасында ир-атлар күбрәк).

Үзенең җенесе турындагы күзаллаулар яшь ярымлык балада формалашып җитә инде. Ике яшьлек бала үз җенесен аера, әмма аерымлыкларны нигезли алмый әле. Өченче яшенә чыкканда, үз җенестәшләре белән уйнауга өстенлек бирү (башта кызларда, соңрак малайларда) ачыктан-ачык чагылыш таба. 3—4 яшьтә бала әйләнә-тирәдәге кешеләрнең

җенесен аера белә, әмма ешрак аны тышкы билгеләргә (әйтик, киемгә) кайтарып калдыра. 5 яшьләрдә балалар, аеруча малайлар, үз җенесе вәкилләре белән генә уйнауны хуп күрә.

Сез ничек уйлыйсыз, кызлар малайлардан нәрсә белән аерыла?

Малайлар һәм кызларны тәрбияләүдә һәм аларның үз-үзләрен тотышындагы аерымлыклар

Ике социаль җенес арасындагы аерымлыклар бала чакта ук башлана, әмма бу аерымлыкларны тәрбияләргә, һәм дөрес тәрбияләргә кирәк. Мондый тәрбия гендер социальләшүе дип атала.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гендер социальләшүе — кызларны һәм малайларны аларга тиешле ир-ат һәм хатын-кыз рольләрен башкару өчен тәрбияләү.

Гендер социальләшүе кешенең бала чагында ук башлана һәм бөтен гомере буена дәвам итә.

Кызлар яшьтән үк өстәл хәстәрләргә, сабый биләүләргә һ.б. өйрәнәләр. Ә малайлар машина төрләрен, юл йөрү кагыйдәләрен, төрле һөнәрләр үзләштерә.

Малайларны батыр — көчле, эшлекле, ә кызларны йомшак күңелле, яхшы хуҗабикә һәм кайгыртучан булыр-

га өйрәтәләр. Малайларны көч-егәр күрсәтүе, ярышырга һәрчак әзер торуы, ә кызларны тыңлаучанлыгы һәм кайгыртучанлыгы өчен мактыйлар.



Рәсемнәрдә кызларның һәм малайларның гендер социальләшүе ничек чагылыш таба?

Ата-аналар балаларына бик еш «чын ир-ат» дип кемнәрне атаулары һәм «чын хатын-кыз» нинди булырга тиешлеге турында сөйлиләр. Сез, кызлар белән малайлар арасындагы аерымлыктан чыгып караганда, иң четерек-ле дип танылган яшькә (10—11 яшь) кердегез. Малайлар әле бер дә тартынмыйча уенчык машиналар белән уйнап йөргән бер вакытта, шул ук яшьтәге кызлар төрле бию кичәләре, киемнәр турында сөйләшә, олылар темалары буенча фикер алыша. 10—11 яшьлек кызлар иннек-кершән белән актив кызыксына һәм тышкы кыяфәтләре турында уйлана башлый. Төрле бизәнү әйберләре, беләзек-алкалар, йөзек-муенсалар аларны бик кызыксындыра.

Кызыклы фактлар

Малайлар урамда яшь ягыннан катнаш зур төркемнәрдә ярыш уеннарында кызларга караганда ешрак катнашалар. Малайлар уеннары озаграк дәвам итә, алар уен вакытында ешрак әрләшәләр, әмма конфликтларны кызлар белән чагыштырганда тизрәк хәл итәләр.

Үсмерлек чорында капма-каршы җенес белән кызыксынуу, охшарга тырышу барлыкка килә. Димәк ки, бала тышкы кыяфәтенә, киеменә, үз-үзен тотышына зур игътибар бирә. Шәхси сөйкемлелек аеруча өстенлек ала.

5—6 нчы сыйныфларда башка җенес вәкиле белән кызыксыну үзенчәлекле чагылыш таба. Малайлар кызларны «кыерсыта» башлый, ә кызлар исә үз чиратында малайлардан зарлана, үзләре дә аларга төрле күңелсезлекләр китереп кенә тора. Әмма яшьтәшләрнең берсе икенчесенә шундый «илтифаты» ике якка да, һичшиксез, рәхәтлек бирә. Соңрак оялчанлык, тартыну һәм каушау барлыкка килә, алар капма-каршы җенестәге яшьтәшенә юри битараф булып кылану, мыскыллы мөнәсәбәт күрсәтү белән бергә бара.

7—8 нче сыйныфларда кызлар һәм малайлар арасында романтик мөнәсәбәтләргә күбрәк урын бирелә, алар берберсенә кыска хатлар яза, бер-берсен яшерен күрешүләргә чакыра башлый. Мондый мөнәсәбәтләр үсмерләрдә яхшыру теләге уята, аларда үз-үзләрен камилләштерү ихтыяҗы туа. Бу яшьтә балаларның күпчелеге үз-үзләрен тәрбияләү белән шөгыльләнә башлый.

Мәктәп фәннәре арасында малайлар өчен математика, физика, физкультура, информатика, ә кызлар өчен технология, әдәбият һәм тарих иң мөһиме дип санала. Шул рәвешчә, җенесенә карап, баланың һөнәр сайлавы да программалаштырыла.

Йомгак ясыйбыз

Уеннар, киемнәр һәм үз-үзен тоту рәвеше аша бала яшьтән үк үзен йә ир-ат, йә хатын-кыз җенесеннән булуын таный.

Малайлар һәм кызлар арасындагы аерымлыклар аларның табигый (физиологик) аерымлыклары, шулай ук тәрбия — гендер социальләшүе белән бәйле.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гендер социальләшүе

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Малайлар һәм кызларның үз-үзен тотышы арасындагы аерымлыкларның аларның табигатьтән килгән аерымлыклары һәм гендер социальләшүе белән бәйле булуын исбатлагыз.

2. Малайларны тәрбияләү кызларны тәрбияләүдән ни белән аерылырга тиеш?

3. Сезнең яшьтә үз-үзеңне малайларча тоту нәрсә дигәнне аңлата?

4. Сезнең яшьтә үз-үзеңне кызларча тоту ни дигәнне аңлата?

5*. Гендер социальләшүе кайчан башлана һәм кайчан тәмамлана? Сезнең яшегездә гендер социальләшүе нидә чагыла?

Практикум

1. Балачагыгызны искә төшерегез яисә кече туганнарыгызның үз-үзләрен тотышын күзәтегез дә биремнәрне үтәгез.

1) Балада ир-ат сыйфатлары тәрбияли торган уеннарга мисаллар китерегез.

2) Балада хатын-кыз сыйфатлары тәрбияли торган уеннарга мисаллар китерегез.

2*. Төрле халыкларда малайлар һәм кызларны тәрбияләү ничегрәк булуы турында мәгълүмат туплагыз һәм кыска хикәя әзерләгез. Бу халыкларда малайларны һәм кызларны тәрбияләүдәге уртаклыкларны һәм аерымлыкларны күрсәтегез. Сез ничек уйлыйсыз, алар ни белән аңлатыла? Энциклопедияләр һәм Интернет материалларыннан файдаланыгыз.

Ниндидер милләткә карау ни дигән сүз? Россиядә нинди халыклар яши? Россиядә һәм дөньяда төрле милләт кешеләре арасында мөнәсәбәтләр нинди?

Кешенең милләте, ягъни ниндидер бер милләткә каравы

Әгәр дә сездән кинәт кенә: «Сез кем?» — дип сорасалар, нәрсә дип җавап бирәсез? Сораштырып карагач: «Мин — кеше, малай (кыз), мәскәүле (казанлы һ.б.), укучы...» — дигән җаваплар ишетәбез. «Мин — рус (татар, калмык һ.б.)» — дигән җаваплар бик аз ишетелә.

Кешенең нинди милләттән булуы тормышта алай зур роль уйнамый, димәк?

Җавап бирергә ашыкмыйк әле. Еш кына шулай килеп чыга ки, кеше соңгы чиратта исенә төшергән әйбер аның өчен иң мөһиме була.

Барысы да үзен уңайлы хис итсен өчен, башка милләт кешеләре белән мөнәсәбәтләрне ничек төзергә?

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Милләт — нинди дә булса бер милләттән, халыктан булу.

Нинди милләттән булуың тормышта зур әһәмияткә ия.

Дәүләтләр миллилек буенча төзелә. Французлар Франция дәүләте төзегән. Бу аңлашыла — алар хәзер 60 миллионнан да күбрәк. Латышлар 1,5 миллионнан артмаган Латвия дәүләте дә бар. Кагыйдә буларак, бер үк дәүләттә төрле милләт вәкилләре яши.

Россия — дөньяда иң күп милләтле дәүләтләрнең берсе. Халыкның күпчелеген руслар тәшкил итә. Илебездә 180 нән күбрәк милләт яши. Алар арасында 1 миллионнан артык санлы халыклар бар, мәсәлән, татарлар (5 миллионнан күбрәк), чувашлар, башкортлар. Шулай ук берничә йөз кешелек кенә халыклар да яши, мәсәлән, орочлар (Хабаровский краенда), энецлар (Таймыр ярымутравындагы төп халык) һ.б.

Безнең илнең Төп законы — Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә һәр граждан үзенең милләтен үзе билгеләргә хокуклы. Бу аның ата-анасына, аны кем тәрбияләп үстерүгә, туган теленә, мәдәни нормалары нинди булуга, социальләшү барышында нинди традицияләр һәм кыйммәтләр үзләштерүенә бәйле.

Кешенең милләте һәм җәмгыятьтәге урыны

Тарихка борылып карыйк әле: дөньяда шундый хәлләр дә була, бер милләт икенчесе өстеннән хакимлек итә. Бу очракта беренчеләре җәмгыятьтә үзеннән-үзе икенчеләренә караганда югарырак урын били. Мәсәлән, инглизләр, французлар, немецлар һәм голландиялеләр XVII—XIX гасырларда Африканы һәм Көньяк-Көнчыгыш Азияне яулап ала. Алар бу җирләрдә үзләренең колонияләренә — үз дәүләтләренә бәйле территорияләргә нигез сала (әйтик, Алжир Франция колониясе була). Яулап алучылар югары урыннарда түрә, сәүдәгәр, сәнәгать предприятиесе хуҗасы була, ә төп милләтләр аларга хезмәт күрсәтә, мескен хәлдә яши.

XX гасырның икенче яртысында колонияләр бәйсез дәүләтләргә әверелә, җирле халык килмешәкләрне куып чыгара, үз илләрендә иң югары вазифаларны били башлый. Африкадагы һәм башка халыкларның аерым вәкилләре социаль хәле уңай якка үзгәрә.

Хәзерге тормышта хәлләр башкача. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, көндәлек тормышта, эштә һәм көнкүрештә төрле милләт кешеләре бер-берсенә ышаныч һәм түземлелек, милли мәдәниятләренә, гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карый.

Законга мөрәҗәгать итик

Россия Федерациясе Конституциясе
19 нчы статья
2. Җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына (...) карамастан, дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген гарантияли. Социаль, расачыл, милли, тел яисә дини билгеләренә карап, гражданнарның хокукларын теләсә ничек чикләү тыела.

Сез ничек уйлыйсыз, нигә «Җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына карамастан, ... кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеге...» илебез халыкларының тату яшәвен тәэмин итүнең иң яхшы ысулы булып тора?

Төрле милләтләрнең тату яшәве Россия дәүләтчелеге үсешендә һәрвакыт төп фактор булды.

Милли аерымлык нәрсәдә чагыла

Һәр халык артына озын, бик авыр, ләкин вакыйгаларга бай тарих яшеренгән, шуңа да төрле халыклар — төрле гореф-гадәтләр, нормалар һәм кыйммәтләр ул. Болар барысы бергә халыкның мәдәниятен тәшкил итә. Шуңа да **милли үзенчәлекләр** барыннан да элек мәдәни аерымлыкларда чагылыш таба.

Европалылар, америкалылар һәм башка халыклар, ашаганда, пычак, чәнечке кулланалар, өстәл артында урындыкта утыралар, йокларга ятканда, баш астына мендәр куялар. Япон кешесе чүмәшеп ашый. Көнчыгышның башка халыклары келәмгә утыралар. Япон ике таякчык ярдәмендә ашый, ә Малайзия кешесе, йокларга ятканда, муен астына агач эскәмия куя. Төньяк Америка индеецлары, гомумән, гамакта йоклый. Күнегелгән яшәү рәвеше гореф-гадәткә әверелә, ә традицияләрдән халыкның мәдәнияте, аның үзенчәлеге барлыкка килә.

Кунакчыллык гадәте Төньяк Кавказдагы барлык халыкларда киң таралган. Йорттагы иң яхшы ризыкны, иң уңайлы ятакны кунакка биргәннәр. Йортка килгән һәркем кунак булып саналган. Ул төнлә белән килеп керсә дә, шатланып каршылаганнар. Гаиләнең һәр әгъзасы — олымы ул, кечеме — кунакка игътибарлы булган.

Мәдәни үзенчәлекләр төрле халыкларның тормыш шартларын чагылдыра, аларның тарихи гореф-гадәтләре һәм характеры турында сөйли. Шулай итеп, дөньяның төрлелеге ачыла, ә халыклар кызыклырак була бара. Милли үзенчәлекләрне хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк.

Милләтләр үзара аралашырга тиеш

Дөньяның төрлелеге күпсанлы сәяхәтләргә китерә, ә безнең заманда тулы бер тармак — туризм барлыкка килде. Кешеләр башка халыкларның гореф-гадәтләре, аларның тарихи ядкярләре белән танышу өчен байтак акча түлиләр.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Танып белү туризмы — табигать, тарих һәм мәдәният истәлекләре, җирле халыкның көнкүреше һәм традицияләре, халык һөнәрләре һәм кәсепләре, фән, мәдәният, сәнәгать һ.б. казанышлары белән танышу өчен төрле урыннарда булу максатларында туристик йөрүләр, сәяхәтләр, экскурсияләр, сәфәрләр.

Туризм киңрәк үсә барган саен, халыклар бер-берсен тулырак аңлый, тынычлыкка һәм күршеләр белән татулыкка омтылыш көчлерәк чагыла. Милләтләр сугышмый,

ә бер-берсе белән аралаша. Алар чик буйларында зур-зур армияләр тупламый, ә тауар алмаша, хезмәт күрсәтешә һәм мәдәни кыйммәтләр тәкъдим итә.

Әлеге фотосурәтләр авторларының нинди халык-лар тормышы белән танышуын чамалап карагыз. Җавабыгызны нигезләгез.

Туристлар — башка илләрдәге кунаклар ул. Алар үз сәфәрләреннән иң яхшы тойгыларны алып китәләр, ә өйләренә кайткач, башка халыкларның гореф-гадәтләрен һәм кунакчыллыгын мактыйлар, шуның белән алар арасындагы тынычлык мөнәсәбәтләрен ныгытуга ярдәм итәләр.

Кайбер халыклар, бигрәк тә казылма байлыклардан һәм алга киткән сәнәгатьтән мәхрүм булганнары, тулысы белән туризм хисабына яши.

Шулай итеп, туристлар — чын мәгънәсендә тынычлык илчеләре алар. Шуңа да мәдәният алмашуның бу төре белән бала чактан ук танышырга кирәк, милли аерымлыкларны аңлау һәм аларга хөрмәт белән карау яшьтән формалашсын.

Төрле халыкларның мәдәни үзенчәлеге белән танышу **миграция** ярдәмендә дә бара.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Миграция — кешенең яшәү урыны белән бәйле рәвештә бер урыннан икенчесенә (бер ил чикләрендә) яисә бер илдән икенчесенә күченүе.

Үткән заманнардан бирле халыклар бер территориядә формалашып, еш кына дөньяның башка якларына

күченгәннәр, бер яисә берничә халык белән бәйләнешкә кергәннәр.

Кешеләр бер илдән икенчесенә сугышлар һәм табигать бәла-казаларыннан качып китә, үз Ватанында алырга мөмкин булмаган белем эстәргә бара, эш эзләп килә.

Тарихка халыкларның янәшә тыныч яшәүләре һәм сугышып торулары мәгълүм. Мәсәлән, борынгы империяләр күрше илләрне басып алганнар.

Милли конфликтлар булмасын өчен, башка халык вәкилләренә хөрмәт белән карау зарур. Бу **толерантлык** була.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Толерантлык — ят яшәү рәвешенә, кешеләрнең хисләренә, гореф-гадәтләренә, ышанулары һәм фикерләренә түземле караш.

Сезнең һәркайсыгыз халыклар дуслыгы урнаштыру эшенә үз өлешен кертә ала. Моның өчен нишләргә кирәк соң? Башка халыклар гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә өйрәнергә, аларның дөньяга карашын һәм тормыш кыйммәтләрен аңларга, мыскыллап сөйләшмәскә, аларны кунакка чакырырга, үз халкың тормышы һәм мәдәнияте белән таныштырырга.

Һәр милләт башка халыкларга нәрсә дә булса тәкъдим итә һәм, үз чиратында, алардан нигә дә булса өйрәнә ала

Йомгак ясыйбыз

Милләттән булу — кешенең нинди дә булса милләт һәм халыкка каравы, шунда саналуы ул. Россия законнары буенча кеше үз милләтен үзе билгели. Россия — дөньядагы иң күп милләтле дәүләтләрнең берсе. Төрле милләт кешеләре бер-берсенең гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә тиеш.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Милләт, танып белү туризмы, миграция, толерантлык

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Бер халык икенчесеннән нәрсәсе белән аерыла?

2. Сез үзегезнең нинди милләткә каравыгызны ничек билгелисез? Нигә шулай икәнен аңлатыгыз.

3. Туризмның ничек итеп төрле милләтләр арасындагы игелекле мөнәсәбәтләрен үстерүгә ярдәм итүен анык мисалларда дәлилләгез.

4. «Милләттән булу», «танып белү туризмы», «миграция», «толерантлык» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

Практикум

1. Россия территориясендә яшәүче кайсы халыкларның гореф-гадәтләре турында белергә теләр идегез? Алар турында мәгълүмат туплагыз, энциклопедия һәм Интернет материалларыннан файдаланыгыз.

2*. Сез сәяхәт иткәндә, берәр җиргә барганда һәм экскурсиядә башка халыклар мәдәнияте турында нинди яңалык белдегез? Компьютерда презентация әзерләгез.

§ 16. Россиянең яшь гражданнары

Нәрсә ул гражданлык һәм кем ул граждан? Паспорт нигә кирәк? Кеше хокуклары нигә табигый дип атала? Хокуклар һәм бурычлар арасында бәйләнеш бармы?

Россия гражданы

Кешенең тормышы нинди мизгелдән башлана? Тууга башлангандай тоела. Әмма баланың йөрәге әнисе карынында ук күпкә алдан тибә башлый. Менә шул вакыттан дәүләт үзенең булачак **гражданы** турында кайгырта башлый.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Граждан — законлы нигездә билгеле бер дәүләт кешесе.

Гражданлык — кеше һәм дәүләтнең үзара хокуклары һәм бурычларында чагылган сәяси-хокукый багланышлары; кешенең билгеле бер дәүләтнеке булуы.

Россия законнары нигезендә әгәр дә яңа туган баланың әти-әнисе Россия гражданнары икән, ул үзеннән-үзе Россия Федерациясе гражданы була. Моннан тыш: беркем дә, беркайчан да, теләсә нинди хәлдә дә сезне Россия гражданлыгыннан мәхрүм итә алмый.

Законга мөрәҗәгать итик

Россия Федерациясе Конституциясе
61 нче статья

1. Россия Федерациясе гражданы Россия Федерациясеннән читкә сөрелә яисә башка дәүләткә тапшырыла алмый.

2. Россия Федерациясе үз гражданнарына аннан читтә яклауны һәм ярдәмне гарантияли.

? Россия Федерациясе гражданы чит илдә булганда дәүләт ягыннан яклау тапкан тормыш хәленә мисаллар китерегез. (Аларны әзерләгәндә Интернет, телевидение, радио, газета материалларыннан файдаланыгыз.)

Гражданлыкны таныклаучы һәм моның белән бәйле барлык өстенлекләрне алуга хокукны раслаучы документ булып **паспорт** тора. Россиядә паспортны 14 яшьтә алалар.

Бу сезнең гражданлыкны раслаучы икенче документ. Беренчесе, үзегез белгәнчә, — туу турында таныклык.

Паспорт алгач, Россиянең яшь гражданы эшкә урнашу хокукына ия була, хезмәт хакы алырга мөмкин. Моннан тыш балигъ булмаган россиялеләр, әти-әниләре рөхсәтен алып, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, банкта үз исәп-хисабын ачарга, шулай ук үзенең ачышын, уйлап табуын теркәргә, үзләре иҗат иткән әдәби яисә музыкаль әсәрне теркәргә, ягъни интеллектуаль милеккә ия булу хокукы турында белдерергә хокуклы.

Гражданның хокуклары һәм бурычлары бар. Кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм бурычлары Россия Федерациясе (РФ) Конституциясендә санап үтелә. Мәсәлән, граждан законнарны (дәүләт хакимиятенең башкару өчен мәҗбүри карарларын) үтәргә, салым түләргә, үз Ватанын якларга, табигатьне сакларга һәм аның байлыкларына сакчыл карарга тиеш, болар — **бурычлар**.

Табигать турында кайгырту — Россиянең барлык гражданнары бурычы

Яшәүгә, фикер йөртү ирегенә, белем алуга хокук, ял итүгә, милеккә, хезмәткә хокук, үз дәүләтенә идарә итүдә катнашу һәм башкалар — болар **кеше хокуклары**.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Кеше хокуклары — дәүләт тарафыннан сезнең ихтыяҗларга туры килүче һәм башка кешеләр теләгенә каршы килмәгән бар нәрсәне эшләү мөмкинлеген тәэмин итү.

Бериш хокукларны кеше билгеле бер яшькә җиткәч кенә ала. Мәсәлән, фәкать 18 яшь тулгач кына дәүләт белән идарә итүдә катнашырга — хакимият органнарына сайлауларда тавыш бирергә яисә үзеңә сайланырга мөмкин.

Кеше тумыштан ук нинди хокуклар ала?

Кеше тумыштан алган хокуклар **табигый** дип атала. Табигый хокуклар һәркемгә хас. Алар бернинди шартларда да тартып алынырга тиеш түгел.

Яшәүгә хокук, шәхес абруена хокук, иреккә хокук, шәхси кагылгысызлык хокукы — шундыйлардан.

Яшәүгә хокук — кеше хокукларының иң мөһиме

Законга мөрәҗәгать итик

Россия Федерациясе Конституциясе

20 нче статья

1. Һәркем яшәргә хокуклы...

21 нче статья

1. Шәхеснең абруе дәүләт тарафыннан саклана. Берни дә аны төшерү өчен нигез була алмый.

2. Беркем дә газаплауларга, көч куллануга, башка рәхимсез яисә кешелек абруен кимсетерлек мөнәсәбәткә яисә җәфага дучар ителмәскә тиеш...

22 нче статья

1. Һәркем иреккә һәм шәхес кагылгысызлыгына хокуклы.

2. Кулга алу, сак астына алу һәм сак астында тоту бары тик суд карары буенча гына рөхсәт ителә...

23 нче статья

1. Һәркем шәхси тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, үзенең намусын һәм кешелек дәрәҗәсен яклауга хокуклы.

2. Һәркем хат язышу, телефон аша сөйләшүләр, почта, телеграф һәм башка төрле хәбәрләшүләр яшеренлегенә хокуклы. Бу хокукны чикләү бары тик суд карары нигезендә генә рөхсәт ителә.

Россия Федерациясе Конституциясе текстыннан файдаланып, «шәхес абруе»ның ни икәнлеген аңлатыгыз. Ул кешегә нигә кирәк?

Кеше гомере — иң югары кыйммәт. Дәүләт үзенең суд системасы һәм хокук саклау органнары аша кеше хокукларын яклый.

Белем алуга хокук

Белем алуга хокук — сезнең иң зур хокукларыгызның берсе — түбәндәгеләргә хокукларның бөтен бер җыелмасын тәшкил итә:

- түләүсез урта белем алуга;
- мәгариф учреждениесен сайлап алуга һәм билгеләнгән стандартларга туры китереп укытуга;
- иминлекне гарантияләүче шартларда укытуга;

• югарырак дәрәҗәдәге мәгариф учреждениеләренә кергәндә башкалар белән тигез хокукларга;

• мәктәпкә идарә итүдә катнашуга;

• өстәмә (шул исәптән түләүле) мәгариф хезмәтләре алуга;

• мәктәп китапханәсе фондларыннан укыту әсәрләре белән тәэмин ителүгә;

• мәгариф учреждениеләре персоналы (укытучылар, директор) ягыннан ихтирамлы мөнәсәбәткә;

• белемне (төп гомуми) туган телдә алуга, шулай ук уку-укыту телен булган мөмкинлекләрдән чыгып сайлауга.

Закон буенча мәктәп укучысы уку йортын, түгәрәк һәм секцияләрне үз теләге буенча сайлап алырга хокуклы.

Укытучылар укучыларның шәхси тормышына тыкшына алмый, чөнки Россиянең һәр гражданы (шул исәптән мәктәп укучылары да) шәхси тормышы кагылгысызлыгына ия. Ләкин шул ук вакытта укырга дигән конституциячел бурычны да онытырга ярамый.

Шәхси тормышның кагылгысызлыгы чикләре түбәндәгеләрне күздә тота: шәхси һәм гаилә серләре, үзара язышу һәм телефоннан сөйләшү серләре, гаилә мөнәсәбәтләре, дуслык бәйләнешләре, симпатия һәм антипатия, кемгәдер бәйле булу, мавыгулар.

Укучы тормышының бу даирәләренә укытучы керә алмый, әмма үзенең күзәтүләрен һәм шикләнүләрен ата-анага җиткерергә хокуклы, хәтта тиеш тә әле.

Беркем дә чит язуларны укырга хокуклы түгел, чөнки ул — шәхси сер. Ләкин шунысын да истә тотарга кирәк: дәрестә язулар тапшыру — дисциплина бозу ул.

Белем алу хокукын сезгә дәүләт гарантияли.

Дәүләт һәм гражданның үзара бурычлары

Әгәр дәүләт кеше турында кайгыртуны үз өстенә ала икән, димәк, кеше дә дәүләт алдындагы бурычын үтәргә тиеш. Әгәр белем алу хокукы бирелсә, укучы, шуннан файдаланып, яхшы укырга бурычлы. Бу — дәүләтнең сезнең укуыгыз өчен акча түләвеннән килеп чыга. Уку иҗади хезмәткә әверелә — син үзеңнең сәләтеңне үстерәсең,

белемеңне арттырасың, соңрак аларны җәмгыять мәнфәгатьләрендә кулланасың.

Башка хокуклар белән дә шулай ук. Дәүләт аларны тикмәгә генә бирми. Һәр кешенең хокуклары аның үзе һәм башкалар өчен җаваплылыгы кадәр үк.

Йомгак ясыйбыз

Кеше тумыштан ук табигый хокукларга ия, аларның иң мөһиме булып яшәү хокукы тора. Кеше гомере — иң зур кыйммәт. Белем алуга хокук — баланың иң мөһим хокукларының берсе. Дәүләт үз гражданнарының хокукларын якларга тиеш, ә гражданнар — дәүләт алдында билгеле бер йөкләмәләрен үтәргә бурычлы.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гражданлык, гражданн, кеше хокуклары, паспорт

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Түбәндәге төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатыгыз: «граждан», «гражданлык», «кеше хокуклары», «паспорт».
2. Тарих дәресләрендә алган белемнәрне кулланып, дәүләтнең нәрсә икәнлеген аңлатыгыз.
3. Кеше нинди хокукларны тумыштан ук ала? Җавап биргәндә, Россия Федерациясе Конституциясе өземтәләреннән файдаланыгыз (116 б.).
4. Сез инде кешенең нинди хокукларыннан файдаланасыз?
5. Белем алуга хокук ни өчен сезнең төп хокукларыгызның берсе?
6. Ни өчен паспортны «тормышка юллама» дип атыйлар?

7*. Уйлап карагыз әле: гражданлык һәм ватанпәрвәрлек арасында нинди уртаклык бар?

Практикум

1. Үзегезнең өлкән туганнарыгыз арасында сораштыру үткәрегез һәм аларның нинди хокуклардан файдалануын ачыклагыз.

2. Шарль Перроның «Кызыл башлык» әкиятен укыганыгыз бармы? Әйтегез әле, Соры Бүре баланың нинди хокукларын бозарга ниятли?

3. Түбәндәге җөмләне тәмамлагыз:
«Мин, Россия гражданы буларак, яхшы укырга бурычлы, чөнки...»

4*. Сезнең хокуклар һәрчак сакланамы? Ничек уйлыйсыз, алар нигә бозыла? Алар бозылмасын өчен сез нишли аласыз?

§ 17. Сәламәт яшәү рәвеше

Сәламәт яшәү рәвеше нигә кирәк? Озак яшәүнең сере нәрсәдә?

Безгә сәламәтлек нигә кирәк? Авырмас өчен, һәрвакыт яшь, хәрәкәтчән булырга, күңел күтәренке булсын дип. Әгәр кеше сәламәт булмаса, аның тормыш сыйфаты начарлана. Исәнлекләренә җиңел карау нәтиҗәсендә кешеләр үз гомерләрен үзләре үк кыскарта.

Хәзерге заман балаларының сәламәтлеге

Сәламәт яшәү рәвеше балалар өчен бигрәк тә мөһим — сезнең организм әле үсә һәм формалаша. Әгәр сәламәтлегегез турында кайгыртмасагыз, гомерлеккә калырлык чирләр алырга мөмкин.

Кайбер табиблар балаларның сәламәтлеге елдан-ел какшый бара дип саный. Бүгенге балалар 10 ел элек туган балалардан физик яктан калышалар. Аларның көче азрак, акрынрак йөгерәләр һәм тизрәк арыйлар. Яшүсмерләрнең 45 проценты иртәнге ашны өйдә дә, мәктәптә дә ашамый. Нәтиҗәдә ашказаны авырулары килеп чыга. Алар бөтен нәрсәне берьюлы эшләргә ашыга, ашаганда телевизор карый, телефоннан сөйләшә, газета караштыра.

Медиклар әйтүенчә, балаларның еш кына авырлыгы җитми, хроник авырулары арта бара. Мондый хәл Россиядә

генә түгел, дөньяның башка илләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән, Кытайда 7—12 яшьлек балаларның өчтән бере начар күрә. Бу нидән килеп чыга соң?

Кызыклы фактлар

Россиядә уку елы башка илләрдәгедән кыскарак. Американлыларга (36 уку атнасы), европалыларга (39 атна) һәм бигрәк тә Көнчыгыш Азиядәгегә (44 атна) караганда бездәге уку елы (34 атна) кыскарак булса да, Россия укучылары арасында да сәламәтлек проблемасы бар.

Ә эш яшәү рәвешендә икән! Ул сәламәт булырга тиеш.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Сәламәт яшәү рәвеше — авыруларны кисәтү һәм сәламәтлекне саклау максатындагы яшәү рәвеше.

Сәламәт яшәү рәвешенең өлешләре

Сәламәт яшәү рәвеше төшенчәсенә җитәрлек кадәр физик активлык, менюның балансланган булуы, гигиена кагыйдәләрен саклау, теләсә нинди артык нәрсәләрдән баш тарту һәм, әлбәттә, чыныктыру процедуралары.

Сәламәт яшәү рәвешен тәшкил итәләр:

балаларда кечкенәдән үк сәламәт күнекмәләр тәрбияләү;

тирә-як мохит: чиста һава, иминлек һәм уңайлы тормыш шартлары;

зарарлы гадәтләрдән: тәмәке тартудан, наркотиклардан, алкоголь кулланудан баш тарту;

туклану: чамалап кына һәм сыйфатлы итеп, натураль тук-лану продуктлары куллану;

хәрәкәтләнү: физик яктан актив тормыш, моңа яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып ясаган физик күнекмәләр дә керә;

организм гигиенасы: шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү, беренче ярдәм күнекмәләрен белү, чыныгу;

уңай кәеф һәм фикерләү, оптимист булу;

үз хисләреңне тыя белү, проблемаларны үзең хәл итү.

Спорт, саф һава, яхшы кәеф һәм дустанә мөнәсәбәт — сәламәт яшәү рәвешен шулар тәшкил итә

Әгәр сез үзегезнең көн тәртибен булдырырга уйласагыз, ял вакыты белән эш вакытын төгәл бүлегез. Алар чиратлашып барырга тиеш. Физкультура белән шөгыльләнү тәнгә генә түгел, психикага да уңай тәэсир итә.

Организмны чыныктыру төрле авыруларны кисәтергә ярдәм итә. Әгәр чынығасыз икән, сезоны җиткәч, салкын тиеп авырудан котылырсыз.

Һәм иртән зарядка ясагыз! Туклану режимын планлаштырыгыз. Йокыгызны туйдырып, уятмыйча гына торырга гадәтләнегез. Үзегездә оптимизм тәрбияләгез.

Белгечләр фикеренчә, дөрес яшәү рәвеше гомерне 10—15 елга озайта ала.

Сәламәтлек һәм озак яшәү

Күпләргә үз сәламәтлекләрен гомер буе саклаулар, картайгач та яшь чагындагы кебек хәрәкәтчән һәм көләч булырлар кебек тоела. Әмма статистика башканы күрсәтә: картайгач та сәламәтлекне саклап калу ихтималы 30 процентган да кимрәк.

Кызыклы фактлар

Белгечләр бәяләвенчә, сәламәтлек 25 процентка әйләнә-тирә мохитнең торышына, 10 процентка — медицина хезмәте дәрәҗәсенә бәйле, 15 проценты нәселдәнлек белән билгеләнә һәм 50 процентка кешенең яшәү рәвешеннән тора.

Үз организмын дөрес булмаган яшәү рәвеше белән озак һәм уйламыйча сынаган кеше иртәме яки соңмы (хәзер ул, кагыйдә буларак, тизрәк була) организмның саклану ресурсларын тулысынча юкка чыгара һәм нәтиҗәдә җитди авыруларга дучар була.

Авыру — дөрес булмаган яшәү рәвеше нәтиҗәсе ул.

Озын гомерлелек — бик күп еллар буена сәламәт яшәү рәвеше үрнәге. Моның өчен тау һавасы, натураль продуктлар яисә көндәлек авыр физик күнекмәләр мәҗбүри түгел.

Бүген дөньяда кимендә 100 мең кеше үзенең 100 яшен билгеләп үтте, ә 450 кеше 110 яшь чиген узып китте. Алар кебек булырга телисезме?

Соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, яшәү озынлыгының өчтән бере генә яхшы геналар белән билгеләнә. Калган өчтән икесе яшәү рәвешеннән һәм дөньяга караштан тора — озак яшәүчеләрнең, гәрчә алар төрле континентларда яшәсәләр дә, бу факторлары бик охшаш. Япониядәге, Италия һәм Америкадагы озын гомерле кешеләрнең яшәү рәвешен карап, *демографлар* — халыкны һәм аның санын өйрәнүче галимнәр — шундый нәтиҗәгә килгән.

Кавказ халыклары арасында озак яшәүчеләр күп. Ләкин Япониядә алар тагын да күбрәк. Бигрәк тә Окинава префектурасында. Хәтта «Окинавача сәламәт яшәү рәвеше» дигән гыйбарә дә бар. Аның сере — ашыкмауда. Окинавада берәү дә кул кушырып утырмый, әмма беркая ашыкмый да, хәтта эшкә барырга да. Барысын да яратып башкаралар. Буш вакытларында өлкән буын кешеләре чәчәк үстерү белән шөгыльләнә.

Окинавалылар һәрвакыт дустанә һәм тормыш сөючән. Алар өчен дуслык зур әһәмияткә ия, картлар бу хисне гомер буена саклап килә.

Кызыклы фактлар

Япониянең Окинава утравында табиб һөнәренә ихтыяҗ юк диярлек, монда яшәүчеләр баһадир сәламәтлегенә ия.

Утрауда яшәүчеләр һәр көнне иртәнге гимнастика белән башлый, гаилә белән төшке ашка җыелу, бергәләшеп чәй эчүләр дә «мәҗбүри программага» кергән, мәнфәгатьләр буенча клубларда булу да каралган. Окинавалылар фикеренчә, буыннан буынга күчеп килүче гореф-гадәтләрне хөрмәт итү бик зур әһәмияткә ия, чөнки алар ниндидер магиягә ия һәм көч-куәт бирергә сәләтле. Һәр буын инде булган традицияләргә яңаларын өстәргә тырыша.

Окинава — мәңгелек җәй патшалыгы

Утрауда физик активлык — һәр иртәдә тешләрне чистарту кебек үк табигый. Ул гимнастиканы, халык биюләрен һәм сугышчан сәнгатьне (Окинава — карате туган урын) эченә ала.

Окинавалылар артык туйганчы ашарга гадәтләнмәгән һәм тәлинкәләрен алданрак алып куялар. Чама хисе — озын гомерле булу ачкычы.

Утраулыларның девизы: «Кайгырма!» Бу гади сүзләр генә түгел. Сораштырулар күрсәткәнчә, Окинавада яшәүче олы кешеләрнең күбесе тормышларыннан канәгать. Алар язмышлары күктә үк билгеләп куелган һәм шуңа да без үзгәртә алмаган нәрсәләргә үз мөнәсәбәтебезне үзгәртергә кирәк дип инана.

Йомгак ясыйбыз

Сәламәт яшәү рәвеше тормыш сыйфатын һәм гомер озынлыгын билгели. Дөрес туклану, физик көч кую, эш һәм ял вакытын чиратлаштыру, яхшы кәеф һәм оптимизм, зарарлы гадәтләр булмау — болар бала организмы өчен бик мөһим.

Баланың сәламәт яшәү рәвеше гаиләдән, шәхесне дөрес тәрбияләүдән тора.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Сәламәт яшәү рәвеше

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Нәрсә ул сәламәт яшәү рәвеше? Сәламәт яшәү рәвешенең төп өлешләрен атагыз.

2. Озын гомерле булуның нигә сәламәт яшәү рәвеше нәтиҗәсе икәнлеген аңлатыгыз.

Практикум

1. Үзегезнең көн тәртибен төзегез һәм аны игътибар белән өйрәнегез. Сезнең яшәү рәвешен сәламәт дип әйтеп буламы икәнлегенә нәтиҗә ясагыз. Әгәр булмаса, аны ничек үзгәртергә икәнен уйлагыз, барысы да үзегезнең кулда ич.

2. Сезнең туганнар һәм танышлар арасында озын гомерлеләр булса, сорашыгыз: озак яшәүнең сере нәрсәдә икән?

3*. Сезнең яшьтәге китап һәм кинофильм геройлары арасында, алар сәламәт яшәү рәвеше алып бара, дип әйтерлекләре бармы? Булса, аларны атагыз.

4*. Окинавадагы озын гомерле кешеләр мисалында озак яшәү өчен кирәк булган шартлар исемлеген төзегез. Әлеге исемлектән сез кайсын куллана алыр идегез. Хәлне үзгәртү өчен үзегез нәрсәләр эшли аласыз?

§ 18. Тормыш иминлеге

Үз тормышыңны ничек куркынычсыз итәргә? Начар гадәтләрнең зарары нәрсәдә?

Куркыныч һәм куркынычсызлык

Дөнья шулай төзелгән инде, кешегә, бигрәк тә балага, һәр адымда **куркыныч** яный.

> **Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!**
>
> **Куркыныч** — кеше гомеренә зарар китерергә мөмкин булган күренеш.

Суда туңарга, батарга, үткен ташларга һәм пыяла ватыгына аягыңны кисәргә, кояш суктырырга мөмкин. Урамда автомобильгә тапталырга, караклар һәм көчләүчеләр корбаны булырга, авыруга китерүче микроблар эләктерергә була. Мәктәптә сугыш чукмарлары, текә баскычлар бар. Хәтта өйдә дә — кухняда, йокы бүлмәсе яисә коридорда — шук һәм игътибарсыз баланы бик күп күңелсезлекләр көтә. Дачага барсагыз, анда агачлар гына түгел, төрле куркынычлар: тырма, чалгы, электр үткәргечләр, тирән сулы буа, агулы бөҗәкләр һәм үсемлекләр көтә.

Балалар аттракционы бигрәк тә куркынычлы, җитмәсә, сез анда үзегез генә барырга яратасыз. Урыннарыннан төшкәндә, балалар егыла, төрле бикләргә һәм тоташтыргычларга кул-аякларын тыга, таган һәм карусель туктаганчы ук сикереп төшәргә маташа — олылар күреп тә өлгерә алмый.

Аттракционга олыларга ияреп кенә барырга, ә суны рөхсәт ителгән урыннарда гына керергә мөмкин

Урам аркылы ничек дөрес итеп чыгарга?

Куркынычлар күп, ләкин аларга каршы көрәш ысуллары да бар. Һәм сез аларны беләсез дә.

Судагы куркынычны кисәтү өчен, йөзәргә өйрәнергә, ә өйрәнгәч, төбе һәм яры чиста булган, рөхсәт ителгән урында коенырга кирәк. Урамда йөрү кагыйдәләрен саклау, таныш булмаган кешеләр белән аралашмау зарур. Мәктәптә укучылар тәртибе кагыйдәләрен үтәү дә җитә. Өйгә кайткач, әлбәттә инде, беренче эш итеп кулларны сабынлап юабыз.

Әлеге гади генә кагыйдәләрне үтәү дә тормышны имин итә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Иминлек, куркынычсызлык — кешенең яшәве өчен мөһим мәнфәгатьләренә зыян китерергә сәләтле нинди дә булса куркыныч һәм янаулар булмау.

Иминлек кешенең төп ихтыяҗларына керә, ә гомерне һәм сәламәтлекне саклауны галимнәр шәхес мәнфәгатьләренең иң беренчесе һәм мөһиме дип атыйлар.

Ләкин күп кенә куркыныч үзебездән үк килеп чыга да. Алар җавапсызлыкка һәм зарарлы гадәтләргә бәйле.

Зарарлы гадәтләр

Игътибарлы булыгыз! Начар гадәтләр нәкъ менә яшүсмер чакта башлана да. Күпчелек яшүсмерләр олыларга охшарга тели — аларның гадәтләрен кабатлый. Ләкин бала организмы алкоголь, тәмәке тарту һ.б. кебек өстәмә авырлыкларга әзер түгел әле. Олыларның организмы көч җыеп өлгергән инде һәм үсештән дә туктаган, ә балада ул һаман үсә, һаман үзгәрә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гадәт — кешегә хас тәртип рәвеше. Ул ихтыяҗ характеры ала (мәсәлән, иртәләрен теш чистарту).

Гадәт файдалы һәм зыянлы була. Иртә белән зарядка ясау, ашау алдыннан кулларны юу, әйберләрне җыеп кую, көнгә ике тапкыр тешләрне чистарту һ.б. **файдалы гадәтләргә** керә.

Иртән ашау гадәте дә файдалыга керә. Иртәнге аш — көнлек туклануның иң мөһимедер, мөгаен. Галимнәр иртәнге ашны яраткан балалар һәм яшүсмерләр акыл дәрәҗәсе буенча югарырак тора дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Иртән ашау хәтерне ныгыта һәм өлгерешне яхшырта икән. Иртә белән ашамыйча гына килергә гадәтләнсәң — үз-үзеңә зыян гына китерәсең.

Зыянлы гадәтләр — алар файдасыз гына түгел, хәтта зарарлы икәнен дә белә торып, кешеләр һаман кабатлый торган, киң таралган гамәлләр. Аларны әле **үтергеч гадәтләр** дип тә атыйлар. Сез ничек уйлыйсыз, нигә шулай әйтәләр?

Сүгенүне, тәмәке тартуны, алкоголь куллануны, токсикоманияне, наркотиклар куллануны, ягъни кешенең рухи һәм физик сәламәтлеген җимерүче бар нәрсәне зарарлы гадәтләргә кертеп саныйлар. Зарарлы гадәтне хәтта тимерне дә әкрен генә ашаучы күгәрек белән чагыштырырга була. Алар да безнең организмны, хәтта җаныбызны да кимерә.

Компьютер каршында озак вакыт үткәрү — шулай ук зыянлы гадәт

Кайбер зарарлы гадәтләр, әйтик, наркомания, хәтта беренче куллануданн соң ук наркотикларга көчле бәйлелек тудырырга сәләтле. Шундый адымга баручы кеше үзенә-үзе үлем хөкеме чыгара дияргә мөмкин. Менә шуңа да наркоманиягә каршы көрәшүчеләр арасында элеккеге наркоманнар күп, алар бу гадәтнең нәрсә икәнен беләләр инде.

Кызыклы фактлар

Россиядә наркомания белән авыручыларның уртача яше — 23. Тормыш озынлыклары беренче тапкыр куллану очрагыннан алып 10 елдан да артмый. Наркотик сатучылар наркоманнар сәламәтлеге һәм исәнлегендә бик зур акчалар эшли, ә үзләре гарипләндергән кешеләрнең язмышы аларны бөтенләй кызыксындырмый.

Һәм менә тагын бер куркыныч. Галимнәр начар гадәтләрнең төркем эчендә җиңелрәк үзләштерелүен ачыклаган. Нәкъ менә яшүсмер чакта бала йорт учагыннан урам киңлегенә омтыла. Анда бит дуслары җыела.

«Дуслар» сүзен куштырнаклар эченә алыйк. Чын дуслар күп булмый — бер-ике, кайчакта — өч. Ә дус дип аталучылар, төгәлрәк әйткәндә — очраклы танышлар, бик күп була.

Чын дус начарга өйрәтмәс, ә очраклы таныш сезнең гомер өчен җаваплы түгел ул. Аларны аерып торган сыйфат — тәкәбберлек һәм мактанчыклык. «Берәрне суырырга хәлеңнән килмиме?!» — дип сорый яки раслый ул. Һәм менә сезнең кулда сигарета, тәмәке.

Бактың исә, ишегалдындагы төркемдә кеше начар гадәтне җиңел кабул итә, ә яхшыны — авыр үзләштерә. Яхшы һәм югары максат өчен тупланганлык, җаның белән кабул итү һәм, ниһаять, төркем фикеренә каршы килә белү яисә ихтыяр көче кирәк.

Ләкин икенче төркемнәр — *спорт командалары* да бар. Алар сәламәт яшәү рәвешенә тизрәк өйрәтәләр.

Өстәмә уку

Виргиния университеты (АКШ) экспертлары 12—14 яшьлек 245 мәктәп укучысын тикшергәннәр һәм спортның командалы төрләре (волейбол, бейсбол һәм хоккей) белән шөгыльләнүче яшүсмерләр үзләрен спорт дәресләреннән качып йөрүчеләрдән яисә спортның көч куллану төрләре белән шөгыльләнүчеләрдән бәхетлерәк хис итүләрен ачыклаган.

Сез ничек уйлыйсыз, спортның командалы төрләре белән шөгыльләнүче балалар үзләрен нигә бәхетлерәк хис итә?

Әйдәгез, туры мәгънәдә иң татлы нәрсәләр турында сөйләшик әле. Табиблар татлы әйберләр яратуның кеше өчен нормаль хис булуын, ләкин аны кирәгеннән артык куллануның авыруларга һәм иртә картаюга алып баруын ачыклаган. Баллы әйберне артык күп ашаудан диабет чире барлыкка килә, һәм кеше симерә.

Артык күп ашау — комсызлыкның бер төре. Күп ашау һәм тыгыну үзеңне-үзең кызганудан да килеп чыга. Рәнҗү хисе һәм җәфаланулар ашау белән компенсацияләнә.

Тәмәке тарту — сәламәтлеккә начар тәэсир итүче зарарлы гадәт кенә түгел, өлкәннәр, хәтта яшүсмерләр арасында да киң таралган чир ул.

Нормаль булмаган яшәү рәвеше сәламәт кешене бик тиз бетәшкән һәм авыру картка әйләндерә, ә моннан соңгы юлга да ерак калмый.

Актив тарту организмга төзәтеп булмаслык зарар китерә. Ә *пассив тарту* нәрсә соң?

Бу тәмәке тартмаучы кеше тартучылар белән бер бүлмәдә эшләгәндә йә утырганда була. Пассив тартучыларда үпкә рагы белән чирләү ихтималы — 34 процентка, ә йөрәк-кан тамырлары белән — 50 процентка арта.

Тормышыгызны сәламәт туклану һәм дөрес яшәү рәвеше генә куркынычсызрак итүен исегездән чыгармагыз.

Йомгак ясыйбыз

Иминлек — кешенең мөһим ихтыяҗы. Зарарлы гадәтләр булмау тормыш иминлеген арттыра.

Бала өчен куркынычсыз яшәү мохите тәэмин итүдә гаилә гаять зур роль уйный.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Куркыныч, иминлек, гадәт

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Нәрсә ул «куркыныч» һәм «куркынычсызлык»?

2. Җәйге ялда, гадәти шәһәр фатирында, урамда безне нинди куркынычлар көтә?

3. Нинди гадәтләр булуы турында сөйләгез һәм түбәндәге схеманы ясап бетерегез.



4. Үзегезнең нинди гадәтләрне зарарлы дияр идегез?

5. Тирә-яктагыларга кешенең зарарлы гадәтләре ничек тәэсир итә?

Практикум

1. Файдалы гадәтләр исемлеген дәвам итегез: иртәнге ашны ашау, иртән һәм кичен тешләрне чистарту...

2. Зарарлы гадәтләрдән котылу ысулларын тасвирлагыз.

Зарарлы (зыянлы) гадәт	Аннан котылу ысулы
Алкоголизм	
Тәмәке тарту	
Наркомания	
Артык күп ашау	
Гиподинамия (аз хәрәкәтләнү)	
Сүгенү	
Ялган сөйләү	
Әләкләү	

3*. Сез: «Башкаларга зыян салучы куркыныч түгел, үз-үзеңә зарар итүче куркыныч», — дигән әйтем белән килешәсезме? Җавабыгызны нигезләгез.

1 бүлеккә йомгаклау сораулары һәм биремнәре

1. Нигә кеше үсеше биологик һәм социаль бергәлекне тәшкил итә? Моны ничек күз алдына китерәсез?

2. Хайваннарның үз-үзен тотышы белән безнең уртаклык бармы? Аларны күзәтегез. Уртак сыйфатлар исемлеген төзегез.

3. Кешенең ихтыяҗлары агачтагы яфраклар кадәр. Үзегезгә тәнкыйть күзлегеннән карарга тырышыгыз. Акылга сыярлык һәм сыймаслык ихтыяҗлар исемлеген төзегез. Кайсы багана озынрак булды?

4. Сез ничек уйлыйсыз, кешенең ихтыяҗлары күбрәкме яисә мәнфәгатьләреме? Үз карашыгызны аңлатыгыз.

5. Нәрсәгәдер бәя бирү нигә мөһим карар кабул иткәндәй киеренке акыл эшен таләп итә? Ә бәлки, ул карар кабул итүдән мөһимрәктер дә?

6. Көндәлек тормышта инвалидларга нинди чикләүләр белән очрашырга туры килә? Аларны ничек җиңәргә мөмкин? Сез аларга ничек ярдәм итә аласыз?

7. Көндәлек тормышта кеше нигә яхшы гамәлләр кылуга караганда гадиләрен күбрәк кыла?

8. Мәгълүм булганча, хисси танып белү биш тою органы ярдәмендә башкарыла? Ә рациональ танып белү нәрсә ярдәмендә була?

9. Тоеп танып белү ни өчен танып белүнең беренче баскычы булып тора? Ә шулай буламы — сез башта нәрсәдер турында уйлыйсыз, аннан соң аны күз алдына китерәсез?

10. Үзлектән өйрәнү һәм белем алу — алар арасында уртаклык нидә, ә аерымлык нәрсәдә?

11. Үзегезгә турыдан-туры йогынты ясаган һәм сезнең социальләшүгә этәргеч биргән кешеләр турында сөйләгез.

12. Бер графада үзегезнең тумыштан булган сыйфатларыгызны күрсәтеп, икенчесендә — тормыштан алынганнарын урнаштырып, таблица төзегез.

Тумыштан булган сыйфатлар	Тормыштан алынган сыйфатлар

Әлеге таблица нигезендә нинди нәтиҗәләр ясый аласыз?

13. Нигә кешенең һәр иҗтимагый статусы үзен хокуклар һәм бурычлар берлеге аша ача? Ә монда җаваплылык кирәкме?

14. Үзегезнең статус портретын төзегез, ягъни барлык социаль статусларыгызны санап чыгыгыз.

15. Нигә җәмгыятьтә баланың хәле олы кеше хәленнән аерыла?

16. Үзегезгә күз төшерегез: хисләрдә, фикер йөртә белүдә, тәртиптә һәм тирә-юньдәгеләргә мөнәсәбәтләрдә сезнең яшегез бер яки ике ел элек булгандагы белән чагыштырганда нинди яңалыклар алып килде?

17. Ир-атны һәм хатын-кызны характерлаучы сыйфатларны тасвирлагыз.

18. Нинди милләттән булу кешеләр арасында нормаль мөнәсәбәтләр булдырырга ярдәм итәме яки комачаулыймы? Фактлар һәм мисаллар белән иллюстрацияләгез.

19. Сез тумыштан ук нинди табигый хокукларга ия?

20. Иминлек һәм зарарлы гадәтләр үзара ничек бәйләнгән?



2 бүлек

Яшүсмернең иң якын даирәсе

§ 19. Иң якын кешеләр

Иптәшләр һәм замандашлар кемнәр алар? Кеше тормышында гаилә нинди роль уйный? Сез гаиләдә нинди роль уйныйсыз?

Немец-американ галиме Альфред Шюц берзаман шундый схема тәкъдим итә: үзәктә — *кеше* һәм аның *гаиләсе*. Аңарга иң якын урнашучылар — аның *иптәшләре, дуслары*. Икенче түгәрәктә — аның *замандашлары* — аның белән бер үк вакытта яшәүче кешеләр.

Иптәшләр һәм замандашлар

Иптәшләр һәм замандашлар белән кешенең мөнәсәбәтләре төрлечә була. Замандашлары турында ул күбесенчә ишетеп кенә белә — радио һәм телевидение тапшыруларыннан, Интернеттан, китаплардан, ә дуслары турында — үзенең шәхси тәҗрибәсеннән.

Замандашларга безнең планетада бер үк вакытта, бер үк чорда яшәүче барча кеше керә. Болар — төрле яшьтәге, расадагы, диндәге, һөнәрдәге һ.б. кешеләр. Картлар һәм яшьләр, кара һәм ак тәнлеләр, шахтерлар һәм укытучылар, руслар һәм американнар — алар барысы да замандашлар рәтенә керә.

Ә кеше үз **иптәшләре** даирәсенә кемнәрне кертә соң? Барыннан да элек алар сезнең мәктәп һәм ишегалды дусла-

рыгыз, күршеләрегез. Башкача әйткәндә, сез үзегез шәхсән белгән һәм актив аралашкан аз санлы кешеләр даирәсе. Боларга сез иптәшлек хисе тоясыз: башка кешеләрне үзегез кебек үк — барлык җитешсезлекләре, хаталары, наянлыклары һәм, әлбәттә, лаек сыйфатлары белән кабул итәсез. Иптәшлекнең төп принцибы — хәтта үзеңә зыян китереп булса да, дустыңа һәрвакыт ярдәм итү.

Монда башкаларның шатлыгына — шатлана, ә бәлагә юлыксалар — кайгыра белү хисен дә өстик. Теләктәшлек һәм кайгыртучанлык — кешеләр арасында рухи туганлыкның иң төгәл билгесе.

Гаилә

Кешегә иң зур йогынтыны якын кешеләре — гаилә ясый. Тулаем җәмгыять тә түгел, мәктәп, эш тә түгел, нәкъ менә гаилә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гаилә — никахка яисә кан кардәшлегенә нигезләнгән, уртак көнкүреш, үзара ярдәмләшү, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән кешеләр берләшмәсе.

Кардәшлек дип уртак әби-бабай, уллыкка-кызлыкка алу яисә никах белән бәйле кешеләр берлеге атала.

Гаилә иң борынгы җәмгыятьтә үк барлыкка килгән һәм озын юл үткән. Кешелек үсешенең барлык баскычларында ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә зур роль уйнаган. Хәзерге заманда да гаилә иң мөһим кыйммәт, кешеләр өчен иң әһәмиятле уртаклык булып кала.

Кешелек тарихында гаилә **мөһим функцияләр** башкарып килә.

Беренчедән, гаилә кешелек кавеменең дәвамлылыгын тәэмин итә.

Икенчедән, гаилә балалар тәрбияләүне үз өстенә ала. Ата-ана балаларга тормыш тәҗрибәсен, кагыйдәләрен һәм гореф-гадәтләрен тапшыра килә, җәмгыятьтә урнашкан тәртип күнекмәләрен өйрәтә. Гаилә балалар шәхесенә, шулай ук гаиләнең өлкән әгъзаларына хәлиткеч йогынты ясый.

Өченчедән, гаилә кешенең мәхәббәткә, рухи аралашуга, үзара ярдәмләшүгә, рухи һәм матди ярдәмгә, буш вакыт һәм ялны оештыруга булган ихтыяҗын канәгатьләндерә.

Дүртенчедән, гаилә йорт хуҗалыгын оештыруда, гаилә бюджетын алып баруда мөһим роль уйный. Ул гаиләнең кече яшьтәге һәм олыгайган әгъзалары турында кайгырта.

Әлеге функцияләрне үтәп, гаилә җәмгыятьне тотрыклы итә.

? Бу фотосурәттә сез гаиләнең нинди функцияләре үтәлүен күрәсез?

Гаилә барлыкка килүнең иң мөһим шарты булып **никах** — ирләр белән хатыннар арасындагы җәмгыять хуплаган мөнәсәбәт рәвеше тора.

Җәмгыять никахны законнар белән саклый. Россия Федерациясендә фәкать гражданлык хәлен теркәү дәүләт органнарында (загсларда) теркәлгән никах кына таныла. Аны рәсмиләштерүнең мәҗбүри шартларын түбәндәгеләр тәшкил итә: никах яше — 18 гә җитү, үзара ихтыяри ризалык, башка никахлар булмау, никахлашучылар арасында туганлык бәйләнешләре булмау.

Гаиләдәге рольләр

Гаиләдә ир белән хатын, ата-ана һәм балалар, ир һәм кыз туганнар, кардәшләр арасында билгеле бер мөнәсәбәтләр яшәп килә, аларның һәркайсы мәгълүм бер урын тота, роль башкара.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гаилә рольләре — гаилә әгъзаларының үз бурычларын үтәве һәм үз хокукларын тормышка ашыруы.

Гаиләнең һәр әгъзасына мәгълүм бер **гаилә роле** беркетелгән:

- ир һәм хатын;
- ата һәм ана;
- балалар — ул һәм кыз;
- туганлык — абый (эне) һәм апа (сеңел);
- буынара — әби һәм бабай, оныклар;
- кардәшлек — әти һәм әнинең апа-сеңелләре, абый-энеләре, туганнарның балалары һ.б.

Гаилә ролен кешеләр сайлап алмый, ул тумыштан була. Әти-әни, әби-бабай, башка туганнар барысы да сезгә юридик (хокукый) һәм кан кардәшлек белән бәйле. Үзенең табигате белән алар аерылгысыз, аларны бер генә көч тә өзә алмый.

Җәмгыять гаилә ролен төрлечә билгели. Мәсәлән, ир кеше хатынын һәм балаларын матди яктан тәэмин итәргә тиеш дип санала. Шуңа күрә ир мәҗбүри төстә эшкә урнашырга, моның өчен хезмәт хакы алырга һәм гаилә бюджетын тулыландырырга тиеш. Хатын өчен, әгәр гаилә мул тормышта яшәсә, эшкә урнашу мәсьәләсе ирекле булып тора. Социологлар хатыннар үтәргә тиешле төп өч роль турында сөйли: ир хатыны булу, ана булу бурычы һәм һөнәри бурыч.

Боларның берсен дә балалар башкара алмый әле. Шуңа күрә **сезнең гаиләдәге төп ролегез** — әти-әниегезгә *ярдәмче* булу. Гаиләдә балаларның роле гади генә хуҗалык эшләрендә (идән себерү, чүп-чарны чыгарып түгү), энекәш һәм сеңелкәшләрегезне карауда, шулай ук ярдәмгә мохтаҗ әби һәм бабайларыгызга булышлык итүдә чагыла. Икенче мөһим роль — *укучы* булу һәм белемнәр туплау. Ата-ана сезгә белемне сезне яраткан өчен генә түгел, сез үскәч эшкә урнашырсыз, картайган әти-әниегезгә ярдәм итәрсез, дип тә бирергә тырыша. Сезнең бүген яхшы укуыгыз — әти-әниегезнең киләчәктәге мул тормышы дигән сүз дә ул.



Сез ничек аңлыйсыз, абыйлар һәм сеңелләрнең гаиләдәге роле нидә чагыла?

Гаиләдә бала

Психологлар беренче вакытларда бала тирәсендә фәкать таныш затлар гына булырга тиешлеген ачыклаган — аңарда әйләнә-тирә дөньяның һәм үз-үзенең тотрыклыгы турында караш формалаша. Бала өчен кечкенәдән алып яшүсмер чагы узганчыга кадәр янында ата-анасын, туган йортын, дусларын тою бик мөһим, алар вакыйгаларны аңларга ярдәм итә, әхлакый кыйммәтләрне күрсәтә, мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Кечкенә чакта бала үз яшьтәшләренә караганда әти-әнисенә көчлерәк бәйле була. Нәкъ менә алардан мактау, ярату, наз көтә. Болар тәтемәгән очракта гына ул әлеге ихтыяҗларына иптәшләре яисә башка өлкәннәр ярдәмендә ирешә.

Өстәмә уку

Галимнәр яшүсмер тәртибендә һәм характерында гаиләгә һәм анда тәрбияләнү шартларына бәйле булмаган бер генә сыйфат та таба алмаган.

Әмма галимнәр балалар һәм ата-ананың мәнфәгатьләре бик нык аерылганын ачыклаган: әти-әни бала тормышының бөтен якларына игътибар бирә, ә шул

ук вакытта бала алар тормышы белән кызыксынмый диярлек. Бу бигрәк тә әтиләре белән аралашканда ачык күренә: балалары аларның эшендәге хәлләр, балалык һәм яшьлек еллары һ.б. турында бик сирәк сораша.

Сез ничек уйлыйсыз, нигә яшүсмерләр үз әти-әниләре тормышы һәм эше белән аз кызыксына? Әти-әниегездән аларның бала чагы, дуслары, эштәге хәлләр турында сорашыгыз.

Сез ничек уйлыйсыз, Белгородта нигә гаиләгә һәйкәл куярга булганнар?

Күпчелек яшүсмерләр әти-әниләрен дус һәм киңәшче итеп күрергә тели. Мөстәкыйльлеккә ничек кенә омтылсалар да, егетләр һәм кызлар тормыш тәҗрибәсенә һәм өлкәннәр ярдәменә мохтаҗ. Күп кенә дулкынландыргыч мәсьәләләрне алар гомумән яшьтәшләре белән тикшерә алмый, чөнки горурлык комачаулый. Синең кебек үк әле аз яшәгән яшь кеше нинди киңәш бирә алсын ди инде? Гаилә генә яшүсмер үзен иң тыныч һәм ышанычлы тойган урын булып кала.

Йомгак ясыйбыз

Гаилә — бергә яшәүче якын туганнар төркеме ул. Гаилә төзүнең иң мөһим шарты булып никах — гаилә кору максатында ир-ат һәм хатын-кыз берлеге тора. Гаиләнең һәр әгъзасына билгеле бер роль беркетелгән.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гаилә, кардәшлек, гаиләдәге рольләр

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Замандашлар кем икәнне аңлатыгыз. Җавап биргәндә, түбәндәге схемадан файдаланыгыз.



2. Безнең замандашлар булган мәгълүм кешеләрне атагыз. Аларның һөнәрләрен күрсәтегез.
3. Сезнең иптәшегез кем һәм нигә нәкъ менә ул?
4. Нәрсә ул гаилә? Төп гаилә рольләрен атагыз.
5. Гаилә кеше һәм җәмгыять өчен нинди әһәмияткә ия?

Практикум

1. Туганнарыгызның исемлеген төзегез.
2. Гаиләдәге рольләрнең бүленешен тасвирлагыз. Сез нинди роль үтисез?
3*. Уйлап карагыз әле, сезнең характерның кайсы сыйфатлары әти-әниегезгә охшый, кайсылары охшамый. Нигә?

20. Гаилә мөнәсәбәтләре

Гаилә мөнәсәбәтләре нинди була? Нәрсә ул гаилә конфликтлары? Ата-ана һәм балалар арасындагы каршылыкны ничек чишәргә?

Гаилә мөнәсәбәтләре турында халыкта бик күп мәкальләр йөри: «Тавышлы йорттан бәрәкәт кача», «Тату гаиләдә — балалар бәхетле» һ.б. Әйдәгез, **гаилә мөнәсәбәтләренең** нәр-сәгә нигезләнүен аңларга тырышып карыйк әле.

«Гаиләсен сөйгән — бәхетле булган»

Гаилә өч типтагы мөнәсәбәтләргә нигезләнә: *ир һәм хатын, ата-ана һәм бала, кардәшлек* мөнәсәбәтләренә.

Никахтан соң ир белән хатынның бер-берсенә карата билгеле бер бурычлары барлыкка килә. Ир һәм хатын бурычлары үзара **мәхәббәт** һәм **хөрмәт, ярдәмләшү** нигезендә ныклы гаилә мөнәсәбәтләре төзүдән, гаилә һәм балалары иминлеге турында кайгыртудан гыйбарәт.

Гаиләдә ир белән хатын арасында гына түгел, ата-ана һәм балалар, абый-энекәш һәм апа-сеңелкәш, туганнар арасында да билгеле бер мөнәсәбәтләр яшәп килә

Өстәмә уку

Ата-ана һәм балалардан, өлкән һәм кече буын вәкилләреннән торган гаилә *ике буынлы* дип атала. Әгәр дә гаиләдә ата-ана, балалар, әби-бабайлар һәм башка туганнар яшәсә, ул *күп буынлы* дип санала, ягъни гаилә турыдан-туры кардәшләрнең өч-дүрт буыны хисабына киңәя. Россиядә, Көнбатыш Европа һәм АКШта ике буынлы гаиләләр күпчелекне тәшкил итә, алар 70 проценттан күбрәк.



Рәсемдә нинди гаилә (ике буынлымы яки күп буынлымы) сурәтләнгән. Җавабыгызны дәлилләгез.

Өлкәннәргә хөрмәт һәм кечеләргә карата кайгыртучанлык кешенең табигатенә үк салынган.

Гаиләдәге ихлас, җылы мөнәсәбәтләр балаларның әтиәнисен хөрмәт итүенә, аларга охшарга тырышуына этәргеч бирә, ә бу, ахыр килеп, балаларда уңай әхлак сыйфатлары формалашуга сәбәп була. Үзләренә карата кайгыртучанлык, мәхәббәт һәм өлкәннәрнең ышанычын тойган балалар башкаларга да шулай карарга өйрәнә.

Әти-әни һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр төрле-чә була. Кайбер гаиләләрдә — бик җылы һәм игелекле мөнәсәбәтләр, ә икенчеләрендә салкын һәм дошманнарча караш яши. Беренче очракта тәрбиянең төп чаралары булып

игътибар һәм кызыксындыру тора, ә икенчесендә — артык таләпчәнлек һәм җәза бирү. Ләкин һәр ике вариантта ата-ана балалары тәртипле, яхшы, игътибарлы булып үсүен тели.

Гаилә конфликтлары

Балаларда нерв тетрәнүләре килеп чыгуда 90 процент очракта **гаилә конфликтлары** гаепле.

Бер генә гаилә, бер генә кешеләр берлеге дә конфликтларсыз яши алмый.

Конфликт гаилә мөнәсәбәтләрендә проблемалар бар, дигәнне аңлата. Димәк, кешеләр арасында үзара мөнәсәбәтләрнең башка сыйфатына күчәргә кирәк.

Шулай итеп, конфликт җыелып килгән проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирә. Яшенле яңгыр кебек, гаиләдәге һаваны чистарта.

Гаилә конфликтларының **сәбәпләре** бик күп: гаилә тормышына төрлечә караш; тупаслык, көч куллану, бер-береңә хөрмәт җитмәү; аралаша белмәү; зарарлы гадәтләр; иренең хатынына өй эшләрендә булышырга теләмәве; көнкүрешнең җайга салынмавы; ирнең хатыны туганнарына хөрмәте булмау һәм киресенчә; рухи мәнфәгатьләр һәм ихтыяҗларда аерымлык.

Һәм, әлбәттә, ата-ана һәм балалар арасында бер-береңне аңлау җитмәү.

Сезгә гаиләдәге конфликтларны хәл итүнең нинди ысуллары билгеле?

Ата-ана һәм балалар арасында конфликтлар

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, балалар белән аларның әти-әниләре арасында мөнәсәбәтләр күпчелек очракта шактый уңышлы була. Ә конфликт килеп чыкканда, аның сәбәпләре булып түбәндәге биш хәл торырга мөмкин:

1. **Яшәү рәвеше.** Каршылыкларның иң киң таралганнары түбәндәге мәсьәләләр буенча бәхәсләрдән килеп чыга:

- дуслар сайлау;
- төрле кичәләр, бию мәйданчыклары, дискотекаларда һ.б. булу;
- вакытны ничек уздыру һәм эшлексезлек;
- өйгә кайту һәм йокларга яту вакыты;
- кием яисә чәч алдыру рәвеше.

Гадәттә, ата-ана яшүсмерләрнең өйдә сирәк булуларыннан, бар вакытларын гаиләдән тыш үткәрүләреннән зарлана. Алар балаларның өйгә кайту вакытын, хәтта кайда булуларын да катгый тикшереп торырга тырыша.

2. **Җаваплылык.** Ата-ана һәрчак диярлек яшүсмерләрне тиешенчә җаваплылык күрсәтмәүдә гаепли. Җаваплылык таләпләре түбәндәге мәсьәләләргә кагыла:

- өйдә хуҗалык эшләрен башкару;
- шәхси әйберләренә, кием-салымына, торакка сакчыл караш.

3. **Мәктәп.** Уку, тәртип һәм мәктәпкә мөнәсәбәт ата-ананың игътибарын һәрдаим җәлеп итә. Әти-әни түбәндәгеләргә борчыла:

- балаларының өлгереше;
- мәктәптәге тәртибе;
- дәресләргә баруы;
- өй эшләрен әзерләве;
- балаларның укуга һәм укытучыларга мөнәсәбәте.

Менә шул уку аркасында балалар белән әти-әниләре арасында каршылыклар килеп чыга да инде. Берәүләре унбер ел мәктәпкә йөри, икенчеләре унбер ел буе алар өчен кайгыра.

4. **Гаиләдәге үзара мөнәсәбәт.** Ата-ана һәм яшүсмерләр арасында конфликт түбәндәгеләрдән килеп чыга:

- балаларның әти-әнисен күрәлмәтә хөрмәт итмәве;

• яшүсмерләрнең абый-энеләре, апа-сеңелләре белән әрләшүе;

• яшүсмерләрнең туганнары — бигрәк тә өлкән яшьтәге бабайлары һәм әбиләре белән катлаулы мөнәсәбәтләре.

Ата-ана яшүсмерләргә үзләрен кайбер йорт эшләрендә алмаштыра алырлык ярдәмчеләр күрергә тели. Алар бик хаклы рәвештә яшьләргә зур өметләр баглый. Әмма бу өметләр һәрчакта да акланмый.

5. **Әхлакый кыйммәтләр.** Конфликтка китерүче төп сәбәпләр:

• яшүсмернең тәмәке тартуы, алкоголь һәм наркотиклар куллануы;

• яшьләр жаргоны һәм сүгенеп сөйләшүе;

• ялган сөйләве;

• башка җенескә мөнәсәбәте;

• яшүсмернең законнарны үтәмәве.

Ата-ана һәм балалар арасындагы конфликтның сәбәпләре

12 яшь тулганнан соң, кызлар әти-әнисе белән малайлар өчен әрләшә башлый, ә конфликтларның күбесе 14—15 яшькә туры килә. Ә малайларда ул 16 яшьләрдә була. Кыз-

лар гаилә проблемаларыннан малайларга караганда ешрак зарлана.

Димәк, дөньяда конфликтсыз гаиләләр юк, ул кайда азрак, кайда күбрәк кенә. Конфликтлардан куркырга кирәкми, аларны чишә һәм билгеле бер чиктә тота белмәү куркыныч. Гаиләдә, гомумән, татулык хөкем сөргәндә, конфликтларның уңай яклары да бар, чөнки алар ата-ана һәм балалар мөнәсәбәтләрен яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

Конфликтны хәл итү юллары бармы? Гаиләнең барлык әгъзалары бер-берсенең хисләрен һәм теләкләрен хөрмәт итәргә, бер-берсенә юл куярга өйрәнергә тиешләр.

Йомгак ясыйбыз

Гаилә мөнәсәбәтләре үзара аңлашу һәм ярдәмләшү нигезендә корылырга тиеш. Чыгып торган гаилә конфликтларын чишәргә өйрәнергә кирәк, чөнки сезнең янәшәдә иң якын кешеләр, туганнарыгыз.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гаилә конфликтлары

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Гаиләдә мөнәсәбәтләр яхшы булсын өчен иң мөһиме нәрсә дип саныйсыз? Нигә?

2. Ата-ана һәм балалар арасындагы конфликтларның сәбәпләре нидә? Җавап биргәндә, 150 нче биттәге схемадан файдаланыгыз.

3*. Ата-ана балаларының тәртибен контрольдә ничек тота ала? Контрольнең нинди балаларга яхшырак йогынты ясый дип саныйсыз?

Практикум

1. Гаиләгездәге мөнәсәбәтләр турында кыскача гына хикәя языгыз.

2. Түбәндәге мәкальләрнең мәгънәсен аңлатыгыз:
«Агачны тамыр тота, кешене гаилә тота»,

«Бердәм гаиләдә — өй җылы»,
«Балалар ата-анага судья түгел».

3*. Сергей Владимирович Михалковның «Тыңлаусызлык бәйрәме» («Праздник непослушания») дигән әкиятендә ата-аналар, тыңлаусыз балаларыннан туеп, аларны үзләрен генә калдырып, шәһәрдән китеп баралар. Башта балалар шатлана, әмма бик тиздән бу ирек белән нишләргә, ничек яшәргә икәнлеген белмәүләрен аңлыйлар. Ата-аналар шәһәргә әйләнеп кайта.
Сез әкиятнең шулай тәмамлануына ризамы? Бу китапны үзегез ничек язып бетерер идегез?

4*. Әниләрнең берсе балалары белән үзара мөнәсәбәте уңаеннан газетага язган хат тексты белән танышыгыз. Күтәрелгән проблемалар буенча үз фикерегезне әйтегез.
«Балаларым белән нинди дә булса проблемалар булыр дип беркайчан уйламаган идем, чөнки үземне заманча ана дип саныйм, яшүсмерләрне аңлыйм дип белдем. Миңа 33 яшь, кызыма — 12. Гаиләдә аның 6 яшьлек энекәше дә бар. Ә иремә — 37. Безнең мөнәсәбәтләрдә шундый проблемалар бар ки, аларны бик тә уртага салып тикшерәсе (мөмкин булса — җавап ишетәсе) килә:
1) кызыбызның энекәшеннән көнләшүе, ул кайчакта ачыктан-ачык агрессиягә әверелә;
2) балаларның уртак хуҗалык эшләрендә катнашырга теләмәүләре — «Мин нәрсә сезгә, хезмәтчеме әллә?»;
3) кызыбызның берни белән дә кызыксынмавы (телефоннан сөйләшүдән башка бер шөгыле дә юк).
Гаиләдәге мөнәсәбәтләрне җайга салырга, эштән кайткач, балаларны ягымлы, хезмәт сөючән һәм тыңлаучан итеп күрергә бик тә телим».

5*. Лев Николаевич Толстой үзенең «Анна Каренина» романын түбәндәге сүзләр белән башлый: «Барлык бәхетле гаиләләр бер-берсенә охшаш, һәрбер бәхетсез гаилә үзенчә бәхетсез». Сез моның белән килешәсезме? Үз карашыгызны дәлилләгез.

§ 21. Гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре

Нәрсә ул гаилә кыйммәтләре? Нәрсә ул гаилә традицияләре? Гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре нигә кирәк?

Гаилә кыйммәтләре шкатулка һәм шкафта сакланучы кыйммәтле костюм һәм күлмәкләр, бизәнү әйберләре түгел ул. Ә менә иске фотосурәтләр, әбинең кияүгә чыкканда кигән күлмәге яисә гаиләнең буыннан буынга тапшырып килгән хикәяләре — болар барысы да **гаилә кыйммәтләренә** керә.

Гаилә кыйммәтләре

Гаилә кыйммәте — бер гаиләне икенчесеннән аерып торган, яшь буын өчен горурлык үрнәге булып хезмәт иткән, өлкән буыннарга хөрмәт уяткан нәрсә ул. Гаилә кыйммәтләрен кечкенәдән күрсәтергә, аны гаилә тарихын сөйләү, **гаилә архивында** күз карасыдай сакланган әйберләр аша тәрбияләргә кирәк.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гаилә кыйммәтләре — гаиләнең тарихи хәтеренең бер өлеше, бабаларыбызның бабаларыннан мирас булып килүче гореф-гадәтләр.

Гаилә альбомы — тарихи хәтер хәзинәсе. Гаилә архивындагы фотосурәтләр кешеләргә ни өчен кадерле?

Гаилә альбомы, әгәр аны цифрлаштырсаң һәм гаилә сайтында урнаштырсаң, заманча төс алырга мөмкин. Бу — гаиләнең тарихи тамырларын барлау һәм аның үткәнен белү мөмкинлеге. Әбиләрегез һәм бабайларыгыз сөйләве, туганнарыгыздан сорашып **гаиләнең шәҗәрәсен (нәсел агачын)** ясарга мөмкин. Бу — ерак һәм якын туганнарыбыз, аларның балалары, оныклары, абый-апалары биографияләрен җыю-ны эченә алган бик мавыктыргыч һәм кызык шөгыль. Моңа өстәмә итеп гаилә тугралары (герб) ясарга була, анда гаиләнең төп үзенчәлекләре һәм үзенә генә хас сыйфатлары чагылыш таба.

Мондый шөгыль хәтердә иң күркәм истәлекләр калдыра, ә балалар, үсә төшкәч, аны үз гаиләләрендә дәвам итә. Һәм бу **гаилә традициясенә** әверелә.

Гаилә традицияләре

Бала чакларын искә алып, күп кенә олылар үз гаиләләрендә гореф-гадәтләр турында сөйлиләр. Бу хатирәләр гомергә кала, һәм кеше, үз гаиләсен корганда, ата-ана йортындагы гореф-гадәтләрне үз йортына алып килә, үз традицияләрен дә өсти.

Һәр гаиләнең үз гореф-гадәтләре бар. Алар безгә теге яки бу хәлдә нишләргә икәнлеген әйтеп җибәрү өчен кирәк. Бик уйланып торасы да юк. Традицияләр тормышны аерым «кирпечләрдән» төзергә мөмкинлек бирә: иртә белән һәрчак ботка ашыйбыз, бәйрәм көннәрендә бәлеш пешә, мунчаны шимбә көнне керәләр, ял итәргә бакчага барабыз.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Гаилә традицияләре — гаиләдә кабул ителгән, буыннан буынга тапшырылып килүче нормалар, үз-үзеңне тоту рәвеше, гадәтләр һәм карашлар.

Табигатькә чыгу — гаилә традицияләренең берсе. Ә сезнең гаилә гадәттә ничек ял итә?

Гаиләнең һәр әгъзасына кагылышлы мөһим карарны **гаилә киңәшмәсендә** кабул итү — шулай ук матур традиция. Яшүсмер теләге һәрвакыт исәпкә алына һәм хәлиткеч була ала, бу, әлбәттә, үз-үзеңә бәя биргәндә уңай чагылыш табачак. Гаилә киңәшмәсе һәр кичне чәй эчү рәвешен дә алырга мөмкин, анда узган көнгә анализ ясала, якын киләчәккә планнар тикшерелә.

Гаилә традицияләре туганнарны тагын да якынайта, гаиләне ныклы һәм бердәм итә. Уртак шатлык гаилә тантаналары: туган көннәр, юбилейлар һ.б. вакытында барысын да бәйрәм табынына җыя. Кайбер гаиләләрдә тантананы өстәл янындагы иң өлкән кеше ача, ә икенчеләрендә моны йорт хуҗасы эшли. Бериш гаиләләрдә балаларны да табынга утырталар, ә икенчеләрендә — юк.

Туганнар һәм дуслар белән язышып тору да файдалы традиция була ала. Бу аларга карата хөрмәт хисе тәрбияли һәм тупланауга хезмәт итә.

Кайбер гаиләләрдә өстәл уеннары, мәсәлән, «Лото» уйнау яки якшәмбе көнне гаилә белән җыелып төшке аш ашау гадәткә кергән. Ә башкалары даими рәвештә машинада иске шәһәрләр карап йөри, шашлыкка бара яисә табигать күренешләрен фотога төшерә. Боларның барысы да җылы

мөнәсәбәт, тотрыклылык һәм үзара ярдәмчеллек атмосферасы тудыра. Ә бу бик мөһим.

Атна саен урманга бару, кыш башында кар бабай ясау, яз килүне бәйрәм итү, сыерчык оясы кору да гаилә традициясе булырга мөмкин. Гаилә елъязмасы алып бару, аны ата-бабаларның һәм хәзерге фотосурәтләр белән бизәү дә бик яхшы традиция булып тора.

Гаиләләр һәм аларның традицияләре ничек кенә үзенчәлекле булмасын, барлык гаиләләрдә дә билгеләп үтелүче гомуммилли бәйрәмнәр бар. Мәсәлән, Яңа ел, 8 Март, 23 февраль. Аларга алдан ук әзерләнәләр, биналарны бизиләр, матур киенәләр һәм бүләк алалар.

Котлаулар язылган Яңа ел открыткасы бирү — традицияләрнең берсе. Ә сезнең гаиләдә аны бәйрәм итү ничек гадәтләнелгән?

Гаилә бәйрәмнәре — алар гаилә тарихындагы күркәм чорлар, гаилә учагының җылысын саклаучы игелекле гамәл. Барыбызның да йөрәк түрендә яшерелгән тылсымны көтү ул. Яңа ел, Раштуа, Ураза һәм Корбан бәйрәме, туган көн диюгә, күзләрдә өмет балкый, әкият, шатлыклы һәм якты вакыйга көтәбез.

Өстәмә уку

«Яңа ел белән! Яңа бәхетләр белән», — дигән бәйрәм сәламе безнең эрага кадәр 153 елда ук яңгыраган. Шул чакта ук борынгы римлылар, Яңа ел җиткәндә, уңыш һәм бәхет теләп, бүләкләр биргәннәр.

Русьта, Яңа ел табыны җиткәндә, өстәлгә арыш, бодай, солы орлыклары сипкәннәр. Аннан соң өстәлгә чиста җәймә җәйгәннәр.

Яңа елны каршылаганда, уртада чыршы тора. Аңа эленгән бизәкләр Җиргә төшкән йолдызлар кебек дип саналган. Һәр йолдыз ниндидер хыял, өмет, сер турында сөйли. Яңа ел җитү мизгелендә чыршыда алдан ук әзерләнгән утларны кабызганнар. Чыршы астына үз бүләгеген эзләп кергәндә яки өйдәге спектакль өчен мәзәк костюмын кигәндә, олы кеше дә балага әверелә.

Россиядә Яңа ел алдыннан торакны чыршы ботаклары белән бизәү, бизәкле чыршы кую традициясе кайчан барлыкка килүен белешегез.

Туган көннәр — шәхси бәйрәм, кагыйдә буларак, алар бөтен гаилә белән билгеләп үтелә. Бу көндә кич табынга утыралар һәм тантана иясенә бүләкләр бирәләр. Аңа ничә яшь, шуның кадәр сандагы шәм куелган торт та була.

Сез үзегезнең кайсы туган көнегезне барысыннан да артык истә калдырдыгыз? Сезгә ул чакта ничә яшь тулды?

Шәхси гаилә бәйрәменә шулай ук исем кушу, сабыйга беренче тешләр чыгу, паспорт алу көне дә керә...

Ә тагын нәрсә булырга мөмкин?

Балалар — гаилә традицияләрен формалаштыру һәм тапшыру процессында мәҗбүри һәм төп буын. Сез барлык гаилә башлангычында катнашырга тиеш. Сез бәйрәм табынын бизи аласыз, әниегезгә Яңа ел пилмәнен ясашырга яисә әтиегез туган көндә бәлеш пешерергә ярдәм итә аласыз, гаилә фотоелъязмасын туплап элеп куярга да була.

Гаилә гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре һәр халыкның мәдәнияте нигезендә ята. Һәр яңа буын шуларда тәрбияләнә. Авыр чорларда нәкъ менә алар гаиләне саклап тора.

Йомгак ясыйбыз

Гаилә кыйммәтләрен тапшыру, гореф-гадәтләрне саклау — гаиләнең берләшүенә, аның ныгуына һәм тупланганлыгына илтүче юл. Нәкъ менә берничә буын кешеләреннән торган гаиләдә халык традицияләре саклана һәм яңалары барлыкка килә, шулай ук кайгыртучанлык тәрбияләнә.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Гаилә кыйммәтләре, гаилә традицияләре

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Гаилә кыйммәтләре» дигән төшенчәгә нәрсәләр керә һәм сездә алар нинди?

2. Нәрсә ул гаилә традицияләре? Сездә нинди гаилә традицияләре бар?

3. Гаилә кыйммәтләре һәм гореф-гадәтләре нигә кирәк?

4. Сез нинди гаилә бәйрәмнәре беләсез, гаиләгездә кайсыларын билгеләп үтәсез?

Практикум

1. План буенча үзегезнең гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре турында хикәя языгыз. Әгәр мөмкин бул-

са, хикәягезне компьютер презентациясе белән иллюстрацияләгез.

План

1) Сезнең гаиләдә нинди традицияләр бар? Алар турында сөйләгез.

2) Гаиләгездә элек булып та юкка чыккан йә үзгәргән гореф-гадәтләр булганмы? Алар нидән гыйбарәт һәм ничек барлыкка килгән?

3) Гаиләгездә бәйрәмнәрне ничек билгеләп үтәләр, ә элек ничек булган? Бөтен гаиләгез бергә нинди очракларда җыела?

4) Сезнең гаиләдә аерым бер аш-су төрләре бармы? Аларның рецепты буыннан буынга күчкәнме?

5) Сезнең гаиләдә бүләкләр яисә гаилә реликвияләре саклананмы?

6) Сезгә әти-әниләрегез нинди әхлак принциплары белән яшәргә куша? Ә әби-бабайларыгыз нәрсә әйтеп калдырган.

2*. Әти-әниләрегез катнашында һәм алар ярдәме белән үз гаиләгезнең шәҗәрәсен төзегез. Үзегезнең әти-әниегез, әби-бабагыз, аларның әти-әниләре фотосурәтләрен җыегыз һәм аларга мәгълүмат бирегез.

§ 22. Гаиләдә кайгыртучанлык һәм тәрбия

Нәрсә ул гаиләдәге кайгыртучанлык? Балаларны ничек тәрбияләргә кирәк?

Сез — безнең балалар — илебезнең киләчәктәге тулы хокуклы гражданнары гына түгел, булачак әти һәм әниләр дә. Вакыты җиткәч, сез дә балаларыгызны тәрбияләрсез. Әмма моның өчен **тәрбия** һәм балалар турында **кайгырту** нәрсә икәнен белергә кирәк. Илебезнекен генә түгел, дөнья тәҗрибәсен белсәгез тагын да яхшы.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Тәрбияләү — бер кешенең икенчесенә аңа кирәкле тәртип кагыйдәләре һәм әхлакый кыйммәтләр өйрәтү максатында йогынты ясавы буенча юнәлтелгән процесс.

Төрле халыкларда тәрбия

Күпчелек халыкларда төп тәрбиячеләр булып гаилә һәм ата-ана санала. Ләкин һәрчакта да болай булмаган. Кайбер илләрдә балаларны тәрбиягә туганнарына һәм бөтенләй ят кешеләргә тапшыралар. Урта гасырларда Европада, мәсәлән, шулай булган. Россия территориясендә Кавказ халыкларының кайберләрендә ата-аналарның үз балаларын якын туганнары гаиләсенә бирү гадәте булган. Бу ир туган тәрбиягә алучы ата дип саналган һәм баланы балигъ булганчы тәрбияләгән.

Төрле тарихи чорларда һәм төрле илләрдә балаларны, бер үк төсле тәрбияләмәгәннәр. Моны күрергә бергәләшеп экскурсиягә кузгалыйк.

Төньяк Кавказ халкы — адыгейларда балаларга беркайчан да тавышларын күтәреп эндәшмәгәннәр, ә кыйнаусугуны гомумән белмәгәннәр. Гадәттә, малайларны 6—7 яшькә кадәр һәм кызларны балигъ булганчы, хатын-кыз тәрбияләгән. Ә аннан соң малайларны, башлыча, ир-ат тәрбиягә алган. 3—4 яшьтән үк малайлар күпчелек вакытларын яшьтәшләре янында булган, кошлар һәм вак җәнлекләр аулый башлаган. 8 яшьтән инде алар түземлелек һәм уйлап чыгару сәләте күрсәткәннәр. Балалар уены зур тәрбия әһәмиятенә ия булган, зуррак малайлар кечкенәләрен өйрәткәннәр. Малайлар, аудан тыш, ярышлар да оештырганнар. Кызлар, «ашарга пешереп», курчак белән уйнаганнар. Яшүсмерләрнең уены җитдирәк булган, күбрәк хәрби төсмер алган. Халык спорты төрләре киң таралган.

Японниядә балаларга җәза бирүгә караганда күбрәк кызыксындыру чаралары кулланылар. Әрләү урынына тәрбиянең аерым бер күнекмәләренә өйрәтәләр, балаларга, әгәр тырышсалар, алар үзләре белән идарә итәргә өйрәнергә сәләтле дигән инану кертәләр. Японнар, кичекмәстән

тыңлатуга юнәлтелгән артык басым ясау киләчәктә капма-каршы нәтиҗә бирергә мөмкин дип саныйлар.



Нигә японнар, балаларны тәрбияләгәндә, җәза бирүгә караганда аларны кызыксындыру яхшырак дип саныйлар?

Инглизләр, киресенчә, ата-ана мәхәббәтен һәм назын күп куллану бала характерына зыян китерә, аларга бик сак, хәтта салкынча мөнәсәбәттә булырга кирәк дип уйлый. Кече яшьтән үк дисциплинага өйрәтәләр. Алар фикеренчә, балаларга җәза бирү — ата-ананың хокукы гына түгел, бурычы да. Инглизләр бала чактан ук мөстәкыйльлеккә һәм үз гамәлләре өчен җаваплылыкка өйрәтә. Инде 16—17 яшьтән үк, аттестат алгач, балалар әти-әнисе яныннан китә һәм бәйсез яши.

Гаилә кайгыртучанлыгы һәм тәрбиянең әһәмияте

Кешеләргә дә, җәнлекләр һәм кошларга да үз балалары турында кайгырту хас. Тик ул төрлечә ачыла. Берәүләр балаларын очарга яисә ауга йөрергә өйрәтә дә, кайгыртучанлыклары шуның белән бетә. Икенчеләре үз бәбиләрен картайганчы «үчтеки» итәләр, акчалата булышалар. Ләкин бу инде җитди эш түгел.

Гаиләдә чын кайгыртучанлык — мөстәкыйль яшәү күнекмәләрен үзләштерергә ярдәм итү максатында балалар-

га өлкәннәрнең кычкырмый-сукмый гына зирәк остазлык итүе.

Ата-ана баланы ашату-эчертү, киендерү, прогулкага йөртү генә түгел, тәрбияләргә дә тиеш.

Тәрбияләү барышында мәдәни кыйммәтләр, әхлакый күзаллаулар бер буыннан икенчесенә тапшырыла. Бала дисциплинага, көндәлек тормыш һәм шәхси гигиена кагыйдәләренә өйрәнә. Шулай ук башка кешеләр (туганнары, дуслары) белән аралашуның мәдәни нормаларын, җәмгыятьтә кабул ителгән социаль рольләрне (мәсәлән, сатып алучы яисә укучы ролен), һөнәри осталык нигезләрен үзләштерә.

Александр Красносельскийның «Әби әкиятләре» дигән картинасын карагыз, 1866 ел. Ә сезне тәрбияләүдә әбиләрегез һәм бабайларыгыз нинди роль уйный?

Кызыклы фактлар

Хәзер Россиядә 40 миллионнан артык гаилә санала, шуларның 20 миллионында диярлек балигъ булмаган бала бар, 6 миллион чамасында — 3 яшькәчә балалар яши. 2 миллионнан күбрәк гаилә — күп балалы.

Бишектә чакта ук бала әти-әнисе һәм бөтен гаилә игътибары үзәгендә була. Ата-ана бала белән рәхәтләнеп уйный, аны иркәлиләр, аңа елмаялар, нәни дә көләргә өйрәнә. Ә берничә айдан ул әти-әнисенең тавышларын таный башлый, нишләргә ярый, нәрсә эшләргә ярамый икәнлекне, рәхәтлекне аңлый.

Бала, кыз яки малай, үсә барган саен, дуслары белән уйнап, әти-әнисеннән күреп, ә соңрак — мәктәптә укып, җәмгыятьтә үзен тиешенчә тоту нечкәлекләренә өйрәнә. Ягъни **гендер социальләшүе** бара (аның нәрсәдә чагылуын исегезгә төшерегез).

Тәрбияләүдә иң мөһиме булып кешенең **рухи үсеше** тора. Үзегезгә игътибар белән карагыз. Сезне кечкенәдән үк дөрес тәртипкә гадәтләндерәләр, грамматикага һәм санарга өйрәтәләр, фән нигезләре белән таныштыралар, дөньяга карашыгызны киңәйтәләр. Кызыксынучанлыкны туктаусыз үстерә бару, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү, өзлексез белем алуга йөз тоту, нәфис әдәбият, вакытлы матбугат (газета, журналлар) укырга күнектерү аерым әһәмият ала.

Гүзәллек дөньясына юл ачып, ата-ана балаларга китаплар укый яисә мөстәкыйль укырга өйрәтә, аларны музыка мәктәбенә, музей һәм театрларга, рәсем дәресләренә йөртә, кинотеатрларга, күргәзмәләргә җибәрә, экскурсияләргә алып бара.

Әхлак нигезләрен балалар күбесенчә нәкъ менә гаиләдә үзләштерә, яхшыны — яманнан, игелекне явызлыктан аерырга өйрәнә, намус һәм гаделлек төшенчәләре белән таныша, зәгыйфьләрне яклау, картларга һәм авыруларга булышу зарурлыгын белә, кешеләргә игелекле караш торырга, хәлдән килгәнчә булышырга өйрәнә.

Гаиләнең мөһим бурычы — **хезмәт тәрбиясе**. Өй мәшәкатьләрендә катнашу, эш әмәлен һәм күнекмәләрен белү, хезмәтнең тормыштагы ролен аңлау, җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнашуга кызыксыну — менә ул гражданның өлгергән, уңышлы тормышы нигезе.



Сезнең гаиләдә хезмәт тәрбиясе ничек бара? Сезнең өйдәге йөкләмәләрегез нинди?

Кешеләр җәмгыятеннән башка җирдә мондый нәрсәләр юк. Хайваннар үз балаларын тәрбияләми. Алар, ояга азык кайтарып, кайгыртучанлык кына күрсәтәләр, аннан соң ерткычлар арасында исән калу, ауга йөрү кебек иң гади күнекмәләрне бирәләр. Кеше үз үсешендә хайваннардан күпкә алга киткән. Ата-ана ничек исән калырга өйрәтми, ә кечкенәләргә ярдәм итәргә, өлкәннәргә карата әдәпле һәм һәрьяклы белемле булырга, зарарлы ләззәтләрдән баш тартырга, үзенең намусын һәм абруен сакларга өйрәтә. Болар барысы да җәмгыятьтә формалаша һәм тәрбия аша бирелә.

Гаилә тәрбиясендә баланың сәламәтлеге турында кайгырту, аның **физик әзерлеге,** аны чыныктыру, көчен, җитезлеген, түземлеген арттыру мөһим урын тота. Ата-ана балаларын кечкенә чактан ук иртәнге зарядка ясарга күнектерә, аларны төрле хәрәкәтчән уеннарга, спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итә, бергәләшеп туристик сәфәрләрдә йөриләр.

Ата-ана тәрбия бирү өчен җаваплы һәм баланың сәламәтлеге (физик, психик, рухи) турында кайгыртырга бурычлы. Ул гына да түгел, ата-ананың башка кешеләрдән үз балаларын тәрбияләүгә өстенлекле хокукы бар.

Йомгак ясыйбыз

Гаиләнең барлык әгъзалары бер-берсе турында кайгыртырга тиеш. Ата-ана һәм гаилә — иң беренче һәм иң кызыксынган гаилә, чөнки сүз үз балалары турында бара. Эстафетаны алардан мәктәп укытучылары ала, алар укыталар да, тәрбиялиләр дә. Укытучы апаларын күпләр икенче әниләре дип йөртә. Күпчелек мәктәп укытучылары һәм балалар йортлары тәрбиячеләре балаларга күңел җылылыгы һәм наз белән карый.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Тәрбия

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Тәрбия» төшенчәсенең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Балаларны тәрбияләүнең өч системасын — Япониядәге, Англия һәм Россиядәге системаларны чагыштырыгыз. Нәтиҗә ясагыз.

3. Гаиләдәге хезмәт тәрбиясенә ниләр керүен санап үтегез. Әлеге исемлектән сезнең гаиләдә кайсылары гамәлдә?

4. Ата-аналарыгыз сезне дисциплинага һәм тыңлаучанлыкка ничек өйрәтә? Көндәлек тормыштагы һәм шәхси гигиенада иң гади күнекмәләрне кемнән алдыгыз?

5. Сезнең турыда әти-әниегез кайгыртуы нәрсәдә чагылыш таба? Ә сез гаилә әгъзалары турында ничек кайгыртасыз?

6. Тәрбияләүдә нигә кешенең рухи үсеше иң мөһиме булып тора? Ул нәрсәдә гәүдәләнә?

7*. Балалар турында чын кайгырту алар белән шаярудан нәрсәсе белән аерыла?



Практикум

1. Борынгы спартанлыларның балаларны тәрбияләве белән хәзерге балаларны ничек тәрбияләүләрен чагыштырыгыз (5 нче сыйныф тарих дәреслеге материалларыннан файдаланыгыз).

2. Түбәндәге мәкальләрнең мәгънәсен аңлатыгыз:
«Җиде нәнкәгә бер бала, ул да күзсез кала»;
«Баланы сәкедә аркылы ятканда тәрбиялә»;
«Баланы чыбыркы белән түгел, оялтып куркыт».

3. Түбәндәге җөмләләр ничек тәмамлана:
«Баланы яхшы тәрбияләр өчен ...»;
«Тәрбияләгәндә ярамый: ...»

§ 23. Гаиләгә дәүләт ярдәме

Дәүләт нигә гаиләгә ярдәм итәргә тиеш? Россия дәүләте гаиләгә ничек ярдәм итә?

Гаилә — җәмгыятьнең иң зур кыйммәте. Шуңа да дәүләт һәрвакыт гаиләгә актив рәвештә ярдәм итеп килде һәм булышты.

Борынгы Кытайда ук җирле хакимият, салым сәясәте үткәргәндә, тол калучыларны һәм ятимнәрне рәнҗетмәскә тырыша. Картлар өчен махсус йортлар иң беренче булып Борынгы Көнчыгышта барлыкка килгән.

Хәзерге Россия дәүләте гаиләгә ничек ярдәм итә?

Ана капиталы

Гаиләнең иң зур кыйммәте — сез ул, балалар.

Россиядә менә берничә ел инде бала тудыруны кызыксындыруның яңа чарасы — **ана капиталы** гамәлдә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Ана (гаилә) капиталы — балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең бер төре.

Россия гражданлыгы булган, икенче һәм аннан соңгы баласын тапкан (уллыкка яисә кызлыкка алган) ана әлеге капиталга хокук ала. Ана капиталының акчалата күләме һаман арта бара.

Ана капиталы бары түбәндәге мәгълүм максатларда тотыла ала:

- балага белем бирүдә;
- торак шартларын яхшыртуда (торак сатып алу, төзү һәм реконструкцияләүдә);
- ананың булачак хезмәт пенсиясенә.

Ана капиталы — илебездә бала табуны арттыруга юнәлтелгән дәүләт сәясәте

Ана капиталы акчаларын бала туганнан соң (уллыкка алганнан соң) өч ел узгач кына файдаланып була.

Дәүләтнең социаль ярдәме

Дәүләт гаиләгә **социаль ярдәм** күрсәтә.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Дәүләтнең социаль ярдәме — аз керемле гаиләләргә, үзләре генә яшәүче аз керемле гражданнарга акчалата түләү, социаль хезмәтләр күрсәтү һәм яшәү өчен кирәкле таварлар бирү.

Дәүләт ярдәме гаиләнең бер әгъзасына санаганда яшәү минимумыннан кимрәк керем алучы гаиләләргә бирелә (2011 елда Россиядә яшәү минимумы 6505 сум тәшкил итте). Ярдәм гражданның махсус хакимият органнарына мөрәҗәгате нигезендә бүлеп бирелә.

Россиядә күп балалы гаиләләргә дәүләт тарафыннан актив булышлык күрсәтелә (күп балалы дип балигъ булмаган өч һәм аннан да күбрәк бала яшәгән гаилә санала). Мәсәлән, җылылыктан, судан, газдан һәм электр энергиясеннән файдаланган өчен ташламалар бирелә, ә үзәктән җылыту сис-темасы булмаган йортларда яшәүчеләргә ягулык бәясе кайтарыла. Күп балалы гаиләләр җәмәгать транспортында түләүсез йөри, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар түләүсез туклана һ.б.

Россиядә гаиләләргә социаль ярдәм түләүнең күләме, шартлары һәм тәртибе билгеләнгән махсус **законнар** кабул ителә. Мәсәлән, «Дәүләтнең социаль ярдәме турында» Федераль закон шундыйлардан.

Гаиләгә социаль ярдәм хезмәтләре

Авыр тормыш хәленә юлыккан гаиләләргә һәм балаларга ярдәм итү өчен дәүләт махсус учреждениеләр — **социаль хезмәтләр,** шул исәптән **гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләре** булдырды.

Алар каты авыруы булган һәм инвалид балалы гаиләләргә; ятим балаларга; ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга; авыр хәрәкәтләнүче, даими карауга мохтаҗ гражданнарга һәм аларның гаиләләренә, дарулар яисә туклану продуктлары сатып алырга кирәк кешеләргә ярдәм итә. Социаль хезмәтләр хәйрия тукланулары, балаларның җәйге ялын, санатория-курортта дәвалануын оештыра; көнкүрешне уңайландыруда (торакны төзекләндерүдә, ягулык белән тәэмин итүдә, йорт яны кишәрлекләрен эшкәртүдә, су китерүдә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә) һ.б. булыша. Социаль хезмәтләр яшь гаиләләргә ярдәм итә, яшь кешеләргә эшкә урнашуда булышлык күрсәтә.

Бөек Ватан сугышы ветераннары гаиләләре дә социаль ярдәм ала. Ә сез аларга ничек булышасыз?

Инвалид һәм авыру балалар булган гаиләләргә аерым игътибар бирелә. Мохтаҗ гаиләләрне ачыклаганнан соң, социаль хезмәтләр аларга төрлечә ярдәм итә, шул исәптән аларны кибетләргә, остаханәләргә беркетә һ.б.

Кызыклы фактлар

Россиядә һәр елны 8 июльдә рәсми рәвештә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне билгеләп үтелә, ә 15 майда Халыкара гаилә көне уздырыла.

Гаиләгә булышлыкның тагын бер формасы булып **гаилә ялы үзәкләре** оештыру тора. Бу үзәкләрдә уен, тренажёр мәйданчыклары эшли, педагогик һәм психологик консультацияләр үткәрелә. Күп кенә үзәкләр каршысында төрле гаилә клублары, «Ышаныч телефоны» хезмәте төзелгән. Соңгысы буенча төрле тормыш-көнкүреш проблемаларын сөйләргә, психолог консультациясе һәм киңәшен алырга була. Гаилә клубларында балалар һәм олылар үзләренең буш вакытларын бергә уздыралар, монда аларның мәнфәгатьләре берләшә.

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган ятим балалар һәм ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен **балалар һәм яшүсмерләр социаль приютлары** төзелә. Балалар монда яши, түләүсез туклана, табиблардан ярдәм ала, мәктәпкә, спорт түгәрәкләренә һәм секцияләренә йөри.

Социаль яклау үзәкләре балигъ булмаганнарга һәм аларның гаиләләренә хокукый ярдәм күрсәтә, имин булмаган гаиләләрне, балалар һәм яшүсмерләрне җинаятькә тартучы затларны контрольдә тота, ябылып тотудан чыкканнарга булыша.

Социаль ярдәм күрсәтүче кешеләр һөнәри әзерлек уза һәм социаль хезмәткәрләр дип атала.

Социаль хезмәткәр белгечлеген урта махсус (һөнәри) яисә югары уку йортларында алырга була

Кызыклы фактлар

2011 ел социаль өлкә белгечләре — Россиянең социаль хезмәткәрләре һәм социаль педагоглар өчен юбилей елы булды. Бу елда югары һәм махсус урта уку йортларында «социаль хезмәткәр» белгечлеге кертелә башлауга — 25 ел, ә «социаль эш» белгечлегенә 20 ел тулды. Социаль хезмәткәр көне ел саен 8 июньдә билгеләп үтелә.

Йомгак ясыйбыз

Гаилә — җәмгыятьнең иң мөһим кыйммәтләренең берсе, шуңа да дәүләт гаиләгә ярдәм итә. Россиядә бала тудыруны арттыру дәүләт сәясәте алып барыла. Социаль хезмәтләр аз керемле һәм күп гаиләле гаиләләргә булыша, каты авырулы һәм инвалид балалары булган гаиләләргә, шулай ук ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм күрсәтә.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Ана капиталы, дәүләтнең социаль ярдәме

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Дәүләт нигә гаиләгә ярдәм итәргә тиеш?

2. Ана капиталы турында сөйләгез. Ул нидән гыйбарәт, кемгә бирелә? Сезнең гаиләдә ана капиталы алдылармы?

3. «Дәүләтнең социаль ярдәме» нәрсә икәнлеген аңлатыгыз.

4. Социаль хезмәтләр, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләре нәрсә белән шөгыльләнә?

5. Социаль хезмәткәрләр кемнәр ул?

6*. Сез ничек уйлыйсыз, Россия дәүләте гаиләгә нинди ярдәм күрсәтергә тиеш? Җавабыгызны дәлилләгез.

Практикум

1. Әти-әниләрегездән дәүләтнең сезнең гаиләгә нинди ярдәм күрсәтүен белегез.

2. Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар нәрсә ул? Газета, журналлар һәм Интернет материалларын кулланып, өстәмә мәгълүмат туплагыз. Зур булмаган хикәя языгыз.

§ 24. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау

Нигә балалар ата-ана каравыннан мәхрүм кала? Мондый балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре ничек саклана? Сез ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ничек ярдәм итә аласыз?

Җәмгыятьтә баланың хәле олы кеше хәленнән аерылып тора. Бала мөстәкыйль түгел, үз хокукларын яклау, үз мәнфәгатьләре өчен көрәшү мөмкинлеге юк. Кагыйдә буларак, аның тормышына һәм үсешенә кагылышлы мөһим карарларны өлкәннәр кабул итә. Балалар өлкәннәр яклавына һәм каравына мохтаҗ. Әмма барлык балаларның да

әти-әниләре юк, барлык балалар да туган гаиләләрендә тәрбияләнми.

Балалар гаиләдә тәрбияләнергә тиеш, ләкин һәркемнең дә гаиләсе юк.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар — әти-әниләре үлгән ятим балалар. Шулай ук **социаль ятимнәр** — төрле сәбәпләр аркасында (ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән, иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтиләр, дәвалау учреждениеләрендә яталар, балалар тәрбияләүдән яисә аларга ярдәм итүдән тайпылалар, балаларын калдырып киткәннәр) әти-әниләре аларны тәрбияләү белән шөгыльләнмәгән балалар бар.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар — әти-әниләре үлгән яисә исән булып та аларны тәрбияләү һәм асрау белән шөгыльләнмәгән 18 яшькәчә балалар.

Барлык очракларда да балалар турында кайгыртуны җәмгыять һәм дәүләт үз өстенә ала.

Өстәмә уку

Борынгы заманнарда җәмгыять ятимнәр турында кайгыртмаган. Индуслар, артык мәшәкатьтән котылу өчен, ятим балаларны Ганг елгасына ташлаганнар. Кытайлылар балаларны сатканнар, ә зәгыйфьләрен язмыш иркендә калдырганнар. Сүриялеләр һәм карфагенлылар балаларны аллаларга корбанга китергәннәр. Спартанлылар зәгыйфь балаларны үтергәннәр, ә ныгракларын дәүләт исәбенә үстергәннәр. Ятимнәргә карата гуманлыкны беренче булып афиналылар күрсәткән: Солон һәм Писистрат (б.э.к. VI гасыр) законнары белән ятимнәр турында кайгыртырга кушылган.

Император Траян (б.э. I гасыр) ташланган балалар өчен аерым йортлар булдыра.

XIX гасыр ахырында Россиядә ятим балаларга ярдәм системасы барлыкка килә. Мәскәүдә генә дә балалар өчен 200 ләп хәйрия йорты эшләп килә, шулардан 40 тан артыгын балалар приютлары тәшкил итә.

Тарих курсыннан борынгы заманда ук дәүләт дәрәҗәсендә ятимнәр турында кайгырткан Солон һәм Траян эшчәнлеге турында сезгә нәрсә мәгълүм? (Кирәк булганда, 5 нче сыйныф тарих дәреслегеннән файдаланыгыз.)

Безнең көннәрдә Россиядә, төрле мәгълүматлар буенча, 100 меңнән алып, 700 меңгә кадәр ятим бала санала.

Ятимнәр бүген бөтен дөньяда бик күп. Хәзерге тикшеренүчеләр барлык хастаханәләр, бала табу йортлары, махсус йортларның ташлап калдырылган сабыйлар белән тулы булуын билгеләп үтә.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау

Ятимнәргә ярдәмгә җәмгыять һәм дәүләт килә.

Россиядә **ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыруның күпсанлы формалары** яшәп килә: уллыкка (кызлыкка) алу, опека, гаиләгә алу, гаилә тибындагы бала-

лар йорты, балалар йорты, мәктәп-интернатлар, шифаханә мәктәпләре, коррекцияле мәгариф учреждениеләре һәм балалар йортлары һ.б.

Балалар Зур театрда Россия балалар фонды оештырган хәйрия спектакле башланыр алдыннан

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга аерым кешеләр дә ярдәм итә. Россиялеләр арасында иң киң таралган ярдәм булып интернат һәм балалар йортларына кием-салым җыю, уенчыклар, азык-төлек, акча бирү тора. Мондый булышлык та бик мөһим, әмма ул балага гаиләне алыштыра аламы соң?

Ярдәмнең иң кулай төре булып ятимне гаиләгә урнаштыру тора. Болай эшләгәндә иң яхшысы — уллыкка (кызлыкка) алу. Икенче урында — баланы опекун яисә попечитель гаиләсенә бирү. Өченчесе — гаилә балалар йорты.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Уллыкка (кызлыкка) алу — ата-анасыз калган баланы гаиләгә үз балалары хокукында алу.

Уллыкка (кызлыкка) алынган бала шунда туган бала хокукларын ала, ятим бала ташламаларын югалта. Димәк, ата-ана өчен уллыкка (кызлыкка) алу бала язмышы һәм аның тулы кыйммәтле тәрбияләнүе өчен иң югары дәрәҗәдәге җаваплылыкны йөкләү дигән сүз.

Уллыкка (кызлыкка) алучылар гаиләсе баланың яңа гаиләсенә әверелә, ул шунда туган бала статусы ала. Балага уллыкка (кызлыкка) алучыларның фамилиясе бирелергә һәм хәтта аның исеме дә үзгәрергә мөмкин. Уллыкка (кызлыкка) алынган баланың барлык хокуклары һәм бурычлары туган балалары хокуклары һәм бурычларына тигезләшә.

Баланы гаиләгә тәрбиягә алуның иң киң таралган формасы булып опека һәм попечительлек кала.

Опека 14 яшькәчә балаларга урнаштырыла, ә **попечительлек** — 14 яшьтән 18 яшькә кадәрле балигъ булмаганнарга. Опека йөкләнгән затны *опекун* дип атыйлар, ә аның вазифалары *опекунлык* дип йөртелә.

Россиядә, традиция буенча, балаларны опекунлыкка аның кардәшләре ала (80 проценты чамасы), шуларның 40 проценттан күбрәге — әбиләр һәм бабайлар. Туганнары тәрбияләүнең өстенлекләре байтак: балаларның тәрбияви һәм психологик проблемалары азрак була. Соңгы вакытта бала белән туганлык мөнәсәбәтләрендә тормаган опекуннар саны арта. Чит кешеләр баланы тора-бара уллыкка (кызлыкка) алу максатында опекага алалар.

Онохиннар гаилә балалар йортында.
Киров өлкәсе

Гаилә нигезендә **гаилә тибындагы балалар йорты** ачылырга мөмкин. Ир һәм хатын, үзара килешеп, тәрбиягә 5—10 бала ала.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар **кабул итү гаиләсенә** (тәрбиягә алган гаиләгә) дә урнаштырылырга мөмкин.

Шундый гаиләдә өлкәннәр хезмәт хакы ала. Һәр баланы асраган өчен аларга азык-төлек, кием-салым алырга дип һәм башка ихтыяҗларга акча түләнә. Кабул итү гаиләсенә бирелгән бала законнар нигезендә ташламага һәм 18 яше тулгач торак алуга хокукларын саклап кала. Мондый гаилә балалар өчен шифаханәгә, савыктыру лагерена, ял йортына юллама алуга (шул исәптән түләүсезгә дә) өстенлекле хокуктан файдалана.

Үз хокукларын яклый барып, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар судка яисә **Россия Федерациясе Президенты каршындагы Балалар хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә** (Татарстанның шундый ук үз вәкиле бар) мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Аның төп бурычы — баланың хокуклары һәм ирекләре гарантияләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, бозылган хокукларын торгызуга һәрьяклап булышу.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар билгеле бер ташламаларга ия. Мәсәлән, 18 яшенә җиткәч, алар түләүсез торак алырга хокуклы.

Россиянең күп кенә төбәкләрендә ятимнәргә өстәмә ташламалар: җәмәгать транспортында түләүсез йөрү, укыганда югарырак стипендия алу, уку дәреслекләре һәм язма әсбаплар сатып алу өчен пособие түләү һ.б. бирелә.

Россия дәүләт хакимияте органнары тарафыннан социаль ятимлекне кисәтүгә, шундый балаларга ярдәм итүгә юнәлтелгән махсус программалар кабул ителгән.

Йомгак ясыйбыз

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятимнәр — гаиләдә беркайчан тәрбияләнмәгән йә гомерләренең бер өлешен генә гаиләдә яшәгән балалар ул. Алар ата-ана игътибарыннан мәхрүм, шуңа күрә җәмгыять һәм дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗ.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, уллыкка (кызлыкка) алу

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Ятим балалар һәм социаль ятимнәр кемнәр алар? Алар кайда яши һәм тәрбияләнә?

2. Сез ничек уйлыйсыз, балалар нигә ятим кала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм була? Андый балалар нигә аерым кайгыртуга мохтаҗ?

3. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга дәүләт ничек ярдәм итә? Аларга һәр граждан ничек ярдәм итә ала?

4. «Уллыкка алу», «опека», «попечительлек», «кабул итү гаиләсе» нәрсә икәнлеген аңлатыгыз.

5*. Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турында сөйләгез (параграф нигезендә һәм Интернет, газета һәм журнал материалларын кулланып).

Практикум

1. Сезнең төбәктә урнашкан теләсә кайсы балалар йорты турында мәгълүмат җыегыз. Интернет, газета һәм журнал материалларыннан файдаланыгыз. Компьютерда презентацияләү әзерләгез.

2. Мәгълүм кинофильмнардагы һәм әдәби әсәрләрдәге ятим балаларны мисалга китерегез. Авыр тормыш хәлләреннән алар ничек чыга? Аларга кем ярдәм итә?

3. Уйлап карагыз әле, сез ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ничек ярдәм итә алыр идегез? Әти-әниегез яисә башка олылар ярдәмендә шуны эшләп карагыз.

§ 25. Кеше кече төркемдә

Нәрсә ул кече төркем? Кече төркемнәр нинди була? Кече төркемнәрдә кешеләр арасында мөнәсәбәтләр нинди була?

Җәмгыять — кешеләрнең төрле: зур һәм кечкенә, дустанә һәм дошман, даими һәм вакытлы, һөнәри һәм дини, милли һәм сәяси төркемнәре берлеге ул.

Алар үзара бик нык аерылып тора. Кайбер төркемнәр шулкадәр аз санлы ки, аның барлык әгъзалары көн дәвамында якыннан аралаша, бер-берсенең эшен күреп тора. Болар — **кече төркемнәр** яисә **шәхси бәйләнеш төркемнәре**. Гаилә — шундый төркемнең иң күренекле мисалы.

Кече төркем

Кеше кече төркемдә (гаиләдә) дөньяга килә һәм гомеренең күпчелек өлешен кече төркемнәрдә: укучылар коллективларында, спорт командасында, төрле түгәрәкләрдә, дуслары янында, студентлар һәм җитештерү коллективларында һ.б. уздыра.

Кызыклы фактлар

Шунысы ачыкланды: Җирдәге кешеләр төркеменең саны барлык халык санышнан 1,5—2 тапкыр күбрәк икән. Әйтик, планетада 7 млрд кеше яшәсә, белгечләр бәяләве буенча, төркемнәр саны 8—10 миллиардка җитә. Бу бер кешенең берничә төркемдә торуы мөмкин булуы аркасында килеп чыга. Мәсәлән, гаиләдә, класста, дуслар арасында, бию мәктәбендә, спорт түгәрәгендә һ.б.

Бериш төркемгә керү өчен, без билгеле бер тырышлык куябыз. Әйтик, мәктәпне тәмамлаучыларның күбесе институтка, университетка керергә, студент булырга тырыша. Башка төркемнәрне безгә әти-әни сайлый, мәсәлән, музыка мәктәбен яисә рәсем сәнгате түгәрәген. Без сайламаган, язмыш билгеләгән төркемнәр дә бар. Гаиләнең составы да өлешчә генә безнең сайлау нәтиҗәсе. Ә дусларны без сайлап алабыз һәм үз теләгебез белән ташлыйбыз.

Спорт командасы һәм дуслар — кече төркем үрнәге

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Төркем — кайсы да булса ягы белән бер-берсенә якын кешеләр бергәлеге.

Кече төркем бер-берсен яхшы белгән кешеләрдән тора.

Төркемдә, ягъни башкалар белән бергәләшеп, без үз шәхесебезне һәм яшәү кыйммәтләребезне формалаштырабыз. Без монда иң авырткан яки иң кадерле, таныш булмаган кешеләргә беркайчан да әйтмәслек серләребезне уртаклашабыз.

Төркемдә нормалар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр туа. Кеше төркемгә мохтаҗ һәм аңарга бәйле. Ул — гаилә, укучылар коллективы, ишегалды компаниясе, спорт секциясе һ.б. әгъзасы. Кешеләр бергәләшеп кенә яши ала.

Укучылар коллективы — кече төркемнең аерым бер төре. Мәктәп балалары өйләрендә яшиләр һәм беркадәр вакытка класста бергә җыелалар, монда аларның төп максаты — яңа белемнәр өйрәнү. Мәктәптә сез хезмәт куясыз, тәнәфестә ял итәсез, төшке аш ашыйсыз. Завод яисә банктагы хезмәт коллективы кебек үк. Укучылар коллективында сездә көн тәртибен саклау буенча **мәҗбүри мөнәсәбәтләр** формалаша, һәм бер-берегез белән мәҗбүри булмаган дусларча аралашу барлыкка килә. Алар шулай — дусларча мөнәсәбәтләр дип атала да.

Укучылар коллективына хас булган мәҗбүри һәм дусларча мөнәсәбәтләргә мисал китерегез.

Ике дус та — бер төркем. Аларны күп нәрсәләр, шул исәптән гомуми мәнфәгатьләр, уртак серләр булу берләштерә. Дуслыкның бәяләп бетергесез сыйфатларының берсе — сер саклый белү. Бала дустына «зур сер итеп» берәр яшерен нәрсәне хәбәр итә, һәм тегесе башкаларга әйтмәвен таләп итә. Әгәр дә дус серне чишкән икән, алар ачуланышырга мөмкин. Ул сезнең серне чиште, чынбарлыкта сезнең ышанычны сатты. Моннан соң авыр минутларда аңа таянып булмый.

Кече сыйныфларда укучылар һәм яшүсмерләр үзләренә дус итеп кыйммәтләре һәм мавыгулары үзләренекенә охшаган малай-кызларны сайлый. Дусларны күпчелеге үз мәктәпләре, үз сыйныфлары, кагыйдә буларак, үзләре җенесендәге укучылардан сайлыйлар. Малайлар күбрәк, малайлар белән, ә кызлар кызлар белән дус була.

Яшүсмер өчен ул үзе торган төркемнең аның турындагы фикере бик мөһим. Кайсы да булса төркемнеке булуны, теләктәшлек, иптәшләрчә ярдәмчеллекне аңлау яшүсмергә иминлек һәм тотрыклылык хисе бирә.

Шәхесара мөнәсәбәтләр

Кече төркемдә мөнәсәбәтләрнең аерым бер төре — шәхесара мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу сүзләргә игътибар итегез әле: шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләр. Ягъни яшүсмерләр — инде шәхесләр булган.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Шәхесара мөнәсәбәтләр — кече төркемдә яхшы таныш кешеләр арасында даими шәхси аралашу процессында барлыкка килүче мөнәсәбәтләр.

Кече төркем бер-берсен яхшы белгән кешеләрдән тора. Үзара даими аралашып, бергәләп нидер эшләп, кешеләр үзләренең шәхси һәм гаилә проблемалары турында сөйләшәләр, мәктәп яңалыкларын, билгеләрен, класстан тыш чараларны, яңа фильмнарны һ.б. кызыксынып тикшерәләр. Үзләре өчен бик мөһим мәсьәләләрне бергә тикшерү кешеләрне якынайта, алар арасында ышаныч тудыра.

Галимнәр тарафыннан бик кызык закончалык ачыкланган: кешеләрнең сезгә карашы күпчелек очракларда сезнең үзегезгә ничек каравыгыз белән билгеләнә. Моны, һичшиксез, аңларга һәм исегездә калдырырга тырышыгыз. Бу — **шәхесара мөнәсәбәтләрнең иң мөһим законы**. Әгәр дә сез һаман үзегездән канәгать булмасагыз, сезнең бу ризасызлык башкаларга да күчәргә мөмкин. Алар да сездән канәгать булмаячак. Әгәр сез үзегезгә түбән бәя куясыз икән, тирә-юньдәгеләр дә шулай гына бәяли.

Яшүсмерләр төркемнәрендә — сезнең яшьтәшләр коллективларында — стихияле төстә үз намус кодексларыгыз формалаша, аларның норма һәм кагыйдәләре өлкәннәр дөньясыннан күчереп алына. Монда тугрылык, намуслылык югары бәяләнә һәм сатлыкҗанлылыкка, хыянәткә, биргән сүзне үтәмәүгә, эгоизм, комсызлыкка һ.б. тискәре карыйлар.

Яшүсмерләр үз фикерләре булмаган, үзләрен хөрмәт итмәгән, үз мәнфәгатьләрен яклый белмәгән яшьтәшләренә катгый бәя бирәләр.

Барысыннан да аерылып торырга омтылыш булса да, яшүсмерләр төркемнәрендә **конформизм** — барысы белән дә килешү хөкем сөрә. Берәү барысына да бәйле була, яшьтәшләренә охшарга омтыла һәм кайчакта төркем кушканның барысын да үтәргә әзер. Сезнең яшьтәгеләр һәм

бераз өлкәнрәкләр дә, үзләренең бер-берсенә якын торуын күрсәтер өчен, бер үк стильдәге һәм төрдәге кием кия башлыйлар.

Шәхесара мөнәсәбәтләрдә үзара аңлашу, кече төркем әгъзалары арасындагы аралашуның ничек үсеп китүе бик мөһим. Аңлашу тапмагач, без ялгызлык кичерәбез. Ә ялгызлык — еш кына кеше иң курыккан нәрсә ул.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмер, олы кеше кебек үк, нинди дә булса кече төркем: гаилә, мәктәп, түгәрәк, секция һ.б. әгъзасы ул. Төркемдәге мөнәсәбәтләргә карап, яшүсмер үзен азмы-күпме рәхәт хис итә.

Кече төркемнәр тугрылык, хөрмәт, намус кебек төшенчәләргә нигезләнгән үзара аңлашу, дусларча мөнәсәбәтләргә таянып яши.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Төркем, кече төркем, шәхесара мөнәсәбәтләр

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Кече төркем», «конформизм», «шәхесара мөнәсәбәтләр» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Яшүсмерләр өчен үзләре кергән төркем нинди әһәмияткә ия? Җавабыгызны мисаллар белән ныгытыгыз.

3. Төркемдә яшүсмер өчен нинди проблемалар туарга мөмкин? Аларны хәл итү ысулларын тәкъдим итегез.

4. Яшүсмерләр төркеме аның һәр әгъзасы тәртибенә йогынты ясыймы?

5*. Нормалар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр нигә нәкъ менә төркемдә туа?

Практикум

1. Сез нинди төркемнәргә керәсез? Аларда югары бәяләнүче шәхси сыйфатларны атагыз.

2. Уйлап карагыз, яшүсмер нинди очракларда төркем фикеренә (мәсәлән, сыйныфташлары фикеренә) каршы тора ала?

3. Сез «Яшүсмер кергән төркем аңа үз-үзенә ышаныч бирә» дигән әйтем белән килешәсезме? Үз җавабыгызны нигезләгез.

4. «Кешеләргә син үзеңә алар ничек каравын теләгәнчә кара» дигән раслауны ничек аңлыйсыз?

5*. Шәхесара мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләрен ачып бирүче хәлләр уйлап чыгарыгыз.

26. Аралашу

Нәрсә ул аралашу? Аралашу нинди була?

Хатын-кыз һәм балалар — планетада иң күп сөйләшүчеләр, диләр. Аларның көндәлек эшчәнлегенең 80 проценты аралашып уза. Әгәр дә бу шулай мөһим икән, әйдәгез, әлеге проблеманы тикшереп карыйк.

Аралашу — кешеләр арасында үзара йогынтының төп формасы

Аралашу — кешеләр арасында үзара йогынты ясауның төп формасы. Күпләр ул тик сүзләр ярдәмендә генә барадыр, дип уйлый. Ә чынлыкта сүзләрне әйтмичә, мәсәлән, ымлашып та аралашырга була.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Аралашу — сөйләшеп һәм сөйләшмичә мәгълүмат алмашу рәвеше.

Аралашу рәвеше — кешенең эчке халәтен тапшырырга мөмкинлек бирүче аралашу күнекмәләре кушылмасы.

Яшүсмерләрнең **аралашу даирәсе** — аның белән мәгълүмат алмашучы кешеләр составы һәм саны — бик тар. Ләкин яше арту белән, ул даими киңәя бара.

Яшь арту белән, мәгълүмат күләме һәм аның эчтәлеге һаман үсә.

Олыгая барган саен, аралашуның роле арта. Кешеләр белән аралашу сәләте, мәсәлән, эшкә урнашканда яисә эшлек-ле сөйләшүләр алып барганда, кешенең язмышын хәл итә, карьерага ирешергә булыша (яисә аны тоткарлый).

Шуңа да бала чактан ук аралашу күнекмәләрен булдырыгыз һәм **рәвешен** камилләштерегез.

Аралашу рәвеше үзен түбәндәгеләрдә күрсәтә:

- *аралашу тонында* — дулкынланган, тыныч, боеручан;
- *тәртиптә* — кешенең аралашканда үз-үзен тотышында: тотрыклы, тынгысыз, басым ясап;
- *үзенә карату да* — аралашканда үзен ничек сизә (ышанычлы, ышанычсыз, башкага ышанып, сакланып);
- *сүзләрендә* — кеше үзенең фикерен һәм хисләрен әйтеп бирү өчен кулланган җөмләләрендә.

Ышанычлы, ышанычсыз, дорфа, битараф аралашу рәвешләре аеруча күп очрый.

Аралаша белүгә күп очракта сезнең язмышыгыз бәйле. Үзегезне күзәтегез: сезнең өчен нинди аралашу рәвеше хас?

Яшьтәшләр белән аралашу

Укытучылар, ата-ана, өлкән танышлар һәм таныш булмаган кешеләр, ниһаять, үз яшьтәшләре белән аралашып, яшүсмер тормыш турында кирәкле белемнәр ала. Яшьтәшләр белән аралашу — ә 5 нче сыйныфтагылар шуңа өстенлек бирә, — шулкадәр мавыктыргыч була ки, балалар кайчакта дәресләрен һәм өйдәге бурычларын да онытып җибәрә. Ул кызыклы гына түгел, мәгълүматлы

да: яшүсмерләр үзләренә олылар әйтмәгән темалар һәм әйберләр турында да белә.

Теләсә нинди яшүсмер якын дус турында хыяллана. Ул «100 процентка», үзең кебек ышанычлы, бернигә дә карамый сиңа бирелгән һәм тугрылыклы булсын. Дуста охшашлык, аңлау, кичерә белү эзлиләр.

Дуслык — кешенең даими юлдашы. Ул барлык чорларда, барча халыкларда, бөтен җәмгыятьтә, төрле яшьтәге һәм җенестәге кешеләрдә булган. Һәр кеше, олымы ул, кечеме, дусларга мохтаҗ.

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Дуслык — кешеләр арасындагы үзара тартылуга, рухи якынлыкка, мәнфәгатьләр уртаклыгына нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Дуслык кеше тормышының барлык этапларында бик мөһим роль уйный.

Кешеләр балалар бакчасында, мәктәптә, университетта, өлгергән яшьтә һәм картайгач та дус була. Һәм һәр чакта үзгәреп тора. Аның *эчтәлеге* үзгәрә.

Балалар әле генә танышкан теләсә кемне дус дип саныйлар. Әнисе, ишегалдындагы комлыкта кем белән уйнадың, дип сорагач, нәни бала, һич шикләнмичә, дус белән, дип җавап бирә. Мәктәп чорында дусны инде сайлыйлар, дуслык бик тиз «яралана» һәм алмашынып тора.

Гадәттә иң күп дуслар бала һәм яшь чакта була. Аннары яшүсмер моңа аңлы карый, һәм дуслык бәйләнешләре кими. Соңрак иң ныклы элемтәләр генә кала. Дуслар саны 5 тән дә кими. 30 яшьләргә кадәр без дуслар табабыз, ә аннан соң югалтабыз. Тормыш шулай корылган инде.

Дуслар әбиең белән бабаң яки әти-әниең гафу итәргә мөмкин булган кыланмышларыңны гафу итмиләр. Дуслык яшүсмер тормышында мөһим роль уйный, чөнки дуслар безнең җитешсезлекләр турында объектив фикер йөртә һәм бу хакта ата-анасы әйтеп бетермәгәнне дә әйтә. Шулай итеп алар файдалы роль башкара һәм безне акрынлап олылар тормышына озата бара.

Укучы, үзенең яшьтәшләре ышанычын югалтуга караганда, укытучылар һәм әти-әнисе белән мөнәсәбәтләрен катлауландыруны артыграк күрә.

Ныклы һәм ышанычлы дусларың булмаса, шәхес дәрәҗәсенә җитү катлаулырак.

Соңгы елларда үзеңә Интернет аша дуслар табу, алар белән мобиль телефон аша гына сөйләшү модага әверелде. Шулай итеп аралашу формасы үзгәрде — *турыдан-туры* (йөзгә-йөз) сөйләшүдән *техника аша аралашуга* әверелде.

Кызыклы фактлар

Мобиль телефоннардан дөньяда 11 дән алып 24 яшькәчә 1 млрд 600 млн егет һәм кыз файдалана. Алар ел саен мобиль элемтәгә 330 млрд доллар сарыф итә. Бу барлык музыкаль индустриягә тотылганнан 12 тапкыр күбрәк. Уртача европалы беренче мобиль телефонын 7 яшендә ала. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, 13—14 яшенә Россия яшүсмерләренең 98 проценты мобиль элемтәдән актив файдаланучыга әверелә.

Яшүсмерләр файдаланган төп хезмәтләр — шалтыратып сөйләшү һәм SMS хәбәрләр. Соңгылары — дуслар белән аралашуның төп ысулы; ата-аналар SMSны 4 тапкыр сирәгрәк ала. 15–16 яшендә дусларга җибәргән SMS саны 10–12 яшьлекләр белән чагыштырганда 2 тапкыр арта. Бактың исә, SMS ярдәмендә аралашу еш кына гади сөйләшүләрдән кыйммәткәрәк төшә. Галимнәр, SMSка бәйле, яшүсмерләрдә тынычсызлык, үз-үзеңә ышанмау һәм үзеңне түбән бәяләү ешрак очравын ачыклады.

Уйлап карагыз әле, турыдан-туры аралашмауның уңай һәм тискәре яклары нидән гыйбарәт? Җавабыгызны нигезләгез.

Замана баласы мобильник яисә компьютер белән генә түгел, Интернет белән дә бергә үсә. Аңа компьютер уеннары, ICQ, «В контакте» кебек социаль челтәрләр гадәти нәрсә (соңгы вакытта анда кече яшүсмерләрнең күпләп керүе күзәтелә). Интернет пәрәвезе Җирнең бөтен өслегенә — Америкадан Австралиягә кадәр, хәтта Антарктидага да җәелгән. Аның белән бергә тагын бер бәла — **Интернетка бәйлелек** килде.

Өстәмә уку

«Интернетка бәйлелек» термины XX гасыр ахырында Америка психологы Иван Голдберг тарафыннан, Интернеттан бертуктаусыз файдалану теләген тасвирлау өчен тәкъдим ителде. Интернетка бәйлелек шулкадәр киң колачлы проблемага әверелде ки, кайбер илләрдә аны наркомания белән чагыштырырлык авыру дип таныйлар.

Интернетка бәйлелекне ни өчен наркоманлык белән чагыштыруларын уйлап карагыз. Җавабыгызны нигезләгез.

Интернетка бәйлелек кешеләрнең даими рәвештә чатта яисә башка интерактив сайтларда булуыннан гыйбарәт. Әгәр дә сез Пәрәвез челтәрендә рәттән берничә сәгать утырасыз икән, чаң кагарга вакыт. Интернетка бәйле кешеләр чынбарлыкны аңламый башлый. Виртуаль дөнья торган саен, кызыграк, ә чынбарлык күңелсез һәм еш кына дошман яклы була бара. Чынбарлык белән хыял арасындагы чик юыла, ә бу бик куркыныч. Шуңа да Интернеттан алган мәгълүматны бик белеп һәм файдага гына кулланырга кирәк. Һәм компьютерда эшләүне сәламәтлегең һәм психикаң өчен зарарлы нәрсәгә түгел, ә файдалы шөгыльгә әйләндерү зарур.

Йомгак ясыйбыз

Аралашу сәнгате кеше гомеренең барлык этапларында зур әһәмияткә ия. Аралашканда без кирәкле мәгълүмат алабыз, дуслар булдырабыз. Соңгы елларда техника ярдәмендә аралашу йөзгә-йөз очрашуны кысрыклап чыгара.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Аралашу, аралашу рәвеше, дуслык

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. «Аралашу», «аралашу рәвеше», «дуслык» сүзләрен ничек аңлыйсыз?

2. Үзегезнең аралашу даирәсенә керүчеләрнең исемлеген төзегез. Анда керүче малайларны сайлап алуда нинди критерийлар кулландыгыз?

3. Нәрсә ул Интернетка бәйлелек? Мобиль телефонга да шундый ук бәйлелек бармы?

4. Нәрсә ул дусларча серләр? Алар каян килеп чыга? Үз серләреңне дусларыңа чишәргә кирәкме?

Практикум

1. Сез «Иске дус ике яңа дустан яхшырак», «Дуслар бәладә сынала», «Йөз сум акчаң булганчы — йөз дустың булсын» дигән мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Дуслык турындагы мәкальләр исемлеген дәвам итегез.

2. «Дуслыкта ... юл куелмый» дигән әйтемне тутырыгыз.

3. Безнең күбебез әти-әниләргә яисә укытучыларга иптәшләрен сатмас өчен (әйтик, мәктәптәге шаянлыклары өчен) малайларның нахакка, хәтта рәхимсезлеккә дә түзеп торырга әзер булуына мисаллар искә төшерә ала. Сезнең белән шундый хәл булдымы? Ул очракны тасвирлагыз.

4. Сезнең һәрвакыт ярдәм кулы сузарлык һәм бөтен дөреслекне әйтеп бирерлек дустыгыз бармы? Аның турында сөйләгез.

5. Сезгә тарихтан һәм әдәбияттан мәгълүм чын дуслыкка мисал китерегез.

6*. Бөек борынгы грек философы Платон үзенең дусты һәм укытучысы Сократны кайбер әсәрләренә керткән. Шуңа да «Сократ миңа дус, ләкин хакыйкать кыйммәтрәк!» дигән сүзләрне аныкы, диләр. Сез ничек уйлыйсыз, Платон сүзләрендә каршылык юкмы? Җавабыгызны нигезләгез.

§ 27. Шәхесара конфликтлар

Нәрсә ул конфликт? Конфликтлар нилектән була? Конфликтларны ничек чишәргә?

«Конфликт» сүзе бездә шөбһәле хис тудыра. Ул беркемгә дә ошамый. Ә шулай да конфликт — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең табигый рәвеше. Аңардан курыкырга түгел, аның килеп чыгышын һәм хәл итү ысулларын белергә кирәк.

Шәхесләр арасындагы конфликтлар

Хәтерегездә калдырырга киңәш итәбез!

Конфликт — кешеләрнең, төрле мәнфәгатьләрнең, фикерләрнең килешмәүчәнлеге, бәхәсе яисә бәрелеше ул.

Кызыклы фактлар

Конфликтларның 80 проценты анда катнашучыларның теләгеннән башка килеп чыгуы билгеле.

Конфликтларны хуплаучы аз, әмма аңарда барысы да диярлек катнаша.

Иң күп конфликтлар шәхесара мөнәсәбәтләр өлкәсендә була.

Шәхесара конфликтлар — нинди дөрес сүзтезмә! Яшүсмерләр арасында бәрелеш ике шәхес, мөстәкыйль, бай эчке дөньясы булган һәм үз гамәлләре өчен җаваплылыкны аңлаган, өлгереп җиткән кеше арасындагы конфликт ул. Менә нигә шәхесара конфликтлар шулай катлаулы.

Шәхесара дип аларны әйберләр аркасында чыккан бәхәснең бик җиңел генә шәхесләргә күчүе өчен дә атарга мөмкин: син минем авторучканы сорамый алгансың, димәк, син — карак. Уйламыйча гына кылынган гамәл бик тиз гаепләүгә һәм, моның соңы буларак, гаепләнүчене мыскыллауга әверелә. Яшүсмерләр бик катгый фикер йөртә.

Мондый конфликтлар эшлекле бәхәсләргә караганда авыррак хәл ителә, чөнки кеше шәхесенең иң тирәндәге хисләренә — әхлакый инануларга һәм принципларга кагыла.

5 нче сыйныф укучысы катнашкан конфликт ике төргә бүленә:

1) **буыннар арасындагы** — өлкәннәр (укытучы, әти-әнисе, күршеләр) һәм балалар конфликты;

2) **бер буын эчендәге** — яшьтәшләр арасындагы конфликтлар.

? Сезнең буын эчендәге конфликтның сәбәбе нидә?

Зур кешенең һәм баланың статуслары төрле. Өлкәннәрнең югарырак статусы аларны еш кына конфликтны өстенлек позициясеннән чыгып хәл итәргә этәрә. Олы кеше бар көченә үзе хаклы булуга ышандырырга тырыша, төрле фикерләр булу мөмкинлеген танымый. Олыларның статус өстенлеге яшүсмерне яки саклану (аклану) позициясенә басарга, йә агрессив позициягә мәҗбүр итә.

Балалар үзара каршы торса, аларның статусы бер үк төрле була. Бу исә бәхәсләшүчеләрне озак вакыт бер-берсенә бирешмәскә өнди.

Шәхесара конфликтта катнашучыларның һәркайсы хаклы булуына ышана. Өлкән кеше бала һичшиксез чигенергә тиеш дип саный һәм җиңүгә өметләнә, ә яшүсмер тигез булмаган көрәштә үз хисләрен генә белдерә.

Күпчелек яшүсмерләрнең олылар аларны аңлавы мөмкин түгел дип санавына гаҗәпләнергә кирәкме соң? Тик бу дөрес түгел!

Конфликтлар нидән килеп чыга

Яшүсмерләрнең үз-үзләрен контрольдә тота белмәве аркасында теләсә нинди вак-төяк: өй эшен күчерергә бирмәү, сыйныфташларның ничек каравы яисә уйланылмаган сүзе, үзенең тышкы кыяфәте, укытучының гадел булмаган бәясе, ата-ана игътибарсызлыгы, кәефе начар булу һ.б. конфликт сәбәбе булырга мөмкин.

Ә чынлап карасаң, бу сәбәп түгел, конфликт өчен бер юл гына, аның әһәмияте дә юк диярлек. Ә чын сәбәп — үсеш үзенчәлекләрендә һәм шуның белән бәйле артык комплекслануда.

Яшүсмерләрнең артык комплекслануының иң еш сәбәпләрнең берсе — малай яисә кызның үз кыяфәте белән ризасызлык. Моңа буйлары кечкенә булу, артык авырлыгы, күзлек киеп йөрү һ.б. да керә.

Конфликт чыгуга сәбәп булып тышкы кыяфәтнең бөтенләй кечкенә (кайчакта — уйлап чыгарылган) кимчелеге дә хезмәт итә ала. Әти-әнисе һәм яшьтәшләреннән үз адресына әйтелгән гаепсез шаярту да ул чакта агрессиягә сәбәп була ала.

Мәктәптә укучы һәм укытучы арасында, укытучыларның үзара, администрация белән укытучылар арасында конфликтлар чыга. Мәктәп чикләрендә яшүсмерләр арасындагы конфликтлар, барыннан да бигрәк, хисләргә һәм шәхси дош-манлыкка нигезләнә.

Укучылар арасында **лидерлык конфликтлары** иң киң таралганы, аларда ике-өч лидерның һәм алар төркемчекләренең сыйныфта беренчелек өчен көрәше чагыла. Урта сыйныфларда еш кына егетләр төркеме һәм кызлар төркеме каршы тора.

Яшүсмерләрнең әти-әниләре белән конфликты киң таралган, алар хакында без алдагы параграфларны үткәндә сөйләштек инде.

Конфликтларны хәл итү юллары

Өйдә үзләре генә калганда, балалар әти-әниләре кебек булырга тырышалар. Мәктәптә исә конфликтларны хәл итәргә педагоглардан өйрәнәләр, кайчакта вак-төяккә кадәр

аларга охшатып кыланалар. Башлангыч мәктәптә укытучы — күпчелек бала өчен иң зур абруйлы кеше, һәм аның үзүзен тотышы — балалар өчен үрнәк.

Иң уңышлысы булып конфликтны демократик юл белән хәл итү — анда катнашучылар белән бергәләп аның сәбәпләрен, якларның мәнфәгатьләрен ачыклау һәм аларны килештерү ысулларын табу тора.

Практика күрсәткәнчә, эшлекле конфликтлар күбесенчә— хезмәттәшлек яисә компромисс юлы, ә шәхесара конфликтлар юл кую юлы белән хәл ителә.

Конфликтта арадашчы катнашса, бигрәк тә яхшы. Бу рольгә фәкать ике яктан да хөрмәт ителүче, эмоциональ яктан конфликтка тартылмаган һәм кемнең дә булса җиңелүенә кызыксынмаган кеше генә ярый. Моннан тыш ул җитәрлек кадәр зирәк һәм мондый мәсьәләләрне хәл итүдә тәҗрибәле булырга тиеш, югыйсә хәл тагын да катлауланачак һәм конфликт хәл ителмәслек хәлгә киләчәк.

Өстәмә уку

Конфликтлар санын киметү өчен, ата-ана — мәктәп таләпләрен, ә укучылар үзләренең тәртип кагыйдәләрен төгәл белергә тиеш.

Башка кеше гамәленә җавап биргәнче, аның нигә башкача түгел, ә нәкъ менә шулай эшләвен ачыклау зарур.

Бу тексттан сез конфликтларны булдырмау буенча нинди файдалы киңәшләр алдыгыз?

Шәхесара конфликтлар, бер яктан, безнең күңелләрдә ризасызлык һәм дошманлык хисләре, башка кешегә зыян китерү теләге уята, үз тирәсендә киеренке хәл тудыра һәм стресс уята. Икенче яктан, конфликт безнең хисләрне һәм фикерләүне чыныктыра. Ул киеренкелекне йомшарта, **компромисс** — үзара юл куюга бару — табарга, үз амбицияләреңне чикләргә өйрәтә, яшүсмерләр арасында үзара аңлашуны үстерүгә этәрә. Килешүгә бару — кыйммәтле нәрсә. Менә шуңа да конфликт ихтыяр көчен

чыныктыра, башка кешеләрнең карашларын һәм хисләрен аңлый белергә өйрәтә.

Конфликтларны җайга салырга һәм килешү юлын табарга өйрәнегез

Бала чактан ук үз хаталарыңны танырга һәм гафу үтенергә өйрәнергә кирәк. Әгәр дә бәхәсләшүчеләргә кочаклашырга, татулыкны кул кысышу белән беркетергә тәкъдим итсәң, килешү ихласрак була.

Шәхесара конфликтларда катнашуның төп файдасы — киләчәктә аларны булдырмаска өйрәнү. Шуны исегездән чыгармагыз: конфликтларны хәл итүгә караганда булдырмый калу җиңелрәк.

Йомгак ясыйбыз

Шәхесара конфликтлар ике төрле әһәмияткә ия: алар киеренке хәл тудыра һәм стресс китереп чыгара, шул ук вакытта кешеләрне бер-берсен аңларга, компромисс табарга өйрәтә. Нинди генә хәлдә дә мөнәсәбәтләрне конфликтка җиткермәскә тырышырга һәм иң мөһиме — барлык конфликтларда үз хаталарыңны таный белергә, гафу үтенергә кирәк.

Төп терминнар һәм төшенчәләр

Конфликт, компромисс

Белемнәрегезне сынап карагыз

1. Шәхесара конфликтларның сәбәпләрен аңлатыгыз.

2. Мәктәп тормышының кайсы яклары тирәсендә конфликтлар ешрак була?

3. Конфликтларны хәл итүдә арадашчылык нәрсә ул?

4. Ата-ана яисә укытучы таләпләренә буйсынмау нәрсә ул — конфликтның сәбәбеме, юлымы әллә башлануымы?

5. Укучылар арасында конфликт анда катнашучыларга да, бөтен сыйныфка да тискәре йогынты ясый. Нигә алай икәнлеген аңлатыгыз.

Практикум

1. Дәфтәрегездә мөмкин кадәр күбрәк дәлилләр язып куегыз: «Конфликт — начар нәрсә, чөнки...» һәм «Конфликт — файдалы ул, чөнки...».

2. Әгәр дә сезнең конфликтларны чишү тәҗрибәгез булса, аны берничә җөмлә белән тасвирлагыз.

3*. Борынгы заман тарихыннан конфликт мисалларын һәм аларны чишү ысулларын китерегез.

2 бүлеккә йомгаклау сораулары һәм биремнәре

1. Замандашлар, иптәшләр һәм яшьтәшләр ни белән аерыла?

2. Гаилә һәм туганнар үз балалары шәхесен ничек итеп формалаштыра?

3. Гаилә кыйммәтләре нигә гаиләнең тарихи хәтере булып тора?

4. Сезнең гаиләдә булган барлык рольләрне (буынара, ир һәм хатын, ата-ана, балалар һ.б.) тасвирлагыз.

5. Ата-ана белән балалар арасындагы конфликтларның сәбәбе нәрсәдә?

6. Кайсы очракларда гаиләдәге әрләшү уңай якка ия? Сез ничек уйлыйсыз, килешү атмосферасы нәрсә ул?

7. Тәрбия — бер кешенең икенчесенә йогынты ясавы процессы ул. Ә икесе дә бер-берсенә тәэсир итә алмыймы?

8. Тәрбияләү барышында мәдәни кыйммәтләрнең бер буыннан икенчесенә тапшырылуы ничек бара?

9. Сезнең гаиләдә башка кешеләр белән (туганнар, дуслар) аралашуның нинди мәдәни нормалары кабул ителгән?

10. Нигә баланың тормышы һәм үсешенә кагылган иң мөһим карарларны алар үзләре түгел, ә олылар кабул итә?

11. Табигатьтәге аталы-аналы кошлар, җәнлекләр үз балаларын исән калырга гына өйрәтәләр, ә кешеләр үз балаларын зәгыйфьләргә ярдәм итәргә дә өйрәтә. Нигә шулай?

12. Сез ничек уйлыйсыз, нигә әти-әниләре балаларын тәрбияләү өчен җаваплы һәм аларның физик һәм рухи сәламәтлеге турында кайгырта? Ә балалар нәрсә эшләргә тиеш?

13. Безнең илдә күп балалы гаиләләргә ничек ярдәм итүләре турында сөйләгез. Сезнең карашка алар өчен тагын нәрсәләр эшләргә булыр иде?

14. Әти-әнисе тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау нидән гыйбарәт?

15. Ике категория кешеләр — ятим балалар һәм социаль ятимнәр ни белән аерыла? Сезнең алар белән аралашканыгыз бармы? Шул хакта сөйләгез.

16. Уйлап карагыз әле, кече төркемнәр юкка чыкса, җәмгыять һәм кеше мөнәсәбәтләре белән нәрсә булыр иде?

17. Түбәндәге әйтемне исбатлагыз: башкаларның сезгә карашы күбесенчә сезнең үзегезгә карашыгыз белән билгеләнә.

18. Сезнең мәктәп коллективында (сезнең сыйныфта) тугрылык, намуслы булу югары бәяләнә, ә хыянәт, сатлыкҗанлык, биргән сүзеңдә тормау, эгоизм һәм комсызлык җәзага тартыла дип буламы? Аның турында тагын нәрсә әйтергә мөмкин?

Йомгаклау тесты

1. Җәмгыять белеменә берничә фән элементлары керә. Шул исәптән:
   1) социология, политология
   2) география, физика
   3) биология, математика
   4) астрономия, химия

2. 5 нче сыйныф укучысы Арслан яхшы укый, мәктәп театрында уйный, спорт белән шөгыльләнә һәм йөзү буенча шәһәр чемпионы булырга омтыла, әнисенә кечкенә энекәшен караша. Болар барысы да Арсланны түбәндәгечә характерлый:
   1) укучы буларак
   2) дус
   3) шәхес
   4) ул буларак

3. 5 нче сыйныфта укучы кыз Васила һәр көнне ниндидер гамәлләр һәм яхшылыклар кыла. Түбәндә санап үтелгәннәрдән кайсысы яхшылыкка керә?
   1) автобуска утыра
   2) өлкән кешегә урын бирә
   3) фатирларына лифтта менә
   4) өйгә бирелгән эшне башкара

4. Рухи һәм социаль ихтыяҗлар — кешенең иң югары ихтыяҗлары. Аларга түбәндәгеләр керә:
   1) ризык, кием-салым
   2) аралашу, белемнәр
   3) әйберләр, акча
   4) автомобиль, компьютер

5. Түбәндәге гыйбарәләрнең кайсы дөрес:

1) Җәмгыять белемен өйрәнгәндә иң мөһиме — тойгылар аша белү.

2) Уку — 5 нче сыйныф укучысының төп эшчәнлек төре.

3) Кеше белемне мөстәкыйль рәвештә, өйрәтүче ярдәменнән башка ала.

4) Инвалидлар гадәти балалар белән бергә укый алмый.

6. Лилия 5 нче сыйныфта укый, музыка мәктәбендә шөгыльләнә, яшьтәшләре һәм олылар белән аралаша, әбисе һәм бабасына булыша, әти-әнисе белән бергә сәяхәт итә, музей һәм театрларга йөри. Болар барысы да түбәндәгечә атала:

1) гадәт

2) социальләшү

3) үз-үзеңә бәя бирү

4) традиция

7. 5 нче сыйныфтагылар — кече яшьтәге яшүсмерләр алар. Сезнең яшькә тагын нинди сүз ачып бирә?

1) күчү чоры

2) балигъ булу

3) яшьлек

4) җитлегү

8. Яшүсмерләрдә дә, өлкәннәрдә дә нинди социаль статус була ала?

1) урта мәктәп укучысы

2) автомобиль йөртүче

3) Россия гражданы

4) социология фәннәр докторы

9. Әнисә өстәл әзерләргә өйрәнә, әнисенә төшке ашны пешерергә булыша, ә Илдар дача өчен эскәмия ясый, әтисе белән бергә океан лайнеры моделе җыя. Болар барысы да түбәндәгеләрнең чагылышы:

1) үз-үзеңне танып белү
2) толерантлык
3) гендер социальләшүе
4) акылсыз ихтыяҗ

10. Россия — дөньядагы иң күп милләтле дәүләтләрнең берсе. Безнең илдә яшиләр:
1) берничә милләт
2) 50 чамасы милләт
3) 100 милләт
4) 200 ләп милләт

11. Бу мисалларның кайсы шәхесара мөнәсәбәтләрне иллюстрацияли?
1) Дәүләт башлыгы телевидение буенча чыгыш ясый.
2) Дуслар татулашты һәм җәйге каникулларга уртак планнарын әзерли.
3) 5 нче сыйныф укучысы нәфис уку конкурсында чыгыш ясый.
4) Табиблар халыкара конференциядә фәнни доклад тыңлый.

12. Кеше турындагы түбәндәге фикерләр дөресме:
А. Кеше — биологик һәм социаль җан иясе.
Б. Кеше — фәкать социаль җан иясе.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

13. Танып белү турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Әйләнә-тирә дөньяны акыл ярдәмендә танып белү «рациональ» дип атала.
Б. Әйләнә-тирә дөньяны танып белүдә хисләр бик кечкенә урын тота.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

14. Үз-үзеңне бәяләү турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Үз-үзеңне бәяләү — кешенең үз сыйфатларын, сәләтен, өстенлекләрен һәм кимчелекләрен бәяләве ул.
Б. Үз-үзеңне бәяләү һәрвакыт югарырак булырга тиеш.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

15. Шәхесара конфликтлар турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. 5 нче сыйныф укучысы катнашкан конфликтлар буынара һәм бер буын эчендәге була.
Б. Конфликтта татулаша, үз хатаңны таный белергә кирәк.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

16. Кеше тормышында төп яшь баскычлары һәм гомер чорлары арасында тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганадагы тиешле позицияне сайлап куегыз.

ЯШЬ БАСКЫЧЛАРЫ	ГОМЕР ЧОРЛАРЫ
А) балачак	1) 11—15 яшь
Б) яшүсмерчак	2) 19—30 яшь
В) яшьлек	3) 11—12 яшькә кадәр
Г) өлкәнлек чоры	4) 30—60 яшь
Д) олылык чоры	5) 80 яшьтән олырак
Е) картлык	6) 60—80 яшь

17. Төшенчәләрне һәм аларның билгеләмәләрен туры китерегез: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганадагы тиешле позицияне сайлап куегыз.

ТӨШЕНЧӘЛӘР	БИЛГЕЛӘМӘЛӘР
А) гендер	1) мәгълүмат алмашуның сөйләм һәм сөйләм булмаган рәвеше
Б) дуслык	2) мәдәни нормаларны үзләштерү һәм социаль рольләргә керү
В) инклюзив белем бирү	3) социаль җенесе
Г) аралашу	4) кешеләр арасында үзара бәйлелеккә, рухи якынлыкка, мәнфәгатьләр уртаклыгына нигезләнгән мөнәсәбәтләр
Д) социальләшү	5) гадәти балаларны һәм инвалид балаларны бергә укыту

ЙОМГАКЛАУ

«Җәмгыять белеме» фәнен өйрәнүнең беренче елы узып та китте. Сез үзегезне һәм үзегез яшәгән җәмгыятьне яхшырак аңлый башладыгыз дип ышанам. Без, бергәләшеп, сез көндәлек тормышта, мөгаен, очрашкан, ләкин игътибар биреп җиткермәгән нәрсәләрне ачыкларга тырыштык. Алар сезгә болай да ачыктан-ачык күренеп торгандай тоела.

Җәмгыять белеме әлегрәк сез уйлап та карамаган нәрсәләрне өйрәнә. Бактың исә, кешедә ике башлангыч — биологик, кешенең табигатьтәге үткәненнән килгәне һәм социаль-мәдәният һәм тәрбия аша җәмгыятьтән алынганы яшәп килә. Аларның үзара көрәшендә шәхес — үз гамәлләре өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга сәләтле мөстәкыйль кеше формалаша.

Кеше үсешен табигый башлангычның социаль кысрыклавы процессы буларак күзалларга мөмкин. Нәкъ менә социаль башлангыч кешегә сәламәт яшәү рәвеше алып барырга кирәклеген исенә төшерә. Тәмәке тарту, алкоголизм, наркомания — аларга каршы без бергәләп көрәшкән иҗтимагый авырулар. Ә менә артык күп ашау, аз хәрәкәтләнү яисә өлкәннәргә карата дорфалык гадәте — начар яшәү рәвешенең индивидуаль сыйфатлары. Һәм сезгә аларны үзегезгә җиңәргә туры киләчәк.

Сез кешенең гомере буе дөньяны һәм үз-үзен танып белүе турында белдегез. Танып белү тойгылы (ул биш тою органы ярдәмендә башкарыла) һәм рациональ (анда вакыйгаларның асылы, дөньяның закончалыклары ачыла) була.

Үзен һәм башкаларны бәяләп, яшүсмер үзе һәм башка кешеләр турында хакыйкатьне ачарга (үзенә тәнкыйть күзлегеннән карап, барысын да рациональ анализлап) яисә

ялган белемнәр (үз өстенлекләрен арттырып һәм хисләргә бирелеп) алырга мөмкин. Үз-үзеңне дөрес (объектив) бәяләү кече төркемдә ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштырырга, ә иң мөһиме — тугрылыклы һәм ышанычлы дуслар булдырырга ярдәм итә.

Дөньяга дөрес караш булдыруда социальләшү — мәдәни нормаларны һәм социаль рольләрне үзләштерү булыша. Нигездә шәхесне әхлакый тәрбияләү ята, моңа мәдәни нормаларга өйрәтү һәм социаль рольләрне урнаштыру өчен җаваплы конкрет кешеләр (барыннан да элек алар — сезнең гаилә һәм укытучылар) ярдәм итә.

Гаилә өч типтагы социаль мөнәсәбәтләргә: ирле-хатынлы, ата-ана булуга, туганлыкка корыла. Аларны гаилә статуслары һәм рольләре — туганлык функцияләрен, гаилә әгъзасы хокукларын һәм бурычларын бүлешү бәйләп тора.

Гаилә мөнәсәбәтләре дустанә һәм конфликты булырга мөмкин. Конфликтсыз гаиләләрдә ата-ана балаларга үз тиңнәре итеп карый: аларның киңәшләрен тыңлый һәм хокукларын исәпкә ала. Дәүләт гаилә иминлеге турында кайгырта, аңа икътисади (пособие һәм ташламалар), административ-хокукый (бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша) һәм социаль (социаль яклау хезмәтләре аша) ярдәм күрсәтә.

Шулай итеп, без 6 нчы сыйныфның төп темасына — җәмгыять тормышы структурасына килеп җиттек. Сез киләсе уку елында иҗтимагый алгарышның нәрсә икәнен, хәзерге заман җәмгыятенең нинди өлкәләрдән торуын, Россиянең дәүләт төзелешен һәм Россия Федерациясе Конституциясендә ниләр язылганын белерсез.

СҮЗЛЕК

Акылга сыймаслык ихтыяҗлар — кешегә зыян сала торган ихтыяҗлар.

Акылга сыярлык ихтыяҗлар — кешегә файда китерә торган ихтыяҗлар.

Ана (гаилә) капиталы — балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең бер төре.

Аралашу — сөйләшеп һәм сөйләшмичә мәгълүмат алмашу рәвеше.

Аралашу рәвеше — кешенең эчке халәтен тапшырырга мөмкинлек бирүче аралашу күнекмәләре кушылмасы.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар — әтиәниләре үлгән яисә исән булып та аларны тәрбияләү һәм асрау белән шөгыльләнмәгән 18 яшькәчә балалар ул.

Әхлак — игелек һәм явызлык турындагы күзаллауларга нигезләнгән, җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар.

Бала — 18 яше тулмаган кеше.

Балигъ булмаганнар — закон нигезендә олы кешеләр түгел дип танылган, 18 яшькә җитмәгән затлар.

Белем алу — махсус учреждениедә укытучы җитәкчелегендә уку.

Белемнәр — танып белү нәтиҗәсе, кеше үзләштергән мәгълүмат.

Биологик (грек теленнән bios — тормыш, logos — тәгълимат) — табигый; терек табигать белән бәйле.

Бурыч — нәрсәне дә булса эшләү зарурлыгы.

Буын — бер яшьтәге, бер үк тарихи чорда яшәүче барлык кешеләр.

Гадәт — кешегә хас тәртип рәвеше. Ул ихтыяҗ характеры ала (мәсәлән, иртәләрен теш чистарту).

Гаилә — никахка яисә кан кардәшлегенә нигезләнгән, уртак көнкүреш, үзара ярдәмләшү, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән кешеләр берләшмәсе.

Гаилә кыйммәтләре — гаиләнең тарихи хәтеренең бер өлеше, бабаларыбызның бабаларыннан мирас булып килүче гореф-гадәтләр.

Гаилә рольләре — гаилә әгъзаларының үз бурычларын үтәве һәм үз хокукларын тормышка ашыруы.

Гаилә традицияләре — гаиләдә кабул ителгән, буыннан буынга тапшырылып килүче нормалар, тәртип рәвеше, гадәтләр һәм карашлар.

Гамәл — кешенең үзен шәхес буларак таныткан аңлы эше.

Гендер — ир-атның яисә хатын-кызның җәмгыятьтәге тормыш эшчәнлеге үзенчәлекләре белән бәйле, социаль җенес (ир-ат яисә хатын-кыз җенесе).

Гендер рольләре — ир-атка һәм хатын-кызга хас үз-үзләрен тоту модельләре, шулай ук әйләнә-тирәдәгеләрнең бу рольләрне башкаручыларга баглаган өметләре.

Гендер социальләшүе — кызларны һәм малайларны аларга тиешле ир-ат һәм хатын-кыз рольләрен башкару өчен тәрбияләү.

Граждан — законлы нигездә билгеле бер дәүләт кешесе.

Гражданлык — кеше һәм дәүләтнең үзара хокуклары һәм бурычларында чагылган сәяси-хокукый бәйләнешләре; кешенең билгеле бер дәүләтнеке булуы.

Дәүләтнең социаль ярдәме — аз керемле гаиләләргә, үзләре генә яшәүче аз керемле гражданнарга акчалата түләү, социаль хезмәтләр күрсәтү һәм яшәү өчен кирәкле тауарлар бирү.

Дуслык — кешеләр арасындагы үзара тартылуга, рухи якынлыкка, мәнфәгатьләр уртаклыгына нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Дуслык кеше тормышының барлык этапларында бик мөһим роль уйный.

Җаваплылык — үз гамәлләрең яисә эшчәнлегең өчен җавап тоту бурычы.

Закон — дәүләт хакимияте карары.

Иерархия — нәрсәнең дә булса өлешләренең (элементларын) түбәннәреннән югарыларына таба, мөһим булмаганнарыннан (икенчелләреннән) мөһимнәренә таба эзлекле урнашуы.

Иҗтимагый (латин телендәге «socialis» сүзеннән) — җәмгыятьнеке; җәмгыятькә бәйле.

Иҗтимагый хәл — кешенең җенесе, яше, белеме, һөнәре, икътисадый (матди) хәле, сәяси мөмкинлекләре кебек позицияләр нигезендә характерлануы.

Икътисад — җитештерүне оештыру һәм кешеләрнең икътисадый эшчәлеген өйрәнүче фән.

Иминлек, куркынычсызлык — кешенең яшәве өчен мөһим мәнфәгатьләренә зыян китерергә сәләтле нинди дә булса куркыныч һәм янаулар булмау.

Инвалид (мөмкинлекләре чикләнгән яисә аерым ихтыяҗлары булган кеше) — физик яисә акыл ягыннан, психик тайпылышлары аркасында мөмкинлекләре чикле кеше.

Инвалидлык — нинди дә булса эшчәнлекне кеше өчен нормаль саналган дәрәҗәдә башкару сәләтенең чикле булуы яисә бөтенләй булмавы.

Инклюзив белем — гадәти балаларның мөмкинлекләре чикле балалар белән бергә укуы.

Интеллект — белем туплауга һәм проблемалар чишүгә сәләтлелек.

Ихтыяҗлар — кешеләргә кирәкле төрле файдалы нәрсәләр ул. Әйтик, азык-төлек, һәм өс-баш, мәхәббәт һәм кайгырту, дуслык һәм ярдәмчеллек, музыка һәм спорт, белем алу һәм аралашу, сәяхәт итү һәм башкалар.

Ихтыяр — сайлап алуга һәм гамәл кылуга сәләтлелек.

Кардәшлек дип уртак әби-бабай, уллыкка-кызлыкка алу яисә никах белән бәйле кешеләр берлеге атала.

Кече төркем бер-берсен яхшы белгән кешеләрдән тора.

Кеше хокуклары — дәүләт тарафыннан сезнең ихтыяҗларга туры килүче һәм башка кешеләр теләгенә каршы килмәгән бар нәрсәне эшләү мөмкинлеген тәэмин итү.

Кешенең үз яшь статусына яраклы рәвештә үз-үзен тотышы яшь роле дип атала.

Кешенең үз-үзен тотышы — аның билгеле бер максатка юнәлтелгән һәм әхлак (игелек һәм явызлык) күзлегеннән чыгып бәяләнә торган гамәлләре җыелмасы.

Конфликт — кешеләрнең, төрле мәнфәгатьләрнең, фикерләрнең килешмәүчәнлеге, бәхәсе яисә бәрелеше ул.

Культурология — мәдәниятне өйрәнүче фән.

Куркыныч — кеше гомеренә зарар китерергә мөмкин булган күренеш.

Кызыксыну — нәрсәгә дә булса яисә кемгә дә булса аңлы ихтыяҗ; нинди дә булса предмет белән танышу нияте, аны танып-белүгә омтылыш. Әйтик, әдәбият, спорт, медици-

на, чәчәкләр үстерү, музыка белән шөгыльләнү, сәяхәт итү мәнфәгате.

Кыйммәтләр — шәфкать, гаделлек, ватанпәрвәрлек, мәхәббәт, дуслык һ.б. турында күпчелек кешеләр тарафыннан хуплана һәм дөрес дип табыла торган күзаллаулар. Кыйммәтләр шик астына куелмый, алар барлык кешеләр өчен эталон, идеал булып тора.

Мәдәни нормалар — кешенең җәмгыятьтә үзен-үзе тоту кагыйдәләре.

Мәдәният — кеше тарафыннан тудырылган бар нәрсә; билгеле бер халыкка хас булган нормалар, кагыйдәләр, традицияләр һәм йолалар.

Мәнфәгать — нәрсәгә дә булса яисә кемгә дә булса аңлы ихтыяҗ; нинди дә булса предмет белән танышу нияте, аны танып белүгә омтылыш. Әйтик, әдәбият, спорт, медицина, чәчәкләр үстерү, музыка белән шөгыльләнү, сәяхәт итү мәнфәгате.

Миграция — кешенең яшәү урыны белән бәйле рәвештә бер урыннан икенчесенә (бер ил чикләрендә) яисә бер илдән икенчесенә күченүе.

Милләт — нинди дә булса бер милләттән, халыктан булу.

Өстен ихтыяҗларга омтылу — кешенең түбән (матди) ихтыяҗларын үтәүдән өстен (рухи, иҗтимагый) ихтыяҗларын үтәүгә күчүе.

Политология — җәмгыятьнең сәяси оешуын өйрәнүче фән (дәүләт төзелеше, сәяси партия, парламент, хөкүмәт эшчәнлеге).

Психология — кешенең эчке дөньясы һәм аның үз-үзен тотышы турындагы фән.

Сәламәт яшәү рәвеше — авыруларны кисәтү һәм сәламәтлекне саклау максатындагы яшәү рәвеше.

Сәләт — кешенең нәрсә булса да эшли белүендә, нинди дә булса шөгыльгә яисә һөнәргә хирыслыгында чагылыш тапкан шәхси үзенчәлеге.

Социаль (латин телендәге socialis сүзеннән) — җәмгыятьнеке; җәмгыятькә бәйле.

Социаль роль — җәмгыятьтә тоткан урынына карап (ул, кыз, ата, ана, укытучы, укучы, сатып алучы, сатучы һ.б.), кешенең үз-үзен тоту өлгесе.

Социаль статус — кешенең җәмгыятьтәге иҗтимагый хәле.

Социаль ярдәм — гражданнарга дәүләт бюджеты хисабыннан билгеле бер күләмдәге акчаны ярдәм итеп бирү.

Социальләшү — мәдәни нормалар һәм иҗтимагый рольләрне үзләштерү.

Социология — җәмгыять төзелешен, аңа керүче кешеләр төркеменең үзара йогынтысын өйрәнүче фән.

Танып белү — мәгълүмат алуга, саклауга, эшкәртүгә һәм системалаштыруга юнәлтелгән эшчәнлек.

Танып белү туризмы — табигать, тарих һәм мәдәният истәлекләре, җирле халыкның көнкүреше һәм традицияләре, халык һөнәрләре һәм кәсепләре, фән, мәдәният, сәнәгать һ.б. казанышлары белән танышу өчен төрле урыннарда булу максатларында туристик йөрүләр, сәяхәтләр, экскурсияләр, сәфәрләр.

Тәрбияләү — бер кешенең икенчесенә аңа кирәкле тәртип кагыйдәләре һәм әхлакый кыйммәтләр өйрәтү максатында йогынты ясавы буенча юнәлтелгән процесс.

Темперамент — кешенең индивидуаль сыйфатлары, беренче чиратта, хис-тойгыларының җитезлек һәм көчлелек дәрәҗәсе белән характерлана. Темперамент кеше хәрәкәтләренең үзенчәлекләрендә дә чагыла.

Толерантлылык — ят яшәү рәвешенә, кешеләрнең хисләренә, гореф-гадәтләренә, ышанулары һәм фикерләренә түземле караш.

Төркем — кайсы да булса ягы белән бер-берсенә якын кешеләр бергәлеге.

Традицияләр — буыннан-буынга тапшырылучы һәм озак вакыт дәвамында яшәп килүче социаль һәм мәдәни мирас.

Үзлегеңнән белем алу — кеше тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, билгеле бер уку йортына йөрмичә генә белем алу.

Үз-үзен танып-белү — кешенең үз-үзен танып-белүе.

Үз-үзеңә бәя бирү — кешенең үзен-үзе, үз мөмкинлекләрен, сәләтләрен, сыйфатларын һәм башка кешеләр арасында тоткан урынын бәяләве; кешенең үз-үзеннән алган тәэсире яисә үзе турындагы фикере.

Үсмерлек чоры — балаларның 11-12 яшьтән 15 яшькәчә үсеше вакыты, бу 5-8 сыйныф укучылары яшенә туры килә.

Уллыкка (кызлыкка) алу — ата-анасыз калган баланы гаиләгә үз балалары хокукында алу.

Фикерләү — кеше танып белүенең иң югары баскычы. Ул чынбарлыкның турыдан-туры тою органнары ярдәмендә мәгълүмат алып булмый торган үзенчәлекләре һәм мөнәсәбәтләре турындагы белем тупларга мөмкинлек бирә.

Философия — дөнья корылышының гомуми мәсьәләләрен өйрәнүче фән.

Характер — кешенең үз-үзен тотышында һәм эшчәнлегендә чагылыш тапкан индивидуаль үзенчәлекләре җыелмасы.

Шәхес — үз гамәлләре өчен үзе җавап бирергә сәләтле, аңлы эшчәнлеккә әзер булган мөстәкыйль кеше.

Шәхесара мөнәсәбәтләр — кече төркемдә яхшы таныш кешеләр арасында даими шәхси аралашу процессында барлыкка килүче мөнәсәбәтләр.

Экстернат — төп гомуми, урта (тулы) гомуми, югары белем программаларын мәгариф учреждениеләрендә арадаш һәм дәүләт (йомгаклау) аттестацияләре белән мөстәкыйль өйрәнүне күздә тотучы белем алу рәвеше.

Этәргечләр — кешенең үз-үзен тотышы һәм аның гамәлләре сәбәпләре. Этәргечләр ихтыяҗлар һәм кызыксынулар йогынтысында барлыкка килә.

Эшчәнлек — озак вакыт дәвамында башкарылган һәм конкрет максатны күздә тоткан гамәлләрнең (акыл яисә физик яктан) эзлеклелеге. Эшчәнлек үҗәтлек, максатчанлык, даими тырышлык таләп итә.

Юриспруденция — хокукны — законнарда язылган һәркемгә мәҗбүри тәртип кагыйдәләрен өйрәнүче фән.

Яшүсмерлек чоры — балаларның 11—12 яшьтән 15 яшькәчә үсеше вакыты, бу 5—8 нче сыйныф укучылары яшенә туры килә.

Яшь роле — кешенең үз яшь статусына яраклы рәвештә үз-үзен тотышы.

Яшь статусы — теге яисә бу яшь өчен хас булган хокуклар һәм бурычлар җыелмасы.

Яшьтәшләр — бер үк яшьтәге кешеләр.

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ БУЕНЧА ИНТЕРНЕТ РЕСУРСЛАРЫ

http://www.constitution.ru — Россия Федерациясе Конституциясе

http://www.uznay-prezidenta.ru — Россия Президенты мәктәп яшендәге гражданнарга

http://www.rfdeti.ru — Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

http://www.youthrussia.ru — Россия яшьләр һәм балалар берләшмәләре Милли советы

http://semyarossii.ru — Россия гаиләсе

http://www.detskiedomiki.ru — Аеруча мохтаҗ балалар турында кайгыртучанлык

http://www.unicef.ru — БМО Балалар фонды (ЮНИСЕФ)

ИННОВАЦИОН
МӘКТӘП
ФДМС





ХӘТЕР
«РУССКОЕ СЛОВО»